ВИНИСА ФӘТТАХОВА

КЫШКЫ ЧИЯ

ВИНИСА ФӘТТАХОВА

КЫШКЫ ЧИЯ

Шигырьләр, җырлар, хикәяләр, эссе, юморескалар

КИТАП
УФА • 2014

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2 Рос=Тат)-5
Ф 96

Фәттахова, В. Ш.

Ф 96 Қышкы чия: шигырьләр, җырлар, хикәяләр, эссе, юморескалар / Виниса Фәттахова. — Уфа: Китап, 2014. — 296 бит.

ISBN 978-5-295-06072-4

Халык яратып өлгергән күп кенә җырлар авторы Виниса Фәттахованың бу китабына төрле елларда язылган шигырьләре, җырлары, проза әсәрләре тупланды. Кыскача әйткәндә, Туган ил, туган төбәк, яшәеш, мәхәббәт турында алар. Автор, тормышында нинди генә авырлыклар булса да, еракта калган бала чагын, яшьлеген сагынып яза.

ЗИ — 2014

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2 Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-295-06072-4

© Фәттахова В. Ш., 2014

ДУС БУЛДЫК БЕЗ ГОМЕРГӘ

Русиянең бер кадерле
Баласы — башкорт иле.
Ватанның да, бездәгедәй,
Назлы, ягымлы җиле.
Ашлыклар ишелеп уңа
Җирләребез тигезгә.
Җитәкләп Агыйдел суын
Идел ага диңгезгә.
Дядя Ваня, башкорт Юлай
Дус булдылар гомергә.
Кулга-кул тотынып гел дә
Яшәде алар бергә.
Бер үк азык, бер үк икмәк —
Ашаган ризык-ашлар.
Алда да булырбыз бергә,
Тик исән булсын башлар.
Җырлап-биеп, уйнап-көлеп
Үтсен безнең киләчәк.
Тыныч, дус яшәүләр генә
Уңышларга илтәчәк.

РУС – БАШКОРТ ДУСЛЫГЫ

Русияне таң калдырып
Яши башкорт илебез.
Курай тыңлап, җырлап-биеп
Үтсен һәрбер көнебез.
Ике телдә сөйләшсәк тә,
Бер үк уй, бер үк теләк.
Русиягә башкорт халкы
Үзе кушылган теләп.
Авырлыклар килә калса,
Русия безгә терәк.
Яклар өчен, саклар өчен
Русия безгә кирәк.
Киләчәк гомерләребез
Үтсеннәр татулыкта.
Аралашсын рус һәм башкорт
Исәнлектә, саулыкта.

БАШКОРТСТАН КЫЗЫ МИН

Горурланам чын күңелдән:
Башкортстан кызы мин.
Матур, гүзәл туган җирдә
Гомер юлын узамын.
Туган җирем – Башкортстан,
Шуңа да мин бәхетле.
Ташлап аны, чит җирләрдән
Эзләп йөрмим бәхетне.
Көчтән килсә, шушы җирне
Чәчәккә күмәр идем.
Ташлап китсәм, илкәем,

Сагыштан үләр идем.
Килгәннәр дә үз итәләр
Башкортстанның җирен.
Төпләнәләр, уйламыйлар
Кайтып китәргә кире.
Мәдхияләр күп язылды,
Язылыр әле тагын.
Мәңге җырлап туялмаслык,
Сөямен гүзәл ягым.

ТУГАН ИЛЕМ – БӘХЕТЕМ

Җир йөзендә гомер буе
Яши байлар, ярлылар,
Яшиләр ятим, ялгызлар,
Бик бәхетле парлылар.
Бәхетле булырга лаек
Һәркем дә җир йөзендә.
Өмет сүнми гомер буе,
Хәтта гомер көзендә.
Эзлисе юк зур бәхетне,
Диңгез гизеп, чит илдән.
Мөмкинчелекләр җитәрлек,
Эзләсәң туган җирдән.
Җилләр исәләр еракка,
Иярмим мин җилләргә.
Туган илләремнән китмәм
Бер белмәгән җирләргә.
Кайда тусаң, шунда яшәү –
Зур бәхет кеше өчен.
Чәчкәгә бизә илеңне,
Кызганмыйча бар көчең.

ҖАН ДУСТЫМА

Иске дустым — җан дускаем —
Кадерле син миңа бик.
Дус булырбыз гомер буе,
Язмыш аермасын тик.
Дуслар тапсаң, сына башта,
Сыналганы — тугры дус.
Булыр-булмас кешеләрне
Ерактан ук урап уз.
Иске дустым — сыналган дус,
Туганым кебек якын.
Пакь күңелле, эчкерсез,
Тора ай кебек балкып.
Ярдәм кирәк була калса,
Килеп җитә йөгереп.
Исәнлек-саулык сорашып,
Минем хәлемә кереп.

ИЛКӘЕМ

Ничек инде яратмассың
Туып-үскән иләңне?!
Туендырган, сыендырган,
Икмәк биргән җиреңне.
Эчеп кенә дә туймассың
Бәллүр, татлы суларын.
Һәркөн иртән урап чыгам
Таллы елга буйларын.
Кырларда арыш чайкала,
Җилләр йөгертә дулкын.

Исем китеп карап торам:
Дулкыны гүя алтын.
Бөтен җаным белән сөям
Туган изге җиремне.
Һәрчак әзермен эшләргә,
Түгеп кара тиремне.
Бер илгә дә алыштырмам
Газиз туган илемне.

ЯЛГЫЗЛЫК

Энем дә юк, сеңлем дә юк,
Апам да, абыем да.
Көнләшеп куям күп вакыт,
Дусларга карыймын да.
Кемгә барып сыенырга
Белмим мин мохтаҗ чакта.
Адашсам, юл күрсәтергә
Беркемем тормый чатта.
Кем иңнәренә таяныйм,
Кемгә сөйлим серемне?
Бик ачынган чакларымда
Ятып кочам җиремне.
Ялгызлык рәхәт диеп,
Әйтә күрмәгез, дуслар.
Кыен булса, бик күп бала
Чыгармас иде кошлар.

БАЛАЧАКНЫ САГЫНАМ

Матур, күңелле балачак
Чыкканы юк усмнан.
Яланнар буйлап йөгердек,
Ләззәт таптык уеннан.
Кайтыр идем балачакка –
Инәкәем янына,
Җанга рухи азык биргән
Туып-үскән ягыма.
Яланаяк чабар идем
Бөтен урамны буйлап,
Зәңгәр күкле авылымның
Саф һаваларын сулап.
Истән чыкмый авылдашлар,
Күршеләр, сыйныфташлар.
Сагындыра туган җирем,
Туган йорт, нигез-ташлар.
Әмма болар – хыялларым,
Бары тик уйлар гына!
Балачакка кайтаргандай
Тик сабантуйлар гына.

ШИКӘР ТӘМЕ

Баш котылса да сугыштан,
Котылмадык ачлыктан.
Тәмле иде умачлы аш,
Солы оны кылчыктан.
Шикәр кайткан кибеткә дип,
Сүз таралды яшендәй.
Төсе ап-ак, кап-каты таш –

Китәргә дә теш үтми.
Белә идем акча югын,
Үтенеп сорасам да;
Шикәр ашыйсым килә дип,
Ачынып еласам да.
Ишеткәнем дә булмагач
Шикәр дигән мәмәйне,
Истә: ялкытып бетердем
Акча сорап әнкәйне.
«Ниндирәк була ул шикәр?
Күрәсем килә», — дидем.
Үтенеп сорагач, әнкәй:
«Мә икс тәңкә», — диде.
Акчамны учыма тотып
Йөгердем мин кибеткә.
Каты шикәрне күрмәдем,
Чаба-чаба килеп тә.
Ике тәңкә акча тотып
Йөгереп барып җиттем.
Бер уч шикәр комы алып,
Сөенеп кайтып киттем.
Башкаемны әйләндерде
Шикәрнең баллы тәме.
Башка бернәрсә кирәкми,
Шушыдыр дөнья ямс.

ЯШИК ЯКТЫ ТОРМЫШТА

Ходаема рәхмәтлебез,
Яшибез имин көндә.
Җаннарыбыз тыныч булса,
Якты караңгы төн дә.

Яшәсәк иде гел шулай
Тыныч тормышта гына.
Мәрхәмәтле була йөрәк
Нурлы караштан гына.
Карый белсәк тирә-якка
Ак күңелебез белән,
Кояшлы имин тормышта
Яшәр илебез гелән.
Яшик гади кеше булып,
Күреп гел яхшылыкны.
Күрә белсәк яхшылыкны,
Күрербез яктылыкны.

ЭТӘЕМ, ИСӘНБАЕМ

Туып-үскән газиз җирем,
Син мәңге күңелемдә.
Шөкер кылам һаман да мин:
Яшим туган илемдә.
Туганмын мин Этәемдә
Көзнең салкын аенда.
Каһәрле сугыш елында
Үстем Исәнбаемда.
Ике авылым да газиз,
Күңелемә бик якын.
Сагышта үтә гомерем,
Йөрәгем тулы ялкын.
Кайтам дисәм, кайта алмыйм
Сөйгән туган ягыма.
Һәрчак безгә вакыт җитми:
Еллар елдам агыла.

Шулай инде, өч көнлек эш
Үлсәң дә кала, диләр.
Сагыш еллары йөрәккә
Ярасын сала, диләр.
Саг(ы)нуымның чамасы юк,
Кайтырмын, озакламам.
Илешемә юл тотармын,
Ят сукмактан атламам.

ХАЛКЫМ САНЛАСЫН МИНЕ

Һич йөрмимен дан артыннан,
Ул миңа кирәкми дә.
Барыбер бер үк сукмактан
Атлыйбыз син дә, мин дә.
Мин гашыйкмын матур җырга,
Күңелем тулы моңга.
Язам йөрәгем кушканга,
Кызыгып түгел данга.
Бәгыремнән таша җырлар,
Изге сүзләр түгелә.
Туган җирем, туган илем
Җырга, моңга күмелә.
Яратып җырласа җырчы,
Куш(ы)лса шуңа халык,
Халкым биргән шушы данны
Кара бизмәнгә салып.
«Син шагыйрә түгелсең лә,
Тормыйсың Союзда да, —
Дигән булалар берәүләр, —
Җыр, шигырьләр язма да!»

Исемнәргә исем китми,
Яздым, язачакмын да!
Сөйгән халкым алкышларын
Алдым, алачакмын да!

ӨЗМИК ӘЛЕ ӨМЕТЛӘРНЕ

Гомерләр булгач — яшибез,
Аллага шөкер итеп.
Харап булырга язмасын,
Вакытсыз җирдән китеп.
Мәхрүм итмә, Аллаһ, безне
Дөньяның ләззәтеннән,
Аерма шатлык, бәхеттән,
Яраткан хезмәтемнән.
Озын гомер, сәламәтлек
Бир, Аллаһ, һәркемгә дә.
Әти, әни, туганнардан
Аерма бер көнгә дә.
Өзмик әле өметләрне,
Бәлки, йөзгә житәрбез,
Күңелләр булганчы яшәп,
Риза булып китәрбез.

ЧИШМӘ ҖЫРЫ

Туктамый еллар, гасырлар,
Таудан чишмәләр ага.
Тирән дәрья елгалар да
Суын чишмәдән ала.

Эчеп үскән чишмә суым
Үзгә тәмле, дәвалы.
Чишмәбезнең тирә-ягы
Иркен, таза һавалы.
Чишмә буйларында уза
Язын сабантуйлары.
Исемнән һич чыкканы юк
Ямьле чишмә буйлары.
Җырлый-җырлый ага чишмә,
Юлы озын шуңадыр.
Җырлап яшик, туганнарым,
Гомерне озайта җыр.
Чишмә сулары озайта
Безнең дә гомерләрне,
Күз карасы кебек саклыйк
Чишмә чыккан җирләрне.

ЮАНЫЧЫМ

Бәхетле бул, бәләкәчем,
Сөекле оныккаем.
Баһадир кебек көчле үс,
Кадерле балакаем!
Сөеп туялмыйм үзеңне,
Бигрәкләр дә татлысың.
Шат күңелле, һәрчак шаян,
Йөгереп кенә атлыйсың.
Алга барыр юлларыңны
Күк капусы яктыртсын.
Күңелеңдә матур гөлләр
Ап-ак чәчкәләр атсын.

Оныгым, син бәләкәчем,
Шатлыгым, куанычым.
Сагыш төшкәндә күңелгә,
Син — минем юанычым.

ӘТИЕМӘ ИСТӘЛЕК

Күз яшьләремә буылам.
Күзләремдә — күк томан,
Гомер буе, ничә еллар
Әтине көтәм һаман.

Ярый әле сагынучы,
Искә алыр кешең бар,
Бердәнбереңң, газиз балаң,
Кызчыгың, җимешең бар.

Әнием дә тугры калды
Тәүге сөйгән ярына,
Киткәнче мәңгелек йортка,
Шөкер кылып барына.

Тугансың гүзәл Илештә,
Ятып калдың еракта,
Инде күпме еллар үтте,
Һаман да син йөрәктә!

Җиңү көне бәйрәмендә
Кем шатлана, кем елый,
Казанда солдат боткасы
Ветераннарны сыйлый.

АЛЫШТЫРМА ЧӘЧӘКНЕ

Эльверт Гарафетдинов көе

Сөям сине, дип әйтәсең,
Акчаң бармы кесәңдә?
Сөеп кенә яшәп булмый,
Нәрсә генә дисәң дә.
Акчаң юк икән кесәңдә —
Син түгелсең беркем дә.
Кесәң тулы акчаң булса —
Бар да синең иркеңдә.
Таһир белән Зөһрәләр дә
Баралар бугай бетеп.
Кызларның гомерс уза,
Бай бабайларны көтеп.
Диңгез аръягы байлары —
Яшь кызларның хыялы,
Яше, төсе мөһим түгел,
Өелеп торса малы.
Корыган көзге агачка
Алыштырмаң чәчәкне.
Сиңа тиң матур табылыр,
Ходай насыйп иткәне.

ДОГАЛАР КЫЛАСЫҢДЫР

Һәр әни дә баласына
Изге бәгырьле була.
Шатлыктан да, сагыштан да
Бик тиз күңеле тула.
Әни өчен иң зур шатлык—

Балалары уңышы.
Тик балалар өчен генә
Бөтен хафа-сагышы.
Җибәрмәс иде янынан
Бер адымга баласын.
Ерак китсәм, тыны белән
Кигә тартып аласы.
Әнием кояш нурыдай
Җылыта ерактан да.
Аның җылысын тоеп, мин
Уянам иртә таңда.
Күңелем сагыштан тулы,
Әнием истә гел дә.
Газизем, бәхетләр телим,
Күмелеп яшә гөлгә.
Көт, әнием, мин кайтырмын,
Беләм, сагынгансыңдыр.
Миңа изгелекләр теләп
Догалар кыласыңдыр.

ДУСТЫМА

Зур уңышлар телим сиңа,
Хафалар йөрсен качып.
Сезнең өйгә керсен бәхет,
Ишекне киереп ачып.
Чир-чорлар дөньяда сезнең
Барлыкны белмәсеннәр.
Кайгылар аяк астында
Буталып йөрмәсеннәр.
Яшь егетләр әби димә,

Апа дип дәшә әле.
Кояш кебек нурлар чәчеп
Яшә дә яшә әле.
Саф йөрәкле, ак күңелле,
Син, дускаем, кадерлем.
Синең өчен утка-суга
Керергә дә әзермен.
Тәгәрәп, гомер йомгагың
Менсен биек үрләргә.
Насыйп итсен Ходай безгә
Йөз яшеңне күрергә.

ЯШЬЛЕКНЕҢ СЕРЕ

Яшьлекнең серләре нидә,
Сөйләсәң иде безгә?
Яз-җәйне сикереп узып,
Җитәсе килми көзгә.
«Һич картая белмиссең син,
Хикмәтен әйтмәссеңме? —
Диеп сорыйлар дусларым. —
Серен сөйләмәссеңме?»
Хәрәкәттә бәрәкәт, ди,
Җитез булырга кирәк.
Иренмәскә бер эшкә дә,
Йөгереп йөрергә кирәк.
Моң сөяргә, җыр сөяргә,
Җырлап яшәргә кирәк.
Шәраб, хәмер кебекләрне
Кирәк эчәргә сирәк.
Шат күңелле, изгелекле,
Рәхим-шәфкатьле булыйк.

Йөрик урманда, кырларда,
Тышта саф һава сулыйк.
Чиста, пөхтә киеник тә
Салкын суда коеныйк.
Атлыйк тик изге юллардан,
Хәрәм эштән тыелыйк.
Кершән, хушбуй да сөртегез —
Матур булыр битегез.
Һәркемгә елмаеп-көлеп
Сәлам биреп үтегез.

СӨЙКЕМСЕЗНЕ КЕМ СӨЙСЕН?

Кара күңелле адәмнәр
Ник туалар дөньяга?
Үзенең кара күңелен
Ак күңеллегә яга.
Хәнҗәрен, угын кадарга
Һәрвакыт әзер алар.
Кирәк чакта иксйөзле,
Төче сүзләләр алар.
Ялган юлында йөриләр,
Туры сүздән куркалар.
Тугрылыкны, ихласлыкны
Тамырыннан кыркалар.
Борын күктә, корсак — мичкә,
Җәнап дип үзен тоя.
Күп чак сөмсере бозылган,
Гүя бозлы су коя.
Кеше сөйми, сөю тоймый
Яшиләр ерткыч булып.

Шушы ямьле дөньябызга
Туган корыткыч булып.
Үзең сөймәсәң кешене,
Кеше дә сине сөймәс.
Сәлам бирмәсәң кешегә —
Кеше дә сиңа бирмәс.

ГОМЕР БЕР ГЕНӘ

Нигә соң кеше яши бер генә,
Килмәгән икән җиргә мәңгегә?
Кемдәдер була кояш гомере,
Кемгә бирелә бик тә аз генә.
Яшәргә кирәк, саклыйк гомерне,
Күпме бирелсә, шуңа кадәрле.
Елмай, көл, җырла, тырышып эшлә,
Гомеркәйләр бит бик тә кадерле.
Яшьләр өстәлә, гомер кыскара,
Көннәр артыннан көннәр узалар.
Кешеләр түгел, хәтта киемнәр дә,
Кия-киелә, берчак тузалар.
Күпме яшибез — шөкерләр кылыйк
Бер Ходай бүләк иткән гомергә.
Тынычлап яшик, канәгать булып,
Ихлас шатланып һәр туган көнгә.

ӘТКӘМ-ӘНКӘМ НАЗЛАРЫ

Әткәм-әнкәм — күз нурларым,
Гомер бирүчеләрем,
Җаным әрнегән чакларда
Хәлгә керүчеләрем.

Аваз салгач та дөньяга,
Ак биләүгә төрдегез,
Кадерләп сез үстердегез,
Яшәргә көч бирдегез.
Әниемнең күкрәк сөте
Тәме телемдә калган,
Кысып-кысып сөюләре
Исемдә әле һаман.
Әтием гелән иркәләп
Башларымнан сыйпады.
Ярга сыймаган ташкындай,
Шатлык эчкә сыймады.
Әти-әнием булганга,
Бәхетле булып яшим.
Алар фатихасы белән
Уңа һәрвакыт эшем.

ДӨНЬЯ ТӨРЛЕЧӘ БУЛА

«Өч көнлек дөнья», — димәгез,
Дөнья төрлечә була.
Кемнекедер, бәлки, өч көн,
Кемнеке йөзгә тула.
«Өч көнлек дөньяга», — диеп,
Кул селтәмәң тормышка.
Дөнья көтү җиңел түгел,
Яшәү карый булмышка.
Хәрәкәттә бәрәкәт, ди,
Җитез, өлгер булыгыз.
Бисмилла әйтеп чыксагыз,
Уңар барыр юлыгыз.

Һәрбер эшнең үз җае бар,
Әгәр эшләсәң белеп,
Җиңел була дөнья көтү —
Яшә елмаеп-көлеп.

КАРТӘТИЕМ

Исемә төшә дә тора
Бәхетле бала чагым.
Кайтыр идем йөгерә-атлый
Әйләнеп шунда тагын.
Тарта да тора үзенә
Картәтием нигезе.
Ямьле җимеш бакчалары,
Уңышлы алтын көзе.
Истән чыкмый картәтием,
Изгедән-изге кешем.
Гүя ул мине иркәли —
Шул хакта күргән төшем.
Гүя кармак салабыз да,
Яр башына утырып,
Тотабыз эре балыклар,
Бер чиләкне тутырып.
Тик болар хәтердә генә,
Якты истәлек кенә.
Болар бар да онытылмаслык
Җырга эчтәлек кенә.
Бик тә уңган, эшчән иде
Кадерле картәтием.
Аның белән бик бәхетле
Яшәде картәнием.

КЕМГӘ – КОЯШ, КЕМГӘ – ЯҢГЫР...

Туктый белми ничәнче көн,
Яңгыр ява да ява.
Кояш әллә ялга киткән,
Тәмам бозылды һава.
Кояш нурларын сипмәсә,
Боега табигать тә.
Чәчкәнең бөбәкләре дә
Таҗларын җәйми хәтта.
Яңгырга сусаса гөлләр,
Үсемлекләр корыйлар,
Башкайларын җиргә иеп,
Ходайдан су сорыйлар.
Кем болыт тели, кем — аяз,
Киң офыкларга карап.
Кемгә — яңгыр, кемгә — кояш...
Булмый шул безгә ярап.
Яңгыры да, кояшы да
Кирәк шул исәннәргә.
Ходай уңай тормыш бирсен
Яшисе килгәннәргә.

САГЫШ

Әйләнәм дә кайтып киләм
Шул газиз авылыма.
Башка урын эзләп йөрмим
Көтеп алган ялыма.
Анда мине зарыгып көтә
Кадерлем, әни, җаным.

Ярдәм кылып йорт эчендә,
Шул җирдә үтә ялым.
Туган ягым шундый гүзәл,
Матур һәрбер почмагы.
Саф һавасы, табигате
Кемне генә кочмады.
Мактау сүзләрен авылга
Салам җыр юлларына.
Күз алдымда туган ягым,
Гел генә уйларымда.
Эшкә уңган халкым яши,
Оста җырга, биюгә.
Ялындырып та тормыйлар
Биюгә чык дию гә.
Сезгә кайту — үзе бәйрәм,
Туган җирем, авылым!
Көндез истә, төнлә төштә —
Авылымны сагындым.

БАЙЛЫК БЕР АЙЛЫК

Байлык — йөрәк өянәге,
Аңа юк бер дәва да.
Җыйган байлык кына түгел,
Байга җитми һава да.

Артык байлык — башка кайгы,
Байлыкка кызмыйк, дуслар.
Байлыгы юк — кайгысы юк,
Сайрашып яши кошлар.

Туганнар күп, дусларым күп,
Оч(ы)рашып торабыз.
Бәйрәмнәрдә, туган көндә
Бик мул табын корабыз.

Җырлыйбыз да, биибез дә,
Дөнья авыр, димибез.
Байлык артыннан кумыйбыз,
Маллар юк дип көймибез.

Туганнарым, дусларым да —
Алтынга тиң зур байлык.
Дуслар барда мал нәрсә ул?!
Байлык, диләр, бер айлык.

ҺӘРКЕМ БӘХЕТКӘ ЛАЕК

Бүген карлы яңгыр ява,
Күңелдә томан, сагыш.
Яктыртып җир йөзен килер
Күптән көткән ап-ак кыш.
Озакламас, тагын килер,
Бәхет алып, Яңа ел.
Һәркемгә дә бүләк итәр
Яңа тормыш, яңа юл.
Парлыларга — тиң мәхәббәт,
Ялгызлар табар парын.
Табышырлар, кавышырлар,
Һәркем сөяр үз ярын.
Яңа елга зур өметләр,
Ышанычлар баглаек.

Ак кар кебек ак күңелләр —
Һәркем бәхеткә лаек.
Каршыларбыз Яңа елны,
Сәгать унике суккач,
Күңелләр, бокаллар кебек,
Мөлдерәмәләп тулгач.

КАРДАЙ САФ СӨЮ КӨТӘ

Караңгы көз китеп бара,
Кар катыш яңгыр ява.
Караңгы көз календаре
Соңгы битләрен яба.
Ап-ак юрган җәяр җиргә
Күптән көткән кышыбыз.
Ак юрганнарга төренер
Мәхәббәт балкышыбыз.
Кардай саф сөюне саклап
Узарбыз шушы юлдан.
Гомер буе киләчәктә
Алмабыз кулны кулдан.

БАШКОРТСТАН ИЛЕМДӘ

Оҗмах бакчасы түгелме
Безнең башкорт илебез?!
Күкрәп ак чәчәкләр ата
Башкорт иле — гөлебез.
Башкорт иле — оҗмах иле,
Гуя кәүсәр елгасы.

Зәмзәм суын эчә-эчә
Үсә авыл баласы.
Кирәк икән — җиләген җый,
Урман тулы җимешләр.
Бакчада чия, алмалар,
Тәлгәш-тәлгәш миләшләр.
Шифа сулы зәңгәр күлләр
Башкортстан илемдә.
Шифа яңгырлар яуганга,
Күкрәп үсә иген дә.
Иркен сулап сулыш алам
Башкортстан илемдә.
Горур һәм бәхетле яшим
Шушы газиз җиремдә.

БИРЕШМӘДЕМ

Гафу итеп булса да ялгышны,
Үзгәртеп лә булмый язмышны.
Ничек кенә таратырга инде
Күңелемдә булган сагышны.

Очрап кына тора каршылыклар,
Әмма бирешмәскә тырышам.
Дөнья гизеп очып йөрим кебек,
Гүя кем беләндер ярышам.

Гөрләвекләр кебек агып китте
Гомеремнең гүзәл чаклары.
Яшьлегемне хәтерләтә бары
Туган җирнең матур яклары.

Узып бара гомер сизелмичә,
Үзгәртеп лә булмый язмышны.
Авырлыклар белән яшәлсә дә,
Үз итмәдем яман-ялгышны.

ТИҢЛЕГЕ СОКЛАНДЫРА

Минем әти кебек әйбәт
Булсын иде әтиләр.
Бер кайгысыз, гел рәхәттә
Яшәр иде әниләр.

Мәрхәмәтле, киң күңелле
Минем газиз әтием.
Шундый әйбәт булганга да,
Аны сөя әнием.

Тавышын күтәреп тә
Эндәшми беркайчан да.
Нинди әйбәт син, әти, дим,
Күзләренә багам да.

Тыныч күңелле әтием
Һәрберебезгә үрнәк.
Тырыш хезмәте белән ул
Эшендә китте үрләп.

Әтием — тормыш терәге,
Гаилә имиңлеге.
Әтиемнең әниемә,
Әниемнең әтиемә
Сокландыра тиңлеге.

КАЙСЫСЫ?

Адашып барып чыгасың,
Басасың ялгыш юлга.
Әллә инде шайтан әйди —
Каерыласың сулга.
Якты юллар күп ул җирдә,
Хагын сайларга ничек?
Туры юлга бер чыгасың,
Ялгыш юлларны кичеп.
Иртән торыйк, дога кылып,
Тик изге юллар теләп,
Күңелгә дәва булырлык
Матур теләкләр белән.
Әйләнеп басмасак иде
Ялгыш юлга кабаттан,
Изге догаларын юлның
Белергә кирәк яттан.
Туры юллар бик күп алар,
Иң турысы кайсысы?
Әйтче, Тәңрем, үтәр өчен
Кайсысы соң җайлысы?

ШУҢА ТУАДЫР ҖЫРЛАР

Авылыма багышлыймын
Җырымның иң матурын.
Тик туган авылда ямьле
Кебек яшәгән урын.
Хәтфә үләннәрдә уйнап
Үтте бала чагыбыз.

Яланнары белән күркәм
Безнең туган ягыбыз.
Сагындыра бала чагым,
Гүзәл авылым кочагы.
Исендәдер, кадерледер
Кемгә дә балачагы.
Вакыт җиткәч, җир өстендә
Карлар да эрер, ятмас.
Ничек кенә теләсәң дә,
Балачак кире кайтмас.
Яшел шәлле ак каеннар,
Алтын башаклы кырлар
Онытылмый, бик кадерле —
Шуңа туадыр җырлар.

ИЛЕМНЕҢ ХОЗУРЛЫГЫ

Урал итәгендә генә
Гүзәл җирләр, урманнар,
Җиләк-җимешле әрәмә,
Иркен басу-яланнар,
Шифа сулы елгалары,
Пар аккошлы күлләре —
Бу байлыклар барысы да
Уралның күркәмлеге.
Карагайлы карурманнар
Кайда бар, кайсы якта?
Уйланып тирән уйларга
Чумасың кайсы чакта.
Яшәгән һәм гел яшәсен

Уралым, гүзәл җирем.
Урал тавы биеклеге
Калган менәсе үрем.
Яңгырап тора Уралым –
Илемнең хозурлыгы.
Карагайлы карурманы –
Русиям горурлыгы.

КҮҢЕЛЕМ ТҮРЕНДӘ

Яшьлегемә кайткан сымак,
Кайтсам туган җиремә.
Басу-кырлар җәйрәп ята,
Күтәрелсәм үренә.
Гүзәл чагы яшьлегемнең
Үтте туган ягымда.
Изгеләрдән дә иң изге
Инәкәем янында.
Һәрчак күңелем түрендә
Дус-ишләр, яшьтәшләрем.
Гел дә хәтеремдә, уйда
Кадерле күршеләрем.
Сокланамын агышына,
Урасам чишмә буен.
Мәңге бакый эчсен суын
Бездән соң туган буын.
Яктырак яна йолдызлар
Авылымның күгендә.
Бар җиһанның уртасы ул,
Һәрвакыт күңелемдә.

ЯШӘП ТУЙГАННАРЫМ ЮК

Гөрләвек кебек йөгерә,
Үтә газиз гомерем.
Өстәлеп торса да яшем,
Япь-яшь кала күңелем.
Әле яшәп туйганым юк,
Алда бик күп өметләр.
Таза булып, бер туксанга
Булса икән җитепләр.
Күпме алдагы хыяллар
Ашар иде тормышка,
Әгәр дә килеп торсалар
Якты уйларым башка.
Теләгең гамәлгә ашса,
Бал-май бит ул җанга да.
Риза булып китәр идем
Мәңгелек дөньяга да.

СЫҢАР КАНАТ

Сыңар канат та кагына,
Очмаса да күкләргә.
Каян көч ала яшәргә,
Аңлашылмый күпләргә.
Ялгызмын дип тормыйбыз ла,
Аптырап юк-барга да.
Машина юк дип тә көймим,
Ярап тора арба да.
Утын да кисә алабыз,
Печәнен дә чабабыз.
Ничек булса да яшәргә

Болай җаен табабыз.
Кирәк булса кадагын да
Чәпәп кенә куябыз.
Эшләп бетерсәк зур эшне,
Чәйләр эчеп юабыз.
Шөкер, аптырап тормыйбыз,
Күңелләр көр гелән дә.
Югалмыйлар гүзәл затлар
Сыңар канат белән дә.

АЛЫШТЫРМЫЙМ АКЧАГА

Минем йортым бакчада,
Тирә-ягы — чәчкәдә.
Су сибәмен, түтәл утыйм,
Эшем бетми кичкә дә.
Шушы гүзәлеккә карап,
Үзем һәрчак сокланам.
«Әл дә әле бакчам бар», — дип,
Сабый кебек шатланам.
«Нәрсәгә сиңа ул бакча,
Өлкәнсең, ташла, — диләр, —
Җиңел, кулыңнан килердәй
Юкмы эш башка?» — диләр.
Кара җимешле миләшем,
Кып-кызыл баланнарым,
Алланып пешкән агачта
Йөзләгән алмаларым.
Чыгып басам, хозурланам
Шушы ямьле бакчага.
Ничек аны кызганмыйча
Алыштырыйм акчага?

АКЧА ҖЕНЕ

Ниләр генә кыландырмый акча:
Буйсындыра адәм баласын —
Киендерә дә ул, чишендерә дә,
Ялангач торып каласың.

Шул акчага кемдер сата җанын,
Булган аңын, рухын югалта.
Байлык колларына фанилыктан
Тәмугларга кадәр юл ята.

Ничек китәр байлыгын калдырып
Ахирәткә мәхлук бу җирдән.
Акча җене кагылса кешегә,
Бер дәва да юк, ди, бу чирдән.

СӨЕНЕП ЯШИМ

Яратам мин бар дөньяны,
Туып-үскән илемне,
Гел сөйләшеп аралашкан
Матур туган телемне.
Яратам мин туганнарны,
Изге якын дусларны.
Көтеп аламын сагынып
Язын кайткан кошларны.
Елмаеп күләм һәркемгә,
Кул бирәм өлкәннәргә.
Изгелек, ярдәм кыламын
Мохтаҗга төшкәннәргә.

Әлегә сөенеп яшим
Исән-имин булганга.
Назлы, нечкә күңелкәем
Мәхәббәткә тулганга.

СЕҢЛЕМ РУЗИЛӘГӘ

Үз гомереңдә бер була
Кабатланмас тантана.
Өстәл тулы сый-хөрмәтең,
Лампалар якты яна.
Илле биш яшь— күп яшь түгел,
Гомер уртасы гына,
Кала озын гомер теләп,
Бәхет юрыйсы гына.
Күңел җылың кояш кебек,
Һәркемгә сибә нурын.
Шуңа сиңа һәрвакытта
Табын түрендә урын.
Балаларың — кошчыкларың
Бәхетле юлда йөрсен,
Сөендереп сине көн дә,
Дөнья рәхәте күрсен.
Алда атлыйсы юлларың
Ак кар кебек ак булсын.
Күңелең куанычларга,
Якты шатлыкка тулсын.
Яшә тагын бер илле ел
Таза-сәламәт булып,
Сөйгәнең — хәләлең белән
Күңелең назга тулып.

КАДЕРЛЕ КЕШЕМ

Шәфкать тулы күңелкәең
Сүрелмәсен, сүнмәсен.
Шатлыкта үтсен гомерең,
Кайгы-хәсрәт күрмә син.
Чәчләрем дә инде ап-ак
Диеп борчылма һич тә.
Йөгереп йөргән яшьләрдән дә
Ким түгелсең син һич тә.
Ашыкма гомер көзенә,
Яшә син гел яз булып.
Кәефең берүк китмәсен,
Күңелең гөле сулып.
Яшә әле озак-озак,
Күңелең назга тулып.
Авыр чакта сөялергә
Безнең таяныч булып.
Кайтып керсәң, ишек ачык —
Шул мөһим минем өчен.
Колачың киң, йөзең ачык,
Минем кадерле кешем!

РОБЕРТ МИНЊУЛЛИНГА

Халык шагыйре исеме
Һәркемгә дә бирелми.
Буе җитмәгән йолдызга
Бар кеше дә үрелми.

Илешем бай талантларга,
Һәркемнең үз каләме.

Иҗатка карап бирелә
Хөрмәт, бүләк-әләме.

Чагыл тавы хәтле сәләт
Безнең Миннуллинда да.
Җырлары яңгырап тора
Бөтен якты дөньяга.

Ничә чакрым шигырь юлы
Китабына кергәндер.
Нишләп Ходай бу бер башка
Шундый акыл биргәндер.

Әллә Сөн суы шифасы
Бәлзәм булган җанына.
Инде күз генә тимәсен
Иҗатына, аңына.

Туганнарың һәм дусларың
Булсалар гел янында,
Күңелең шатлыкка тулып
Яшәрсең шул чагында.

Иҗатың ак чәчкә атсын
Яза алган чагында,
Уең, фикерең сүнмәсә,
Язылыр ул тагын да.

Ходай озын гомер бирсен,
Аек акыл, тазалык.
Әлегәчә, гомер буе
Данласын сине халык.

МАЯНЫ ҮЗЕБЕЗ САЛЫЙК!

Бу дөньяга зарланабыз,
Яшәве авыр, дибез.
Аны җиңеләйтер өчен
Ниләр эшләдек соң без?
Уңган кеше, тырыш кеше
Ташка кадак та кага.
Укырга да, бар эшкә дә
Өйрәнә бала-чага.
Буыннан-буынга күчә
Өлкәннәрнең һөнәре.
Алар шуңа нык булганнар:
Эшләп үткән көннәре.
Үз кулларың белән генә
Төзеп була дөньяны.
Күктән төшкәнне көтмичә,
Үзебез салыйк маяны.

ҖЫРЛАП ЯШӘДЕМ

Утырганым юк баш иеп,
Гомерем узды диеп.
Төшенкелеккә бирешмим,
Йөрәгем тузды диеп.
Хәрәкәттә бәрәкәт, ди,
Йөгереп кенә йөрим.
Кирәк икән — утын кисәм,
Кирәк икән — кар көрим.
Бер эштән дә курыккан юк,
Тазалык бирсен Ходай.

Күмәчем өстәлдә торсын,
Кырларда уңсын бодай.
Язмышны үзгәртеп булмас,
Ни диеп теләсәк тә.
Җырлап яшәдем гомергә,
Җырлармын киләчәктә!

БӘХЕТЕҢНЕ САКЛА!

Кеше өмет итә матур язмыш,
Хыялында гел зур мәхәббәт.
Күпме генә бәхет юрасаң да,
Яшәп булмый икән гел рәхәт.

Нинди якты уйлар син йөртсәң дә,
Ходай куя үз урынына.
Әгәр җибәрсә зур сынау сиңа,
Түзәсең кайгының авырына.

Язмыш белән көрәшеп тә булмый,
Йөгереп алга уза алмыйсың.
Күпме генә сакланып йөрсәң дә,
Күрәчәкне күрми калмыйсың.

Йөгереп эзләсәң дә бәхетне син,
Төшереп калдырмаган беркем дә.
Булган бәхетне дә, дускайларым,
Югалтырга була бер көндә.

Учка сыйган бәләкәй кошыңны
Очырмаска тырыш, нык сакла.
Риза булып яшә булганына,
Ходай үзе биргәнне сакла.

ХОЗУРЛЫК

Җир йөзебез шундый матур,
Матур итеп яшәсәң.
Бер мохтаҗсыз яшәп була,
Көч кызганмый эшләсәң.
Төнлә йөзә тулы аем,
Көндез — кояш нурлары.
Җирдә — аккош йөзгән күлләр,
Каен, чыршы урманы.
Сокланып туймаслык җирем,
Шөкер кылам дөньяга.
Матур хисләргә бирелеп,
Чыгып китәм далага.
Яшәрбез фани гомернең
Кадерен белеп кенә.
Иминлектә, тынычлыкта
Яшәсен илем генә.

ГАДИЛЕК НАЧАР БУРЛЫКТАН

Бигракләр дә беркатлымын инде,
Бар җитмәгән җирем — гадилек.
Кешеләр дә яхшы сүзне отмый,
Ялгыш сүзне алалар элеп.

Ни эшлисең, шундый «юләр» инде,
Шулай гади булып туганмын.
Йөргәнем юк кара янып юкка,
Ак кар белән битем юганмын.

Бурлыктан да начар — гадилек дип,
Дөрес әйтә урыс мәкале.
Сиздермимен, эчтән әрнеп-янып,
Кемгә кызык соң ул кем хәле?

Ышанамын белгән-белмәгәнгә,
Кайчагында күрәм каза да.
Мәкерле җан чакырганны көтми,
Килеп керә ишек кага да.

Үкенүдән, гарьләнүдән кайчак
Еласам да, күңелем тулып,
Ишетсәм — ишетми, күрсәм — күрмичә
Яшим шулай гел гади булып.

ДӨНЬЯ МАЛЫ КАЛАСЫ

Туганың бай булса — рәхәт:
Бирмәсә дә, сорамый.
Туганым баеды диеп,
Көнләшергә ярамый.
Дусың бай булса да — яхшы,
Көчен түгеп баеса.
Кайберәүләр байлык җыя
Хәрәм аша, югыйсә.
Хәләл җыйган байлык кына
Бәхет китерәдер, дим.
Әмма байлык җыялмадым
Хәләл көчем белән мин.
Шулай да күңелле яшим,
Исән-имин әлегә.
Туганнар да, дусларым да

Көреп тора хәлемә.
Дөнья маллары — байлыкмы,
Күңелең ярлы булса?
Минем өчен олы байлык —
Дусларым янда булса.
Оҗмахка мандат сатылмый,
Күпме ришвәт бирсәң дә.
Җаның тартыла җаванга,
Саф алтынга төрсәң дә.

ТАБИБӘ ЗИЛӘГӘ

Ак халатлы ак фәрештә —
Табибәбез Зиләбез.
Чирләп аяктан егылгач,
Гелән аңа киләбез.
Шифа булып тәэсир итә
Ап-ак йомшак куллары.
Тормышка ашсын хыялы,
Уңсын берүк юллары.
Әл дә, Зиләм, сөяләргә
Синең иңсәң бар әле.
Авырулар төрле була,
Ярый син сабыр әле.
Күңелең киң һәммәбезгә,
Һәркемгә игътибарлы.
Үзеннән зурмы, кечеме —
Һәркемгә ихтирамлы.
Бер елмаеп каравың да
Эретә йөрәк маен.
Сокланып калабыз һәрчак,
Син үтеп киткән саен.

Бар яклап та син килгәнсең —
Берүк күзләр тимәсен.
Шултиклем гүзәл ханымны
Кем генә соң сөймәсен?
Изге җаныңа лаектыр
Бөтен язылган сүзләр.
Сиңа ярдәм көтеп карый
Ничәмә мохтаҗ күзләр.
Барыбыз да рәхмәтлебез,
Телибез зур уңышлар.
Кайгы күрмәсен башкаең,
Урап үтсен сагышлар!

ӘНКӘЙ ЯНЫНДА

Ел саен авылда үтә
Хаклы ялларым җәен.
Каршы ала әнкәй мине,
Елмаеп, колач җәеп.
Ашкынып кайтам бит инде
Газиз әнкәй янына.
Мин аны сагынган кебек,
Ул да мине сагына.
Өйгә кайтып керүемә,
Ипие чыккан мичтән.
Кай арада җитешкәндер —
Изеп куйгандыр кичтән.
Ясап бирә, сөтләр салып,
Мәтрүшкәле тәмле чәен.
Йөрәген бирергә әзер
Изге һәм юмарт әнкәем.

Токмачын, җәймәсен җәеп,
Нәп-нәзек итеп кисеп,
Пешереп тә куя ашын,
Минем кайтасым сизеп.
Ул мине яраткан кебек,
Мин дә аны яратам.
Кайтсам, серләремне сөйләп,
Хисләремне таратам.

СЕҢЛЕМӘ

Кошлар бала чыгарырга
Мамык ташый ояга.
Яз көннәрен ямьләндереп
Син тугансың дөньяга.
Алмагач чәчәге кебек
Матурсың син, туганым.
Өй түрендә сиңа урын,
Иң кадерле кунагым.
Йөрәгемә шифа була,
Бер елмаеп карасаң,
«Туган апам, тазалыгың
Ничек?» — диеп сорасаң.
Язгы гөрләвекләр кебек,
Йөгереп кенә атлыйсың.
Бетәсе түгел эшләрең,
Ял да итеп алмыйсың.
Йөгергәндә йөгереп кал,
Хәрәкәттә бәрәкәт.
Килер гомер юлларында
Очрамасын гарасат.

Алда — иң матур елларың,
Көймә, олыгаям дип.
Үтеп киткән яшьлегемне
Эзләп табыйм каян дип.
Тормышны сөеп яшисең,
Шуңа һич картаймыйсың.
Көзен яфрак саргайса да,
Син, шөкер, саргаймыйсың.
Шулай матур, гел яшь булып
Яшә, сеңлем, сөеклем,
Таза, шат күңелле булып,
Йөз егермегә тиклем.

НӘНӘЕМӘ

Нәнәй булгач, күңелле:
Өй эчебез гөл генә.
Без кайтуга тәмле ашлар
Әзерли ул гел генә.
Нәнәемнең безгә булган
Изгелекләре чиксез.
Ул булгачтын, күңел тыныч,
Ишегебез дә биксез.
Тапкыр сүзле, көләч йөзле
Минем газиз нәнәем.
Мин дә аңа озын гомер,
Зур тазалык телимен.
«Иртәң бәхет өләшәләр, —
Ди көн саен нәнәем, —
Таңнан торып, бәхет телә,
Йоклап ятма, бәбәем!

Елына бер генә тапкыр
Күк капусы ачыла.
Тирә-якка нурын сибә,
Аннан бәхет агыла».
Файдалы киңәшләр бирә,
Югалып калган чакта.
Гел яхшы фикердә генә
Нәнәем безнең хакта.
Рәнҗетмәскә тырышабыз
Без дә нәнәебезне.
Минем газизләрем, диеп
Сөя нәнәем безне.

ШӨКЕРАНА КЫЛАМ

Таныклыкта ничә яшьтер,
Санап караганым юк.
Дөресен генә әйткәндә,
Яшем барлаганым юк.
Күңелем гел язлар кебек:
Чәчкә ата, җәй җиткәч.
Кырда чәчәк саргайса да,
Мин саргаймыйм, көз җиткәч.
Аллага шөкер, яшимен,
Тик изгелек уемда.
Якты хисләргә бирелеп
Йөрим урман буенда.
Игелекле гамәлләрем —
Рухи ризык күңелгә.
Шөкерана кылып яшим
Ходай биргән гомергә.

РӘХМӘТ, АВЫЛДАШЛАР!

Күптән киттем синнән, туган ягым,
Чит җирләрдә бик озак тордым.
Зур шәһәргә ияләшеп китеп,
Үземә күрә оя да кордым.

Зур калага ияләшсәм дә мин,
Онытмадым туган авылымны,
Ачык йөзле, киң күңелле, сабыр,
Чиксез тырыш, эшчән халкымны.

Зур рәхмәт сезгә, авылдашлар,
Дус-ишләрем, якын туганнар.
Күптән китсәм дә мин авылымнан,
Үз күрепләр каршы алалар.

ЯКЛАГЫЗ ТЫНЫЧЛЫКНЫ!

И кешеләр, сезгә дәшәм,
Нинди мал бүлешәсез?
Кеше гомере өзелә ләса,
Аңламыйсыз нигә шуны сез?

Ирешәм диеп олы бәхеткә,
Утырырга биек тәхеткә,
Гомерләрне сез юк итәсез,
Салясыз бит тирән ләхеткә.

Әфәнделәр, яле уйлапыгыз,
Кемгә сугыш бәхет китерде?

Бөек Ватан сугышы гына да
Күпме кешеләрне үтерде?

Изге ана биргән газиз жанны,
Кемнең хокукы бар алырга?
Күз нурыдай сөекле баласын
Тырыша ул саклап калырга.

И түрәләр, акылыгыз кайда,
Ни уйлый соң сезнең башыгыз?
Тынычлыкны яклап, тәүге башлап,
Кулын сузар икән кайсыгыз?

ТАШЛАМАГЫЗ ТУГАН ЯКНЫ

Илешемдә туып үскәнмен мин —
Илешемнең газиз баласы.
Бик еракка китми, булган да бит
Анда гына торып каласы.

Бөтен горурлыгым — син, Илешем,
Күңелемнең иң якты хисе.
Әле дә тоям — күкрәккәем тулы —
Йомшак искән таң жиле исен.

Яшел шәл ябынып, каеннары
Илешемне бизәп торалар.
Гүя сөенеп каршы алалар да,
Киткәндә, моңаеп калалар.

Илешемне сагынып, мин дә жырлыйм,
Юктыр искә алмаган көнем.

Гүзәл туган яккаемны уйлап,
Саташыплар үтә лә төнем.

Дәрт-дәрманым сүнә — сизәм үзем,
Еллар үтә, якыная көзем.
Туган якларны ташлап китмәгез —
Шушы сезгә әйтәсе сүзем.

КОРЪӘН ДӘРЕСЕН ҮТСӘҢ

Мөхәммәт Рәсүл Аллаһ дип
Өч тапкыр әгәр әйтсәң,
Зур бәхеткә ирешерсең,
Коръән дәресен үтсәң.
Кем зурлый белә Аллаһны —
Аның бик изге җаны.
Кем күтәрә Ислам динен,
Илаһым зурлар аны.

ЧӘЧӘК ГОМЕРЕ БЕЗДӘ

Күпме оста шагыйрьләрнең
Дөнья күрә шигыре.
Оста язылган шигырьнең
Озын була гомере.
Кабер өстендәге ташлар
Җуелырлар берзаман.
Шагыйрь сүзе һәйкәл булып
Тора бирер ул һаман.
Җырлар мәңге онытылмас,
Онытылса да җырчылар.

Җыр гомере шуңа озын:
Җырлый халык, юлчылар.
Кояш җылысы мәңгелек,
Чәчәк бит сула көзгә.
Җырлар яшәр, без китәрбез,
Җырлар калдырып сезгә.

СӨЯ БЕЛГӘН БӘХЕТЛЕ

Кешегә күп тә кирәкми
Бәхетле булыр өчен.
«Мин сине яратам», — дисәң,
Бәхетле мин бу кичен.
«Мин сине яратам», — дисәм,
Бәхетле эни бүген.
Шушы сүзләр аңа дәва,
Яктыртa күңел күген.
Бәхет кешене эзләми,
Кеше эзли бәхетне.
Кем чынлап ярата белә —
Тик шул гына бәхетле.

ЧҮП-ЧАР ҺӘМ АСЫЛТАШЛАР

Чүп-чарлар суда батмыйлар,
Чыгалар өскә йөзеп.
Дулкыннар ташып ярыннан
Чыгарып ташлый сөзеп.
Чүпне җыеп бер урынга,
Ут төртеп яндыралар,
Йә, чүп чокырына түгеп,

Черергә калдыралар.
Асылташлар һәм энҗеләр
Диңгез төбендә ята.
Саклагыз, суга салмагыз:
Суда ташлар тиз бата.
Суга салсаң да, батса да,
Янмый ул, яндырсаң да.
Асылташлар мәңгелек ул,
Сынмыйлар, сындырсаң да.
Асылташлар су астында
Ятмасыннар билгесез.
Су астында булсалар да,
Чүп-чарларга биргесез.

КАРА ҖИРЕМ

Кара җирем — ярма туфрак,
Бик кадерле син миңа.
Тереклегемне саклыйсың —
Бурычлымын мин сиңа.
Син миңа кадерле икмәк,
Татлы җиләк-җимешем,
Бетмәс-төкәнмәс байлыгым,
Күмер, алтын, көмешем.
Булмас иде тереклек тә,
Мин шуны яхшы беләм.
Рәхмәт әйтәм Илаһыма,
Дога кыламын гелән.
Нык итеп басам җиремә,
Өстендә яшел үләм.
Үлгәндә дә, кочып ятып,
Җирем, өстеңдә үләм.

КӨЗГЕ КҮҢЕЛ

Караңгы көз төне — күңел китек,
Йөрәгемне сагыш биләгән.
Бәхет көтеп инде ничә еллар,
Ялгыз яшәп җаным җиләгән.

Агачыннан өзелеп яфраклар да
Җил-яңгырдан җиргә коела.
Агач белән яфрак язмышлары
Минем язмыш кебек тоела.

Җилләр очырсын ла яфракларны,
Бәхетне тик алып китмәсен.
Сабышсам да сары сагышларга,
Өметемнән мәхрүм итмәсен.

НИЧЕК ОНЫТАСЫҢ?

Өзгәләнәм сине сагынып,
Илешем, туган җирем.
Туган авылымда яши
Әнием-бердәнберем.
Сөйләп бетәрлекләр түгел
Йөрәгемнең сагышын,
Сихри төнне моңга салган
Чишмә суы агышын.
Ничек онытасың инде
Авылымның кичләрен?
Җаныемның күз карашын,
Миңа булган хисләрен?!

Ничек онытасың инде
Туган йортның учагын,
Күкрәгенә кысып сөйгән
Әнкәемнең кочагын?

ГОМЕР ИТТЕК ПАРЛАШЫП

Әби һәм бабай, парлашып,
Бер-берсенә карашып,
Яшь вакытны искә алып,
Чәй эчәләр сайрашып.
— Матур иде елмаюың,
Тигез энҗе тешләрең.
Йөри идем көне буе
Күтеп айлы кичләрне.
— Куе-кара чәчләрең,
Бөркеттәй карашларың,
Ерактан күреп үзеңне,
Китә иде һушларым.
— Сине минем гел генә
Килә иде күрәсем.
Чәчләреңә гөл-чәчәкләр
Килә иде үрәсем.
— Туймый идек яшь чагында
Бер-беребезгә карашып.
Сокланып калалар иде,
Узып китсәк парлашып.
— Гомер буе гыйшык уты
Сүнмәде, сүрелмәде.
Саф сөюле күңелебез
Башкага үрелмәде.

— Шуның өчен безнең картлык
Чиксез бәхетле бүген.
Җитәкләшеп гомер иттек,
Тарттык дөньяның йөген.

ТАБИГАТЬ ЮМАРТ

Җәйнең бер көне елны туйдыра —
Аны әйткәннәр ата-бабалар.
Тырыш хуҗалар хәстәр күрәләр,
Яшәү имәнең җаен табалар.
Кочагын җәеп безне каршылый
Табигатебез җәй айларында.
Мул үсә җимеш урманнарда,
Кызыл җиләкләр аланнарында.
Табигать юмарт, иренмә генә,
Җый хәзинәсен, тулсын келәтләр.
Бер мохтаҗлык та күрмәссең кышын,
Ходайга әйтик зур-зур рәхмәтләр.

ИЛКӘЕМ ӨЧЕН

Туганмын икән яшәргә диеп
Туган ил өчен, җир өчен янып —
Барырга көч бир, Ходай Тәгаләм,
Авыр дөньяның ярып юлларын.

Газиз халкымны, илне сөюем
Кыйммәтрәк лә миңа алтыннан.
Ләгънәт-каргышлар, юк-бар нахак сүз
Иярмәсеннәр, берүк, артымнан.

Илкәем өчен җаным җәл түгел,
Утларга кереп, суга төшсәм дә.
Көн итү түгел, илкәем өчен
Таулар күчереп, ташлар киссәм дә.

ИЛҺАМЫМ – ТУГАН ҖИРДӘН

Илешемдә туып үстем,
Базы суларын эчтем.
Язмыш юлымны борды да
Миңзештесенә күчтем.
Кайсы суны эчсәм дә мин,
Ул бары – Илешнеке.
Кайсы җирдә мин үссәм дә,
Барыбер Илешнеке.
Анда үткән балачагым
Яши һаман йөрәктә.
Туып-үскән Илешемдә
Кадерле бит тирәк тә.
Җырлап үстем Илешемдә,
Күңелем тулы моң-җыр.
Илһам бирде яшәешкә
Туып-үскән газиз җир.

КЫЗЫҢ КӨТӘ ҺАМАН

«Әти» диеп, бер стакан чәй дә
Ясап эчермәдем беркемгә.
Карар идем туйганчы йөзеңә,
Кайтсаң иде бер генә көнгә!

Ник соң сугыш чыккан мин туганчы,
Ник кытмәгән минем үскәнне?
Йөрәктәге сызланулар аша
Төшерәмен искә үткәнне.
«Әттә» диеп телем ачылмаган,
Сөймәгән ул алып кулына.
Нәнәем дә әллә озын гомер
Теләмәгән микән улына?
Кабереӊ дә ерак туган яктан,
Чәчәк салыр идем өстенә.
Шушы сагыш гомеремә житте,
Башка кайгы, Тәңрем, өстәмә.
Көтеп алалмады әнкәем дә,
Көтеп алалмады Этәсң.
Гомер буе зарыгып бер күрергә
Һаман көтә кызың, әткәем...

ИЛЕШ ҖИРЕ ҖИМЕШЛЕ

Чагыл тавына мендем дә
Күз салдым тирә-якка.
Илеш җире кебек гүзәл
Түгелдер, дим, бер як та.
Санадым күпме авыллар
Офыкларга җиткәнче.
Арып беттем атлый-атлый
Урман буйлап үткәнче.
Кочам дисәм Илешемне,
Җитмәде кочакларым.
Бер исемнән чыкканы юк
Анда үскән чакларым,

Базы буе, ага суы,
Бөтен Илешне буйлап.
Сагышларга сабышамдыр,
Шул туган якны уйлап.
Юкка гына җырламыйлар
Җырга кушып Илешне.
Ишелеп үсә игеннәре,
Илеш җире җимешле.

КАБЕРЛӘРЕ КАЙДА ӘТИЛӘРНЕҢ?

Сугыш кырларында ятып калган
Әтиләрнең каберләре кайда?
Яшь нәратлар кебек мәңге яшь-яшь
Корбан булып ятып калды яуда.

Сезне көттеләр, һаман көтәләр —
Әле дә ялгыз безнең әниләр.
Сезне озаткан яшь-яшь сылулар
Хәзерге көндә сылу әбиләр.

Аз булмагандыр сагыш-әрнүләр,
Сагынулардан алар саргайды.
Күпләре инде гүр куенында,
Ә исәннәре бик нык картайды.

Бар дөнья халкы, бөтен ил беләң
Башлар иябез сезгә, яугирләр.
Туган илләрдән, ерак чит җирдә
Ятып калдылар пәһлеван ирләр.

ТУКАЙ ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘМ

Тукаемның телендә мин
Рәхәтләнеп сөйләшәм.
Шигырьләрен укыймын да
Чынлап торып көнләшәм.
Көнләшмәс идем дә, бәлки,
Мин дә шулай язалсам.
Китапларга язар өчен
Матур сүзләр табалсам.
Күпме уйлар, күпме фикер
Тупланган иҗатында.
Нинди мәдхияләр языйм
Бу бөек зат хакында?
Тукайлар бит көн дә тумый,
Туалар йөз елга бер.
Галимнәр ачыкламаган —
Әлегә ул безгә сер.

ӨЙРӘНЕГЕЗ ЭШЛӘРГӘ

Картайсак та, китмик әле,
Яшик тагын бер йөзне.
Дөньяга да бик кирәкбез,
Көтмәсен дә җир безне.
Теркәлдибез көне буе,
Көч житкәнчә эшлибез.
Башны да иеп йөрмибез,
Әлегә бирешмибез.
Үстерәбез яшелчәләр,
Төрле җиләк-җимешләр.

Китәргә вакыт юк әле,
Бетмәде һич тә эшләр.
Курыкмадык бер эштән дә,
Түздек авырлыкларга.
Эш яратмаган яшьләрне
Ничек авызлыкларга?
Үрнәк алыгыз зурлардан,
Өйрәнегез эшләргә.
Җиң сызганып эшләсәгез,
Җиңел булыр яшәргә.

КҮҢЕЛ ҖЫЛЫҢНЫ БҮЛ

Беркемгә дә кирәге юк —
Берәү ята урамда.
Җәнлек килеп иснәр иде,
Әгәр ятса урманда.
Исерек диеп көләләр,
Якын килми бер кеше.
Урап уза йөзен чытып,
Һичберенең юк эше.
Кайда бездә шәфкатьлелек,
Кайда бездә игътибар?
Миһербанлык хисе кайда,
Әллә йөрәк — салкын кар?
Күңел җылың бүл мескенгә,
Битараф калмаң, зинһар!
Иртәгәсен шул урында
Кемнең дә ятуы бар!

ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА

Гомеркәең булса, язган шигырьләрең
Сыяр идеме соң китапханәләргә?
Безгә күпме рухи азык калыр иде,
Юлыкмаган булсаң чир-бәлаләргә.

Туңмас идең өй алдында яланаяк,
Туган булсаң әгәр син йөз елга соңрак.
Кибетләрдә киштәләр сыгылып тора,
Акчаң булса — сат та ал син алтын тарак.

Юлыкмаган булсаң әгәр каһәр чиргә,
Зур рухи мирас калдырыр идең җиргә.
Эш дисеңме, якты дөньяны калдырып,
Җир астына керен яту яшь-яшь иргә.

МӘҢГЕ ЯШЬ БУЛЫП КАЛДЫҢ

Шулай мәңге яшь калырга
Уйладыңмы, әткәем?
Сине зарыгып көтә торгач,
Картайды бит бәбкәең.
Көтсәм дә күңелем белән,
Кайтмасыңны мин белдем.
Бары бер төшемдә күрдем:
Минем яныма килдең.
Бер-беребезне белмәгәнгә,
Эндәшмәдек бер сүз дә,
Ләкин якынлык чаткысы
Чагылды безнең күздә.

Яшәсәң соң картайганчы,
Исән булып әле дә,
Каршы алып Җиңү көнен
Язның чәчкә мәлендә.
Горур атлап барыр идең
Җиңү бәйрәменә син,
Күтәр идем табын корып
Синең кайтуыңны мин.
Илем белән баш иябез
Җиңүче яугирләргә.
Озын гомер һәм тазалык
Батыр, гаярь ирләргә.

БЕЗ ДИҢГЕЗНЕ ГИЗӘРЛЕК

Типсәк тимер өзәрлекләр
Идек без заманында.
Җиңелмәдек көрәшләрдә
Сабантуй мәйданында.
Сөюнең кадерен белдек,
Күзләр тулы наз иде.
Кышкы салкыннар җитсә дә,
Күңел тулы яз иде.
Сөйләсәң, сөйләмәсәң дә,
Яшьлек үзе — гүзәллек.
Әле дә без бирешмибез,
Диңгезләрне гизәрлек.
Ашыкмыйк гомер көзенә,
Тормыш үзе — гүзәллек.
Күңел яшь кала бит әле,
Калганына түзәрлек.

ҖЫРЛАРЫМ АША ЯКЫН КҮПЛӘРГӘ

Мин бәхетсез түгел бу дөньяда,
Җырлап та гөрләп үтә гомерем.
Янәшә атлый тормыш юлымда
Өзелеп сөйгән берләрдәнберем.

Сикәлтәләр юлда очрап тора —
Дөньясы кызык шуның белән дә.
Төрле чаклар була, дөнья булгач:
Кайчакта елыйм, кайчак көләм дә.

Канат куялар җырларым миңа:
Талпынам, очам, менәм күкләргә.
Тагын да шуңа бәхетлемендер:
Җырларым аша якын күпләргә.

Ходайга шөкер кылып яшимен,
Бар булмышыма һәм тормышыма.
Җырларым белән юанып яшим,
Канәгать булып үз язмышыма.

ӘНКӘЕМ ШОМЫРТЫ

Әнкәем утырткан иде
Шомырт агачын күптән.
Сизми калдым — агач үскән,
Инде ничә ел үткән.
Әнкәем дә китеп барды
Мәңгелек дөньясына,
Калдырып ялгыз шомыртын
Берләнбер баласына.
Бакчада шомырт агачым

Бер ялгызы тибрәлә.
Күршеләр дә китеп барды —
Беркемем юк тирәдә.
Тәлгәш-тәлгәш җимешләрен
Кем генә өзәр икән,
Ятлар сындырса ботагын,
Ничекләр түзәр икән?
Мин дә ерак яшим синнән,
Кайта алмыйм гел генә.
Миннән саг(ы)ну сәламнәрен
Сиңа әйтер җил генә.

МОГҖИЗАЛАР ӘКИЯТТӘ

Дөнья көтү бер дә җиңел түгел,
Төрле чаклар була тормышта.
Могҗизалар әкияттә генә,
Тырышу да кирәк булмышта.

Уңыш миңа бик җиңел килмәде,
Күпме эзләнүләр аркылы.
Күпме газап, әрнү кичергәндер
Күңелемнең нечкә һәр кылы.

Үз кулларым белән барын төзим,
Яратам мин эшем пешкәнне.
Ярты юлда туктап калганым юк,
Көтеп тормыйм күктән төшкәнне.

Мин тырышып яшим гомер буе,
Эзләп йөрмим төшеп калганны.
Гел таянып яшим үз көчемә,
Өмет итмим бушка алганны.

ШӘФКАТЬ ТУТАШЫНА

Ак халатлы, ак күңелле
Изге шәфкать туташы.
Сиңа һәммәбез табына
Син — безнең йөзек кашы.
Синең матур елмаюың,
Күз карашың ягымлы.
Җылы сүзең үзе шифа,
Шундый да син акыллы.
Син — ак халатлы фәрештә,
Уңгансың син һәр эштә.
Йөрәгемә дәва була,
Күрсәм дә сине төштә.
Котлыйм зур бәйрәмең белән,
Тазалык, шатлык теләп.
Күңелдәге теләкләрне
Бетәрлек түгел сөйләп.

ДӨНЬЯ ЯМЬЛЕ, ДӨНЬЯ МАТУР

Дөнья ямьле, чиксез, иркен,
Мин тормышны яратам.
Киң далага чыгып җырлыйм,
Сагышымны таратам.
Дөнья ямьле урман, кырлар,
Күлләр, елгалар белән.
Ямьле зур бәйрәмнәр, туйлар,
Матур йолалар белән.
Дөнья матур әти-әни,
Дуслар, туганнар белән.
Тормыш төзек, балкып тора

Эшчән, уңганнар белән.
Суларга саф һавасы бар,
Кояшы бар, ае бар.
Күңелең салып эшләсәң,
Һәммә эшнең җае бар.
Тагын да күңелле дөнья:
Мәхәббәт бар, сөю бар,
Яратышып өйләнешү,
Нәсел өчен туу бар!
Шулай тормыш кабатлана:
Кем туа, кемдер китә.
Кочакка сыймый Җир шары,
Дөнья һәркемгә җитә.

ӘНИЕМ, КАДЕРЛЕМ!

Сагындыра әниемнең
Озатып калулары.
Сагындыра, балам, кайт дип,
Хат язып салулары.
Офыкларда калды әнкәм,
Озатып, кулын болгап.
Өзелә гел бәгырьләрем,
Газиз әнкәмне уйлап.
Сагындыра шелтәсе дә,
Яшәргә өйрәтүе.
Югалып калган чагымда
Киңәш белән дәшүе.
Рәхмәт сиңа барсы өчен,
Әнкәем, бәгырькәем.
Шатлыкта, рәхәттә үтсен
Тик калган гомеркәең.

СИЗМИ КАЛДЫМ

Очып китте кошлар, сизми калдым
Инде көзнең килеп җиткәнен.
Мәшәкатьләр белән күрми калдым
Кояшлы җәй үтеп киткәнен.

Кояш белән бергә торам көн дә,
Кояш белән йокларга ятам.
Кышны туйдыра җәйнең бер көне –
Шуңа таңнан эшкә мин батам.

Эш ул миңа сабан туе гына,
Ходай тәнгә тазалык бирсен.
Якты тормыш, озын гомеремдә
Эш дигән бәхетемә төрсен.

Кулларымда әле көчем барда
Заяга үтмәсен гомерем.
Кара тирем түгеп эшләгәнгә,
Уңышны да мул бирә җирем.

БЕЗ ӘЛЕ ӘБИ ТҮГЕЛ

Артта калганнардан түгел,
Бик алдан чапмасак та.
Акылсызлардан да түгел,
Бик акыл сатмасак та.
Ким-хур булып яшәмәдек,
Бик чибәр булмасак та.
Гомер көзе генә җитә,
Гөл кебек сулмасак та.

Яшьлегебез гүзәл чакта
Җырлап, биеп яшәдек,
Бәйрәмнәрне бәйрәм иттек,
Җиң сызганып эшләдек.
Әл(е) дә әле күңелебез
Уналты, унсигездә.
Без әле әби түгелбез,
«Әбекәй» дисәгез дә.

ӘНКӘЕМ – САГЫШЫМ

Төзәлми йөрәк ярасы,
Айлар, еллар үтсә дә.
Сагыш-әрнүләр дә китми,
Әнкәй, күптән китсәң дә.
Төшемә дә еш керәсең,
Чыкмыйсың бер дә уйдан.
Кабереңә дә кайтырга
Төшми гел генә юл да.
Үзем дә бит өлкән яшьтә,
Тазалык та чамалы.
Шуа түбән, тотып булмый
«Гомер» дигән чапаны.
Ярый, газизем, ятасың
Туган җир кочагында.
Ятасың туган җиреңдә,
Киң ялан ачыгында.
Йөрәк ярасы төзәлмәс,
Яшем белән юсам да.
Нишлисең, түзәргә кала,
Өзелеп сагынсам да?!

УЕМ БЕЛӘН

Уем белән балачакка
Кабат әйләнеп кайтам.
Иркәләнеп таң чыгында
Хәтфә чирәмдә ятам.
Күзәтәм бар тирә-якны,
Могҗиза — тирә-ягым.
Кайларда калдың адашып,
И гүзәл балачагым?
Искә төшә әнкәемнең
Иркәләп сөюләре,
«Син бит минем берләнберем,
Бәхетем», — диюләре.
Ярый әле төшләремә
Кереп торасың гел дә.
Балачак, китмәдем читкә,
Яшимен синең илдә.

МИН ҮЗЕМ ИЛЕШ МАЛАЕ

Мин үзем Илеш малае —
Илештә туып-үстем.
Хуш исле ипиен ашап,
Татлы суларын эчтем.
Ташлап гүзәл Илешемне,
Юл тоттым зур шәһәргә.
Хәзер сагышта көеләм:
Белмим, ничек яшәргә?
Кошлар моңы йөрәгемдә
Мәңгелек урын алды.

Җәйге урман күцелемдә
Моңлы җыр булып калды.
Тормыш күрсәтә үз юлын,
Буйсынабыз язмышка.
Кайда гына яшәсәк тә,
Гомер үтмәсен бушка.
Авылыма кайтырмын мин,
Тик исән булсын башым.
Анда бит газиз әнкәем,
Анда бит нигез ташым.
Шатланып яшәргә язсын,
Җырга-моңга күмелеп.
Дөнья бит ул бер могҗиза,
Яшәсәң кал(е)рең белеп.

ЯШИК ХОДАЙ КУШКАНЧА

Дөнья булгач, булмый, диләр,
Ялгышмый гына яшәп.
Кайчак каты утырталар,
Мамык түшәкне түшәп.
Ялгышны кире кайтарып,
Бернәрсә булмый эшләп.
Калырга кирәктер дәшми,
Кайчак телеңне тешләп.
Күрәчәкне, киләчәкне
Булмый шул алдан күреп.
Адаштырма безне юлдан,
Ходай Тәгаләм, берүк!
Ярамый, Ходай кушмаган
Кеше йөзен ертырга.

Кысклап төзәгән булып,
Кинәт туры атарга.
Мәкерле җан һөҗүм итсә,
Алдан кора хәйләнс.
Якла, сакла хәрәм эштән,
И Ходаем, бәндәне.
Туры сүз туганга ятмый,
Булмый һәркемгә ярап.
Уйламыйча әйткән сүзнең
Кайтавазы да харап.

ҖЫРЫМ – ГОМЕРЕМ

Нишлим инде, җырсыз яши алмыйм,
Җырлар – минем бөтен гомерем.
Җырларымда минем сөйгән халкым,
Туган авыл һәм туган җирем.

Шатлык килсә, җырлыйм шатлык җырын,
Кайчагында өзеләм сагыштан.
Шушы моңнар мине юаталар
Башка төшкән ачы язмыштан.

Йөрәгемне ярып керә моңнар,
Дулкынланам ташкын су кебек.
Күңелемнән ургылып агылган
Җыр-моң чишмәм бетмәсен кибеп.

Җыр-моңнарым – күңел юанычым,
Яши алмыйм җырсыз бер көн дә.
Тормышымны яктырталар алар,
Йолдыз булып караңгы төндә.

Йөрәгемә ярып керә моңнар,
Урын ала күңел күгендә.
Отып алам, ләззәтләнеп җырлыйм,
Ташкын булып җырым түгелә.

АЧАБЫЗ ТӘҮГЕ БИТЕН

Гаилә кору, никах белән
Котлыйбыз, яшьләр, сезне.
Рәхмәт инде, искә алып
Чакырган өчен безне.
Сезнең гаилә тарихының
Ачабыз тәүге битен.
Ак битләргә ни язылыр?
Алдан әйтүе читен.
Әмма безнең күңелләрдә
Изге теләкләр генә.
Шаярып әйткән сүзгә дә,
Берүк, тотмагыз кенә.
Табыштыгыз, кавыштыгыз,
Сез икегез — бербөтен.
Якты күңел күгегезне
Каплый күрмәсен төтен.
Икегез дә бигрәк матур,
Карап туймаслык парсыз.
Үпкәләшеп юк-бар сүзгә,
Кала күрмәгез ярсыз.
Бүген биибез, җырлыйбыз,
Мәшәкать бетеп торсын.
Ходай сезгә зәңгәр күктән
Бәхетләр сибеп торсын.

Сөеп-сөелеп яшәгез,
Гомер тик бер бирелә.
Мәхәббәт уты сүнмәсен
Йөрәгегез түрендә.

БӘХЕТЕҢНЕ ЮГАЛТМА

Бәхтлеләр бәхетсезлек
Эзләп чаба кайчакта.
Бәхтләрен югалталар
Булган чакта кочакта.
Сөяркәләр назлы була,
Кемнең башы әйләнмәс?!
Юмарт, купшы чыпчыкка соң
Кемнең жаны бәйләнмәс.
Йөри ул синең кырыңда
Күңеле сүрелгәнче.
Куык кебек буш күңеле
Башкага үрелгәнче.
Бәхетле тормышыңны син
Алыштырсаң ялганга,
Үпкәлә үзеңә генә
Башың ялгыз калганга.

НӘНӘЕМНЕҢ МИРАСЫ

Нәнәемнән калды мирас — дисбе,
Элеп куйдым өйнең түренә.
Дисбесенең һәр тезгән төймәсе
Оҗмах ташы булып күренә.

Дисбесенең һәрбер төймәсендә
Нәнәемнең бармак эзләре.
Ягымлы елмаеп һаман да
Карый кебек назлы күзләре.

Шул күзләрем карасыдай дисбене
Саклыйм нәнәем төсе итеп.
Шул дисбене тотып дога кылам,
Булган чакта күңелем китек.

Күпне күргән шушы изге дисбем —
Иң кадерле, кыйммәт зиннәтем.
Теләгем шул изге нәнәемә:
Ходай насыйп итсен җәннәтен.

ИКЕ ФӘРЕШТӘМ

Иңемдә ике фәрештәм:
Әткәем һәм әнкәем,
Яшәсеннәр алар озак,
Шул иң зур теләккәем.
Икесе дә иң кадерле,
Иң изге кешеләрем.
Алар фатихасы белән
Уңай бара эшләрем.
Ярый әле, якыннарым,
Сау-сәламәт, исәнсез,
Гомер биреп үстердегез,
Рәхмәтләрем исәпсез.
Минем өчен сез кадерле,
Иң бөек сез дөньяда.
Яшәгез шатлыкта гына
Бергә корган ояда.

ТЕЛИМ БӘХЕТЛӘР

Дулкынын ярларга бәреп,
Елга сулары ага.
Шундый матур яз көнендә
Син килгәнсең дөньяга.
Илле биш яшькә дә җиттең
Ходай рәхмәте белән.
Узсын алдагы гомерең
Дөнья рәхәте белән.
Гомерең шатлыкта үтсен,
Тормышың барсын алга.
Исән-имин эшләп барып
Чыгарга язсын ялга.
Тазалык, кояштай гомер
Телим сиңа тагын да.
Төшенкелеккә бирешмә,
Күңел төшкән чагында.
Яшә тагын илле бишне,
Һич күрми кайгы-хәсрәт.
Алга барасы юлыңда
Тәңрем бирсен көч-кодрәт.

ӨМЕТ СҮНМИ

Күңелемнең көзләре юк,
Гел чәчәкле яз гына.
Ашыкма, гомер сәгатем,
Туктап торчы аз гына.
Көзе дә бер, язы да бер,
Туктамый ага сулар.

Гомер буе өмет сүнми,
Башта хыялый уйлар...
Тормыш шундый, кеше гел дә
Үрләргә тиеш үргә.
Бәлки, мине дә бервакыт
Утыртырлар, дим, түргә.
Өметләнәсең, көтәсең,
Уйда яктылык гелән.
Әллә кайларга җитәсең
Күңелең, уең белән.
Бүген көн караңгы булса,
Иртәгә челлә кояш.
Тормыш юлы да нәкъ шундый:
Берчә — үлән, берчә — таш.
Тормыш шундый, кеше гел дә
Үрләргә тиеш үргә.
Өмет сүнми, яши яшьнәп,
Кергәнче кара гүргә.

САЙЛАП АЛМЫЙЛАР

Туганнарны сайлап алмыйлар шул,
Ул синеке — нинди булса да.
Гафу итәсең үз туганыңны,
Утка-суга кайчак салса да.

Бер бәрәңгең булса, яртысын син
Туганыңа бүлеп бирәсең.
Авырлыклар төшсә газиз башка,
Хәлләренә һәрчак керәсең.

Бер кумәчең булса, син бүләсең,
Кирәк булса, ничә кисәккә.
Туган-тумачаңны, дусларыңны —
Аласың һәркемне исәпкә.

Дөнья булгач, төрле чаклар була,
Томанлы көн, караңгы төннәр.
Туганнар бердәм булса гына,
Көтә алда тик якты көннәр.

СӨЙМӘГЕЗ КЕШЕ ЯРЫН

Булса, булсын үзеңнеке,
Сөймәгез кеше ярын.
Башта ул татлы бал булса,
Соңгарак — ачы әрем.
Мавыгып китә, ялгышып,
Кайчак адәм баласы.
Шул кара йөкне күтәреп
Күпме еллар барасы.
Кеше яры — бәхет түгел,
Үз бәхетеңне эзлә.
Кеше бакчасына кереп,
Назлы чәчәген өзмә.
Пешмәс өчен, кайнар чәйне
Кирәк өреп кабарга.
Сабырлыкларың җитәрме
Чит ярларга ярарга?
Бәхетне сатып алып та,
Булмый алып та урлап.
Каралган күңелне азак
Агартып булмый бурлап.

КҮЗ ТИМӘСЕН КҮЗЕҢӘ

Күзләрнең теле юк-югын,
Сөйлиләр әмма күпне.
Күрә ул акны-караны,
Аера җирдән күкне.
Начарны, яхшыны күрә
Үткәннәр хәтерендә.
Кирәк чакта күз йомыла,
Саклый белә серен дә.
Ягымлы да бага күзләр,
Кырыс та карый белә.
Үз итә изге күңелне,
Явызны таный белә.
Алдый алмыйсың күзләрне,
Туры кал үз-үзеңә.
Сүнмәсен нуры, очкыны,
Күз тимәсен күзеңә.

САНДУГАЧЫМ

Сандугачым, бәләкәчем,
Сайрыйсың да сайрыйсың.
Минем авыр хәлләремне
Әллә син дә аңлыйсың.
Таң йолдызы да сүнмәстән
Сайрарга керешәсең.
Парлы үткән төннәремне
Исемә төшерәсең.
Исләремә төшерәсең
Бәхетле яшьлегемне.

Хәзер килеп беркем какмый
Бикләнгән ишегемне.
Сандугачым, кун учыма,
Икәү бергә сайрашыйк.
Тумышымнан моң яратам,
Мин дә бит моңга гашыйк.
Телә миңа, сандугачым,
Алда бәхетле көннәр.
Киләчәктә сагышларда
Үтмәсен иде төннәр.

ИКЕТУГАННАРЫМ

Икетуган туганнарым
Якын бертуганнан да.
Ярдәм кирәк булса, алар
Һәрвакытта янымда.

Сый-хөрмәттән калдырмыйлар,
Өстәл түреңдә урын.
Ишеткән юк үпкә сүзе,
Һичкем карамый кырын.

Артыгы миңа кирәкми,
Ипи, чәй, жылы сүзе.
Аралашып яшәүләре
Әллә ни тора үзе.

Алдагы гомеребез дә
Гел шулай үтсен иде.
Дус, тату яшәү генә
Ача безнең күңелне.

ҮРЕЛМӘ ЙОЛДЫЗЛАРГА!

Үрелмә күккә, йолдызга,
Барыбер тоталмассың.
Насыйп булмаган алманы
Барыбер йоталмассың.
Җирдә дә йолдызлар күпләр,
Күрә белергә кирәк.
Күз күрмәсә, тояр өчен
Безгә бирелгән йөрәк.
Җирдәге бәхет тә җиткән,
Үрелмә күкнеккенә.
Бәхетең үтеп китмәсен
Болытлар кебек кенә.
Эзләмә читтән парыңны,
Карама ят кызларга.
Безнең авыл кызлары да
Тиң якты йолдызларга.

ЯШЬЛЕК – ЧӘЧӘК БӨРЕСЕ

Теләсәң, теләмәсәң дә,
Барыбер килә картлык.
Һич яшәүдән туймыйсыңдыр,
Булмыйдыр яшең артык.
Яшьлек — чәчәк бөресе,
Яшьлек — ул җиләкле җәй.
Күңелне яшьлек җилкетә,
Күңелне яшьлек бизи.
Калыр идем яшьлегемдә
Җилкенчәк бер кыз булып.
Туар идем бу дөньяга
Тагын яшел яз булып.

ЯШЕЛ – ЯШЬЛЕГЕМ ТӨСЕ

Яшел күлмәгемне кидем,
Яшел — яшьлегем төсе.
Кешенең дә куәт-дәрте,
Яшьлектә бөтен көче.
Дөнья яшелгә күмелә,
Яшәреп яз килгәндә.
Яшьлек, исләремә төшеп,
Йөрәгемне телгәндә.
Яшел юрганга төрелә
Гүзәл дөньябыз имин.
Тыныч дөньябызга дошман
Керә күрмәсен димен.

ВӘГЪДӘ-АНТ БИРЕШТЕК

Ак яулыгым бигрәк матур,
Бик килешә үземә.
Аккош кебек матур булып
Күренимче күзеңә.
Аклы ситсы күлмәгемне
Кидем әле бүген дә.
Гүя синең янга очам
Фәрештәләр күгендә.
Өз(е)леп сине сагынганга,
Ашкынам күрешергә.
Бер-беребезне ташламаска
Вәгъдәләр бирешергә.
Сүз куештык без гомергә
Вәгъдә-антны бозмаска,
Икебез йөргән сукмакка
Ятлар белән басмаска.

СӨЮ БИЛГЕСЕМЕ ӘЛЛӘ?

Кайткач яшь солдат хезмәттән,
Килде безгә кунакка.
Нинди җилләр, уйлар аны
Ташлаган безнең якка?
Чакырылмаган кунагым
Үзе шундый да тыйнак.
Самавыр чыжлатып алдым,
Өстәлгә куйдым коймак.
Үзе миннән күзен алмый,
Чәй, коймакка үрелми.
Ничек белергә уйларын —
Йөрәге бит күренми.
Бигрәкләр серле карашы,
Елмаюы, көлүе.
Сөю билгесеме әллә
Мине юллап килүе?

САРГАЙСЫН, ДИСЕҢМЕНИ?

Саргаеплар үлсен бу дисеңме?
Хат-хәбәрең юк бу арада.
Сагынсам да, ара бик тә ерак,
Очрашырга юк бер чара да.
Офыкларга кереп югалдың да,
Онытыр бу әле диденме?
Йөрәк өзеп, иске төшеп торгач,
Онытуы әллә җиңелме?
Чит җирләрдә ничек яшисең соң,
Сагындырмыймыни туган як?

Төшеңә дә керми, исеңә дә
Төшмимени бергә булган чак?
Озын гомер җирдә яшәргә дип
Һәммәбез дә туа торгандыр.
Сөйгән ярсыз, газиз туган җирсез
Тормыш нурсыз була торгандыр.

ӘКИЯТТӘГЕ КЫЗ

Эльверт Гарафетдинов көе

Төштә түгел өнемдә, билләһи,
Бер сылуны очрадым берчак.
Әллә рәсемдәге әкият кызы,
Әллә инде матур бер курчак.

Куе бәрхет керфекләр астында
Зәңгәр сөрмәле күзләр.
Шундый матур әкият кызын күреп,
Гашыйк булмый кем генә түзәр.

Әллә күтәрелми керфекләрең,
Әллә карамыйсың оялып.
Ни эшләрмен, миңа карамасаң,
Харап булсам, сиңа күз салып.

Зәңгәр күзләр — минем бәхетемдер,
Бәлки, үзем синең бәхеттер.
Гомер буе ашкынып эзләгән
Күңелемнең чәчәге синдер.

Ник бу күзләр сагыш белән тулы,
Нур чәчәргә тиеш бит алар.
Дөрләп янып, очкын атып торган
Карашны күрмиләр ник алар?

ӨЗГӘЛӘНМИМ, АШЫКМЫЙМ

Көн артыннан көннәр үтә
Кабаланып, ашыгып.
Алда торган һәр эшкә дә
Тотынабыз шашынып.
Үткән көннәр кире кайтмый,
Минуты, сәгате дә.
Ашыгырга, ашкынырга
Юк сыман сәбәбе дә.
Ашыкмыйм гомер көзенә
Барырга киләчәккә.
Алга атлыйсы юлларым
Күмелсен гөлчәчәккә.
Үз көенә барсын дөнья,
Мин үзем һич ашыкмыйм.
Көчем җиткәнчә яшимен,
Өзгәләнмим, ашкынмыйм.

КЕМНЕ СӨЯР ИДЕМ?

Кемне генә тиңем итәр идем,
Сине очратмасам юлымда?
Кем белән мин алга атлар идем,
Кулларың булмаса кулымда?

Кемне генә өз(е)леп сөяр идем,
Син булмасаң шушы дөньяда?
Кем белән сө(е)неп яшәр идем
Икәү бергә корган ояда?
Кемгә соң мин бүләк итәр идем
Бар назымны, сөю хисемне.
Миннән башка кем соң җырлар иде
Җырга кушып синең исемне?
Яшик әле, җан-җанашым, бергә,
Белеп мәхәббәтнең кадерен,
Куанышып балалар үскәнгә,
Корытмыйча нәсел тамырын.

АК СИРЕНЬ

Килеп кердең дә түрләргә
Кыюсыз гына уздың.
Назлы карашыңны ташлап,
Сирень бәйләме суздың.
Ап-ак сирень тәлгәшләре
Күмде хуш искә өйне.
Сиңа гашыйкмын үзем дә,
Истән чыгармыйм сине.
Сирень таҗларын саныймын,
Белсәм дә сөйгәнеңне.
Тоям бар йөрәгем белән
Мин диеп көйгәнеңне.
Җан атып торырга язсын
Беребезгә беребез.
Ак сиреньнәргә күмелсен
Мәхәббәтле түребез.

САУ БУЛЫГЫЗ, КЫР КАЗЛАРЫ

Салкын яңгыр ява, көзләр җитте,
Кыр казлары очып киттеләр.
Күккә карап елап озатып калдым,
Гүя күңелемне өттеләр.
Туган җирне ник ташлап киттегез,
Күңелләрдә сагыш калдырып?
Кай якларга очасыздыр инде,
Пар канатыгызны талдырып.
Сау булыгыз, сез кайтырсыз, казлар,
Алла бирсә, җылы яз җиткәч.
Күпме уфтансаң да, еласаң да,
Яшьлек кенә кайтмас, бер киткәч.

ҖИТӘКЛӘШЕП АТЛЫЙБЫЗ

Әллә син мине сөясең,
Әллә минме яратам?
Бер минут сине күрмәсәм,
Сагышымны яңартам.
Яратышып туялмыйбыз,
Гыйшык утыбыз көчле.
Яратам мин гөлчәчәкне,
Чөнки ул синең төсле.
Күптәнге хыял-уебыз
Ашты тормышыбызга.
Тәкъдир аркылы төшмәде
Безнең язмышыбызга.
Зәңгәр күкнең син — кояшы,
Мин — аның якты ае.
Югалма, берүк, кояшым,

Офыкка кереп баеп.
Җитәкләшеп, гелән парлап
Атлыйбыз туры юлдан.
Гомер юлын үтсәк иде,
Аерылмый куллар кулдан.

ЧӘЙЛӘР ЭЧӘРБЕЗ

Гел күңелем түрендәсең
Син, әнием, сөеклем.
Бик еш күрешеп торсак та,
Сагынамын шултиклем.
Синең фатиханнан гына
Яшәргә мин көч алам.
Сөйлим кат-кат догаларны,
Өйрәнсен диеп балам.
Тәмле, баллы күчтәнәчләр
Алып кайтырмын әле.
Кара-каршы утырышып
Чәйләр эчәрбез, ямь.

ЙӨРӘКНЕҢ ТҮРЕН БИЛИ

Сандугачлар яшеренә
Яфрагына тирәкнең.
Тәүге өз(е)леп сөйгән ярлар
Түрен били йөрәкнең.
Боз йөрәкне назлы кочак,
Җылы сүзләр эр(е)тә.
Кешене бит җир йөзендә
Мәхәббәт кенә йөртә.

Йөрәк яшерен урында,
Ул кешегә күренми.
Сөйсә сөя, янып-көеп,
Бер кабынса, сүрелми.

КЫШКЫ ЧИЯ

Илгиз Закиров көе

Күбәләкләп яуган ап-ак карлар
Килеп куна битем очларына.
Күзләремдә ай һәм йолдыз нуры,
Бөтерелəм хисләр кочагында.

Кушымта:
Әмма күрмим яуган карларны да,
Җитәкләшеп үткән парларны да.
Син бит миңа бүген: «Сөям, — диден, —
Кыш көнендә пешкән чиям», — диден.

«Күрәгемә кысып җылытырмын,
Чиям, — диден, — сине өшетмәм».
Мондый иркә, назлы сүзләрне бит
Мин тик тәүге кабат ишетәм.

Кушымта.

Күбәләкләп яуган ап-ак карлар,
Килеп куна битем очларына.
Иреннәрдә баллы чия тәме,
Эрим кебек синең кочагында...

Кушымта.

АК КАРЛАР ЯУСЫН

Кайтыр идем мин үткән елларга,
Тик каян соң аны юлларга?
Атлап түгел, очып барыр идем,
Ходай канат куйса колларга.

Кабат гашыйк булыр идем үлеп,
Гашыйк итәр идем үземә.
Кабат балкыр иде язгы кояш,
Нурын өстәп нурлы күземә.

Кабат үтәр идем җитәкләшеп
Иркәм белән төнге урамнан.
Тәгәрәр идем кар өстенә ятып,
Ләззәт эзләп карлы бураннан.

Эх! Кире кайтулары мөмкин түгел
Үткән гүзәл яшьлек елларга.
Инде калган гомерләрдә безнең
Ап-ак карлар яусын юлларга.

ДУСЛАР ТАПТЫМ ҖЫР АША

«Эшең кайда?» — дип сораман,
Мин җырчы булып эшлим.
Җыр — ул миңа рухи азык,
Җыр белән яшып яшим.
Күп дуслар таптым җыр аша,
Гиздем байтак җирләрне.
Каршы атладым давылга,
Күрдем күпме илләрне.

Җыр булды минем юлдашым,
Җырлап атладым алга.
Тормышым ыгы-зыгылы,
Вакыт та калмый ялга.
Ләкин ул шатлыктан тора,
Җырлап яшим мин көн дә.
Моңлылар бәхетсез, диләр,
Ышанмагыз беркемгә.
Авыр юлны җиңел үтәм,
Карамыйм уңга-сулга.
Җырлар миңа дәрт-көч өсти,
Җырлап яшим мин шуңа.

ТЕЛИСЕҢДЕР КҮРЕРГӘ

Төшләремә гел керәсең,
Онытмасын, дисеңме?!
Әле булса җырларыма
Кушам синең исемне.
Сагышлардан өзгәләнеп
Үлсәм, йөрәгем янып,
Ниләр эшләрсең дөньяда,
Минсез берүзең калып.
Күзләрем талганчы карыйм
Агыйдел агышына.
Йөрәгем ничек түзәдер
Аерылу сагышына.
Бәлки, син дә уйлыйсыңдыр,
Телисеңдер күрергә,
Назга сусаган йөрәгем
Мәхәббәткә төрергә.

АЛМАСЫ НИГӘ АЧЫ?

Алмагачның алмалары
Ачы була, пешмәсә.
Сагышларны белмәс идем,
Үз башыма төшмәсә.

Алмагачлар бергә үсә,
Аерылдык без генә.
Көтеп торыйм әз генә,
Ул бит пешә көз генә.

Өзеп алды икән кайсы
Мин өзәсе алманы?
Ташлап китте иркәм мине,
Хат та язып салмады.

Сабыр итим мин беразга,
Алма пешә көз генә.
Кайтыр сөйгәнем сагынып,
Түзү кирәк әз генә.

КАЙГЫ КИЛМӘСЕН БАШКА

Аккошлар тик парлап йөзә,
Ялгыз калса, йөзми ул.
Ялгызларның әрнегәнен
Пар яшәгән белми ул.
Кыйгаклап аккош кычкыра,
Эзләп төшкән күлләрен.
Юлга карап, хатлар көтеп
Узар инде көннәрем.

Аккош канатларын җилпи
Зәңгәр күлдә йөзәргә.
Ходай сабырлыклар бирсен
Ялгызларга түзәргә.
Канаты төшмәсен кошымның,
Күле генә кипмәсен.
Ялгызлыкка түзеп була,
Башка кайгы килмәсен!

КЕМ ӨШЕСЕН КОЧАКТА?

Сөйгәнем мине чакырды
Очрашырга, кич җиткәч.
Мин килермен, чыгарсың, ди,
Якты ай нурын сипкәч.
Агачларны бәс каплаган,
Чатнама суык тышта.
Очрашырга, күрешергә
Кем йөрсен салкын кышта?
Йөрәк түзми, үзем көтәм
Күктә айның калкуын,
Тулган ай кебек елмаеп
Сөйгәнемнең балкуын.
Чиллә суыклары нәрсә,
Йөрәкләр янгач дөрләп,
Үткәрәбез айлы кичне
Күгәрчен кебек гөрләп.
Иреннәре иренемә
Кушылалар кайчакта.
Кысып коча иркәм мине,
Кем өшесен кочакта?

ГАШЫЙК ПАРЛАР БӘХЕТЕ

Син — минем мәхәббәт моңым,
Син минем җырым булдың.
Син якты кояшы идең
Бергә атлаган юлның.
Җитәкләшеп без атладык,
Җимереп киртәләрне.
Таң атканда каршыладык
Томанлы иртәләрне.
Таратырга томашны да
Өйрәндек икәү бергә.
Юкка килмәгәнбез без, дим,
Бу изге якты җиргә.
Шундый бәхет телим, дуслар,
Сөйгән изге җаннарга:
Бәхетле булып уянсын
Гашыйк парлар таңнарда.

ЧӘНЕЧКЕЛЕ ГӨЛЕМ

Тәкәббер кызларга никтер
Күңел тартыла гел дә.
Нәфис, гүзәл чәчәк ата
Бар чәнечкеле гөл дә.
Нәкъ менә шундый чәчәкне
Килә өзеп аласы.
Нәкъ менә шундый гүзәлне
Килә назлап карыйсы.
Килә хыялыйлар кебек
Гашыйк булып сөясе.
Мәхәббәт мичснә кереп,

Ялкынында көясе.
Килә мәхәббәт утында
Гомерлеккә каласы.
Килә нәкъ шул «чәнечке»не
Кәләш итеп аласы.

ТАШЛАМА, ИРКӘМ!

Бер кыек астында яшибез,
Булмас сымак һич кенә чара да.
Бәйләп торган алтын чылбыркай бар:
Сөю җимеше — бала — арада.

Сөю хисе күптән сүнде диеп,
Ашыкма син араны өзәргә.
Кузы сүнмәсә, учак кабыныр,
Ә мин әзермен мәңге көтәргә.

Дөнья булгач, төрле чаклар була:
Тиргәшәсең дә, сөешәсең дә.
Тормыш бит ул үзе бер могҗиза:
Дуслашасың да, килешәсең дә.

Яшәп булмый хәзер бергә, димә,
Бәхетсезлек бит шуннан башлана.
Мәхәббәт учагы сүнде, димә,
Ташлама, иркәм, зинһар, ташлама.

Минем сөю хисем җитәр, димен,
Икебезгә дә гомер буена.
Мин сөеп яшим бөтен дөньяны,
Изге теләгем һәрчак уемда.

СӨЙДЕРГЕЧ ДОГАСЫ

Әллә сөйдергеч догасы
Йөртәсең үзең белән.
Тылсымлы карашың сирпеп
Карыйсың күзең белән.
Шултиклем дә син сөйкемле,
Ягымлысың, сылуым.
Зур бәхет ул минем өчен
Синең янда булуым.
Кемнәргә ачык ишеге
Йөрәгемнең, чибәрем?
Башканың күзе төшкәнче,
Әллә ячы җибәрим?
Сихерләдең: йөрәккәем
Ачык тик синең өчен.
Мәңге җиңәлмәсәм иде
Сөйдергеч догаң көчен!
Синнән башка беркемгә дә
Урын юк йөрәгемдә.
Ятлардан тартып алырлык
Гайрәт бар беләгемдә.

МӘҢГЕ ЙӨРӘКТӘ

Булса корычтай тазалык,
Яшь булсам илле яшькә,
Бик дәртләнеп, җиң сызганып
Тотыныр идем эшкә.
Курыкмыйм мин авыр эштән,
Тик көч югала кулдан.

Төп-төз җирдә дә абынып,
Атлыйм мин туры юлдан.
Булмый икән сатып алып
Саулыкны, гомерне дә.
Чыгарып ташлый алмыйсың
Шул өянәк чирне дә.
Ник, яшьлегем, китеп бардың,
Калдың ерак-еракта?
Онытылмас бер моң булып
Калдың мәңге йөрәктә.

БӘХЕТ ТАБЫЛА ҖИРДӘ

Башыңны иеп утырма,
Әгәр сагышка калсаң.
Хыяллар тормышка аша,
Бераз тырышлык салсаң.
Кеше күңеле гел уйда,
Яши якты хис белән.
Иртән килмәсә бәхетем,
Бәлки, килер кич белән.
Өметем җимерелде дип,
Төшермә кулларыңны.
Үзең эзлә бәхетлесен
Барасы юлларыңның.
Йөрәге типкән кешенең
Өмете сүнмәс бер дә.
Тик иренмә, эзлә генә —
Бәхет табыла җирдә.

ОЛЫ АБЫЕМА

Эльверт Гарафетдинов көе

Олы абыем, кадерлем,
Рәхмәтлемен мин сиңа.
Төрле яклап ярдәм көче
Күрсәтәсең син миңа.
Җаның изге, күңелең киң,
Йөзең якты һәркемгә.
Сине дөньяга китергән
Рәхмәтлемен бу көнгә.
Син абыем — зур киңәшчем
Мохтаҗ чакта, ярдәмчем —
Югалып калган чагымда,
Серем булса — сердәшчем.
Кулдан килгәнчә ярдәмне
Мин дә сиңа кылырмын.
Синең кебек, изге җанлы,
Мәрхәмәтле булырмын.

ҖЫРЛАМЫЙ НИЧЕК ТҮЗИМ?!

Йөрәгем ярсып әрнегәч,
Еламый ничек түзим?!
Сагыштан күңелем ярсый,
Җырламый ничек түзим?!
Җыр тыңласам, исем китеп,
Күңелем назга тула.
Кушылып җырлап җибәрсәм,
Көннәрем кояш була.

Әл дә әле җырларым бар,
Әл дә әле моңым бар.
Алдымда илһам бирүче
Бара торган юлым бар.
Әл дә әле сөйгәнем бар,
Кочып туймас җирем бар.
Мәдхияләр язу өчен,
Сөеп туймас илем бар.
Мәхәббәт бар, балалар бар,
Өзелеп сөйгән ярым бар.
Бар җиһаным җырдан тора,
Мәңге үлмәс җырлар бар.

КОДАГЫЕМА

Безнең кодагыйкаебыз —
Алтынның да алтыны.
Һәммәбезнең күңелен таба,
Ул бит шундый акыллы.
Без дә аны яратабыз,
Хөрмәт итәбез гел дә.
Аның кебек шәп кодагый
Юктыр ул бөтен илдә.
Өлкәннәргә, балаларга
Күңел җылысын бирә.
Шуның өчен дә бит аны
Үз итә күрше-тирә.
Изгеләрдән изге нәнәй
Һәм кадерле әнкәй дә.
Бигрәкләр шәп кеше инде,
Чын күңелдән әйткәндә.

Инде Ходай озын гомер,
Тазалык кына бирсен.
Ак бәхетләр, зур шатлыклар
Бергә уралып йөрсен.

СӨЮ КҮЛЕНДӘ

Болытлы көннәр дә якты,
Син янымда булганда.
Бәхет кочагында йөзәм,
Кич житкәч, ай тулганда.
Кочып алып бөтерелеп,
Назлыйсың, иркәлисең.
«Гомеремнән артык күрәм
Мин сине, иркәм», — дисең.
Синнән башка бер минут та
Яши алмыйм мин хәзер.
Синең өчен жанымны да
Бирергә бит мин әзер.
Тик парлашып, бергәләшеп
Үтәргә язсын юлны.
Зур мәхәббәт кочагында
Алмыйча кулдан кулны.
Үтәргә язсын тиң булып
Озын гомер юлларын.
Мәхәббәт көснә генә
Чиртеп күңел кылларын.
Яшәргә язсын шатланып,
Сөю күлендә йөзеп.
Жыеп алырбыз түбеннән
Бәхет ташларын сөзеп.

ТИРӘН ЭЗ САЛА

Үлеп гашыйк булган идем сиңа
Яшь чагында, теге заманда.
Гыйшык уты көйри йөрәгемдә,
Оныталмыйм әле һаман да.
Эзсез генә сүнми бер ялкын да:
Уты сүнсә, күмере кала.
Өзелеп сөю, артык янып-көю
Йөрәкләргә тирән эз сала.
Менә шулай йөрәк тиле инде,
Буйсынмый гына һич акылга,
Сөйгәнне сөйми, сөйсә, сөелми,
Гомере буе яши ялкында.
Онытырга тырышып карадым
Теге чакта, теге заманда.
Күңелемне юатырлык кеше
Очратмадым әле һаман да.

МӘХӘББӘТ СЕРЕ

Мамык-мамык карлар куна
Иркәмнең чәчләренә.
Бөтереләм, мин төренәм
Мәхәббәт хисләренә.
Хисем таша йөрәгемнән,
Иркәм дә аны сизә.
Минем кебек, күрәм, ул да
Сөю хисендә йөзә.
Кысып кочам, гүя очам
Иркәм белән күкләргә,

Гыйшык нурын сибә-сибә
Парсыз калган күпләргә.
Яшибез шулай гөрләшеп,
Сөеп бер-беребезне.
Чишәргә булдым мин сезгә
Мәхәббәт серебезне.

БҮГЕН МИҢА КИРӘКСЕҢ

Ерак түгел аралар да:
Урам аша торабыз.
Капкадан чыккач та юлны
Башка якка борабыз.
Йортларыбыз капма-каршы —
Күз алмыйм тәрәзәдән.
«Сөяме?» — дип әллә инде
Сорарга курәзәдән.
Үзең һич тә сер бирмисең,
Әллә инде белмисең?
Көне-төне утта янам,
Әллә һич тә сизмисең?
Нинди йөрәк соң ул синдә,
Әллә бозланып туңган?!
Күреп калыйм әле диеп,
Мин күзем алмыйм юлдан.
Күңелең бер дә тоймыймыни,
Нинди үлгән йөрәк син?
Еллар үткәч, соң булыр ул,
Миңа бүген кирәк син.

СЫНГАН СИРЕНЬ

Бүләк итеп бирмәгәчтен,
Сиреньне ник сындырдың?!
Нигәләр карап елмайдың,
Күңелне ымсындырдың?
Күз кыскан булдың бик серле,
Баш иеп сәлам бирдең.
Сизми калганмын үзем дә,
Йөрәккә килеп кердең.
Сиңа шаяру гынадыр,
Мин барын чынга алдым.
Башым хыялга чумды да
Кыен хәлләргә калдым.
Ять-ятъ керсез күңелемне
Сүнмәс утларга салдың.
Сынган сирень — мәхәббәтем,
Син киттең дә югалдың.

ХАТ ҖИБӘРӘМ ИРКӘМӘ

Куш табак битне тотырып
Язам сагыну хатлары.
Оныткандыр инде диеп,
Сөймә, берүк, ятларны.
Шул ук сөю, шул ук тойгы,
Истән чыкмыйсың һич тә.
Күз алларымда торасың,
Иртән торгач та, кич тә.
Куш табак битне тотырып,
Хат җибәрәм иркәмә.

Сагынуымның чиге юк,
Кайтып жит дип иртәгә.
Кайтырсың дип өмет итәм,
Сөекле сөйгән ярым.
Син генә, берүк, онытма
Яраткан парын барын.

ӨМЕТ ЯШӘТӘ

Кемгә бәхет авыл килә,
Кемнәдер уран уза.
Кемнең, бәхет кетә-кетә,
Изге йөрәге туза.
Йөрәк ул табигать түгел,
Яшәрә алмый яз саен.
Дөрләп янган учак уты
Сүнә бара ел саен.
Йодрык чаклы бер йөрәктә
Күпме уйлар, өметләр.
Үзенә тигән бәхетне
Кем зарыга көтепләр.
Шулай да өмет яшәсен,
Дәрт сүнмәсен йөрәктә.
Алда гомер бардыр әле —
Күңел шундый теләктә.
Өмет яшәтә кешене,
Өметсез шайтан гына.
Бик кечкенә бәхеткә дә
Күңел дулкыны тына.

КЫРЛАЧНЫ ҖИҢӘ ГЫЙШЫК

Чыдап булмаслык салкыннар,
Башлансалар кырлачлар.
Ай нурында ялтырыйлар
Бәс каплаган агачлар.

Салкынны да, буранны да
Тоймый икән гашыйклар.
Бер-берен кочып жылыта,
Көчле булса гыйшыклар.

Тынында өреп җылыта
Сөйгәнен гашыйк егет.
Йолдызлы күкләргә чөя,
Тормый ул һич тә җебеп.

Хыялларга сабышасың,
Сөю чире кагылса.
Берни түгел кырлачы да,
Күңел өз(е)леп сагынса.

КАРЛАР КЕБЕК ОЧАМЫН

Җир йөзен мамыкка урап,
Күптән көткән кар ява.
Иркен сулап тын аламын:
Тирә-якта саф һава.
Кар бөртекләре очалар,
Күңелгә шундый рәхәт!
Шушы мамык карлар өчен
Ходаема зур рәхмәт.

Ак карлар — күңел сафлыгы,
Ап-ак төс ул — саф сөю.
Салкында да янасың шул,
Мәхәббәт — утта көю.
Иркәм белән бөтереләм,
Карлар кебек очамын.
Үбә-үбә бит очларын,
Сөйгәнемне кочамын.

КАРАШЫП АҢЛАШАБЫЗ

Иркәлисең, назлыйсың да,
Үзең «сөям» димисең.
Мин бит сине үлеп сөям,
Әллә шуны сизмисең.
Телең әйләнмимени соң
Шул бер сүзне әйтергә?
«Тик сине яратам» сүзен
Миңа күпме көтәргә?
«Сөясеңме?» дип сорасам,
Тик елмаеп карыйсың.
Кысып кочып аласың да
Сыйпап чәчем тарыйсың.
Аккошлар да сөйләшмиләр,
Карашып аңлашалар.
Алар да бит гашыйк булып,
Сөешеп кавышалар.
Нәкъ шулай, аккошлар кебек,
Яшәп ятабыз без дә.
Карашлар аңлашкан чакта
Кирәкмидер бер сүз дә.

БАЛАЛАРЫМ – ГӨЛЛӘРЕМ

Уртак гөлләр, ак чәчәкләр —
Безнең балаларыбыз.
Күбрәк үссәләр чәчәкләр,
Сүнмәс араларыбыз.
Балалар — күңел шатлыгы,
Алар бит өйнең яме.
Түгәрәк өстәл җыелса,
Шунда икмәкнең тәме.
Балалар янда булганда —
Өйдә кояш җылысы.
Йөрәктән таша шатлыгым,
Килеп тора җырлыйсы.
Шушы шатлыктан аерма,
Ходай Тәгаләм, безне.
Шул чәчәкләргә күмелеп
Көтеп алырбыз көзне.

ЯКТЫ ӨМЕТ КҮҢЕЛДӘ

Тоз сипмә, зинһар, ярама,
Ул әле төзәлмәгән.
Өмет учагы күңелдә —
Ара, дим, өзелмәгән.
Өмет һәрчак маяк булып
Янарга тиеш алда.
Тик үзеңә насыйп булган
Йолдыз балкысын таңда.
Күк гөмбәзеннән күк томан
Төште безнең арага.

Томан-таралыр да бетәр,
Сөю булса арада.
Сакланганды саф сөюләр,
Томан аша күренә.
Якты өмет һәрвакытта
Яши күңел түрендә.

ТАТЛЫ БАЛЫМ

Көн дә кичен сагынып көтәм
Синең килүләреңне.
Татлы бал кебек тоямын,
Иркәм, иреннәреңне.
Кочагыңа сыенам да
Исерәм назларыңнан.
Аермасын гына язмыш
Яшьлегем язларыннан.
Иркәләнеп туймам сымак,
Күпме иркәләсәң дә.
Синең кебекне табалмам,
Күпмеләр эзләсәм дә.
Нәкъ син булгансың икән ул
Минем яшьлек хыялым.
Синең белән үтсен иде
Кадерле изге җаным.
Шундый бәхет бирсен иде
Ходай һәрберебезгә.
Яңгыр булып яусын иде
Бәхетләр җиребезгә.

КЕРЕР ӘЛЕ ХӘЛЕМӘ

Яшьлегемнең чәчәк аткан чагы,
Хисләр таша йөрәк түремнән.
Гел яшәрмен сыман шулай дөрләп,
Гүя инде мәңге сүрелмәм.

Үлеп гашыйк булдым бер сылуга,
Ярсый күңелем шашып сөюдән.
Үзем кыймыйм туры карарга да,
Әллә куркам күзем тиюдән.

Язын чәчкә аткан гөлләр кебек
Күренә ул минем күземә.
Күңелемдә бер уй: белмим, аны
Каратырга ничек үземә?

Серле карашымны күрер әле
Дигән уйда яшим әлегә.
Үзе минем кебек гашыйк булгач,
Керер әле ул да хәлемә.

ЯКТЫ ТАҢДА

Яратып кигән киемнәр
Нигә тиз туза икән?
Бәхетле яшәгән еллар
Нигә тиз уза икән?
Озынайтыр идем дә бик
Бәхетле елларымны.
Алыштырмам караңгыга
Мин якты юлларымны.

Тормыш якты булса гына,
Күңел дә якты була.
Кабул булса теләкләрең,
Дөньяң шатлыкка тула.
Дога кылырга онытмыйк
Уянгач якты таңда.
Таза булу, исән яшәү —
Ул үзе шатлык җанга.

АЛТЫН-КӨМЕШ ҖЫЙМАДЫМ

Гомер үтә, үтми тормый,
Йөрәк кенә тузмасын.
Үзенә кадерле җаның
Тиккә генә узмасын.
Шатлыкка тулы күңелләр
Калсын мәңге яшь булып.
Ак чәчәкле язгы гөлем
Харап булмасын сулып.
Саклансын күңел байлыгым,
Дәрт-дәрманым сүнмәсен.
Ходаем биргән гомерем
Кайгы-хәсрәт белмәсен.
Биек тауга менмәсәм дә,
Төшмәдем чокырга да.
Көмеш-алтыннар җыймадым,
Канәгать бакырга да.
Бар алтыннан да кадерле
Яшәгән гомеркәем.
Гомеремнән дә кадерле
Туып-үскән җиркәем.

БӘХЕТ ӨЛЕШЕ

Буласы бәхет булыр ул,
Китмәс, дим, беркая да.
Бәхет эзләп йөрүчеләр
Әллә азмы дөньяда.
Эзләп табып булса икән
Бәхет дигән йолдызны.
Ничек саклап калырга соң
Яшьлегем дигән язны?
Мәхәббәткә, бәхеткә дә
Яшьлекнең өмете бар.
Җир йөзендә һәркемнең дә
Бәхеттән өлеше бар.
Безнең урамда да кояш
Чыгар әле бер заман.
Могҗизалар булыр әле —
Өметне өзмим һаман.

КҮРЕП КУАНСАК ИДЕ

Язмыш ишек кагып тормый,
Үзе килә дә керә.
Кайгыны да, шатлыкны да
Язмышлар үзе бирә.
Аллаһ сынау бирә, диләр,
Тик сөйгән бәндәсенә.
Уйламаган җирдән генә
Тарыта бәласенә.
Килә уңыш, шатлыклар да,
Бар сынауларны җиңеп.

Сөендерә таулар хәтле
Кечкенә бәхет килеп.
Тәкъдир алдында без көчсез
Үзгәртергә язмышны.
Күрепләр куансак идс
Бәхет дигән балкышны.

НИ ҖИТӘ?

Син гүзәлләрнең гүзәле,
Ягымлысың, сөйкемле.
Күкнең алтын нурын чәчеп
Торган ае шикелле.
Сине күрми бер сәгать тә
Яши алмыйм мин түзеп,
Чәчәкләрнең иң матурын
Биримме, иркәм, өзеп?
Мин дә сөям сине, дисәң,
Кочсаң йөгереп килеп,
Җаным күккә күтәрелер,
Очып йөрермен кебек.
Күңелең сөйгәнең белән
Яшәүләргә ни җитә?
Тик парлы яшәлгән көннәр
Алда бәхетле итә.
Күңелең тулса шатлыкка,
Сагыш-зар үтеп китә.
Шушы якты дөньяларда
Шат яшәүгә ни җитә?!

Нишләрмен икән, кайтмаса,
Гомер буе көтеп тә?
Корыган гөл чәчәк атмас,
Күпме сулар сипсәң дә.
Яшьлек хисләре уянмас,
Ничек кенә сөйсәң дә.

БАШКОРТ КЫЗЫН СӨЯМЕН

Кара кашлы, кара күзле
Башкорт кызын сөямен,
Азга гына күрми торсам,
Янам дөрләп, көямен.
Ул гынадыр — минем бәхет,
Көткән якты өмстем.
Ходаемнан теләп алган
Алтынга тиң көмешем.
Ансыз ничек яшәгәнмен —
Шуңа хәзер шаккатам.
Күз алларыма килә ул
Иртән торсам, атса таң.
Хәзер инде атлап түгел,
Очып кына йөримен.
Иреннәр иренгә тисә,
Кочагында эримен.
Шушы бәхетле сәгатьләр
Булсын иде гомерлек,
Беребез өчен беребез
Җаныбызны бирерлек.

САГЫНЫП ЯШИМ

Кире кайтам кебек яшьлегемә,
Искә алсам үткән елларны,
Уем, күңелем белән бер әйләнәм
Өр-яңадан үткән юлларны.

Узган еллар алар — якты хисләр,
Шатлык белән үткән көннәрем.
Якын дуслар, тәүге мәхәббәтем,
Очрашулар, айлы төннәрем.

Узган еллар алар — якын дуслар,
Матур җырлар, гармун моңнары.
Һәрчак күз алдымда авылымның
Сызылып аткан алсу таңнары.

Сагынуларым телә йөрәгемне,
Истәлекләр һәрчак күңелдә.
Үтеп киткән гүзәл гомеремне
Сагынып яшим шулай гомергә.

УРТАК СӨЮ КАВЫШТЫРЫР

Көмеш телле гармунымны
Алам да кулларыма,
Сине генә, җан сөйгәнем,
Кушам җыр юлларына.
Торасың гел күз алдымда,
Кичен йокларга ятсам,

Сиңа охшатып сокланам,
Гөл чәчәгенә баксам.
Шулай уза һәрбер көнем,
Хыялда сине уйлап.
Суга килер дип әйләнәм
Чишмә тирәсен буйлап.
Мин син диеп хыялланам,
Син сөясең, әйт, кемне?
Уртак сөю кавыштырыр —
Өзмимен өметемне.

НАЗЛАР МИНЕ, ЯРАТЫП

Сөйгәнем көтәдер диеп,
Йөгереп чыктым урамга.
Мамык шәлемә уранып,
Каршы атлыйм буранга.
Сөйгәненнән башка кем соң
Янган йөрәккә кирәк?
Дулаган буран нәрсә ул,
Дулагач ярсып йөрәк.
Кар бөртекләре уйныйлар,
Дөнья йөзе ап-ак кар.
Көртне ярып атлыйм алга,
Чөнки көтә сөйгән яр!
Кысып алыр кочагына,
Назлар мине, яратып.
Икеләнгән уйларымны,
Шикләремне таратып.

АЕРЫЛМАГЫЗ ЯРЛАРДАН

Су өсләре дулкынлана
Әкрен искән җилгә дә.
Сөйгәне белән аерылу
Рәхәт түгел кемгә дә.
Аерылганнар гына белә
Кемне югалтканнарын.
Очратып, табыплар кара
Күңелгә ятканнарын.
Ертык киемгә — ямаулык,
Диләр икенче ярны.
Ямаулы кием кимәгез,
Сакларга кирәк барны.
Сайлап алган ярың белән
Бергә үтегез юлны.
Аермагыз беркайчан да
Сөеп кушылган кулны.

КАДЕРЛЕ ГОМЕРКӘЕМ

Чәчәк ата, матурлана
Туып-үскән җиркәем.
Ник бик тиз үттең әле,
Кадерле гомеркәем.
Ага һаман, туктамады
Эчәсе суларым да.
Озак аксын иде әле
Яшисе елларым да.
Сокланып туймадым әле
Шушы матур дөньяга.
Тотып та туктатып булмый,

Гомер ага да ага.
Күпме эшләр ята алда,
Язасы фикерләрем.
Күңелемдә ачылмаган,
Чишелмәгән серләрем.
Ходаем, кызганма әле
Гомер дигән асылны.
Берүк, тартып ала күрмә
Уй-зиһенне, акылны.
Күренмәгән шатлыкларым
Күп булсын киләчәктә.
Ким-хур булмыйча яшәргә
Тырышырмын ничек тә.

ҖӨЙСЕЗ ТӨЗӘЛМИ ЯРА

Ыргытырга ашыкмагыз,
Гөлләрегез сулса да.
Аерылырга ашыкмагыз,
Аралар суынса да.
Төенсез җеп тә ялганмый,
Җөйсез төзәлми яра.
Тирән яралган яраны
Җөйсез төзәтеп кара.
Таныш булмаган сукмакка
Басмагыз уйламыйча,
Алда үтәчәк юлларны
Җиде кат буйламыйча.
Ашыкмагыз ташлашырга,
Аерылырга шулай да.
Тормыш юлы сикәлтәле,
Авыр үтә болай да.

ЯШЬ ГОМЕР КИРЕ КАЙТМАС

Яшәп туйганым юк әле,
Күп кенә яшәсәм дә.
Кире кайтмас яшь гомерем,
Терсәкне тешләсәм дә.
Яшь гомерем матур үтте:
Сөйдем дә, сөелдем дә.
Төрле чаклар булды инде:
Аудым да, сөялдем дә.
Күпме генә яшәсәм дә,
Атладым туры юлдан.
Авыр эшме, җиңелеме —
Эшлим килгәнчә кулдан.
Картаерга ашыкмыйм һич,
Картлыкның ни кызыгы?
Картлык ул азаккы сулыш,
Картлык — гомер азагы.

СОҢЛАГАН БӘХЕТ

Соңлап килде миңа бәхет,
Соң булса да, уң булды.
Шатлыктан да елый кеше —
Күзләрем яшькә тулды.
Бер бәләкәй генә кисәк
Бәхет сораган идем.
Ходаем мине яратты —
Бирде бәхетне өеп.
Икебезнең дә чәчләргә
Ап-ак карлар кунганчы,
Яшәсәк иде пар булып,
Алтын туйлар булганчы.

БЕРӘҮ ДӘ БӘХЕТ САТМЫЙ

Әллә инде адаштыммы,
Әллә инде ялгыштым?
Бәхет сайлап, отам диеп,
Кемне кемгә алыштым?
Әллә яшьлек иләслеге,
Әллә күңел хатасы:
Сөяр идемме башканы,
Белсәм ялгыз каласым?
Үкенсәң, үкенмәсәң дә,
Үткәннәр кире кайтмый.
Күпме генә эзләсәң дә,
Берәү дә бәхет сатмый.
Буйсынып яшәргә кала
Сайлаган язмышыма.
Кайгыларны йотып яшим,
Төшкәч газиз башыма.

УЙЛАМАГАН ИДЕМ

Очрашырбыз диеп аерылдык,
Әле алда еллар бар диеп.
Теләгәнчә бармый икән тормыш,
Яшәсең килсә дә сөелеп.

Аерылабыз мәңгелеккә диеп
Уйламаган идем, сөеклем.
Күз яшьләре аша хушлашуны
Авыр була диеп шүлтиклем.

Язмыш шулай аера да куя,
Сөйгән йөрәкләрне яралап.
Бәхетне дә Ходай Тәгаләбез
Бирә икән нигә аралап?

Башка очрашмадык, кем гаепле,
Әллә хисләр сүнде, кем белсен?
Тик язмышны үзгәртепләр булмый,
Алда еллар имин, ак килсен!

КАРАМАДЫМ БУРАНГА

Иңнәремә салып ак шәлемне,
Озата чыктым сине урамга.
Яратуым шундый көчле иде:
Карамадым җилгә, буранга.

Кочагыңа кысып сөйдең мине,
Чибәрем дип үптең күзләрне.
Чын күңелең белән сөю кирәк
Әйтер өчен матур сүзләрне.

Төште шәлем ап-ак кар өстенә,
Тоймыйм суыкны да буранны.
Иркәм кочагында эссе кояш,
Күмсә күмсен карлар урамны.

Бәхет тулы рәхәт вакытларны,
Их, кичерсәң иде гел генә.
Сузар идем татлы минутларны
Бер мизгелгә түгел, мәңгегә.

ТАШЛАМАГЫЗ ЯРЛАРНЫ

Күңел — якын, ара — ерак,
Ара — якын, күңел — ерак.
Нигә икән шулай була:
Мәхәббәт йөри урап?
Бәлки, арабыз еракка
Өзелеп сагындыра?
Уйлап йөреп көне-төне
Сарыга сабыштыра?
Пар аккошларның канатын
Давыллар каермасын.
Үлеп гашыйк булганнарны
Аралар аермасын.
Китмәгез ташлап еракка
Ярыгызны, гашыйклар!
Ерак ара аерса да,
Сүнми икән гыйшыклар.

ТАЛПЫНЫПЛАР КАЙТЫРСЫҢ

Ай нурлары уйный, йөзә
Зәңгәр күл өсләрендә.
Якты ай нурлары булып
Калдың син исләремдә.
Ай нурын мәңге сипсә дә,
Мәңге түгел сөюләр.
Сөю гом(е)ре кайчак кыска,
Авыр янып-көюләр.
Ташлап киттең еракларга,
Төрдең сары сагышка.

«Кайт инде, сагындым», — диеп,
Ничәләр яздым хатка.
Хат ташучы узган саен,
Җавап хатыңны көтәм.
Сагынырсың, талпынырлар
Кайтырсың — өмет итәм.

ӘКИЯТТӘГЕ ЯРНЫ ЭЗЛӘМӘ

Яшем узган, җыерчыклар куйган,
Мине кем яратсын, диясең.
Тормыш юлын ялгыз үтәрмендер,
Тапмам парны диеп көясең.

Якыннарга күңел күзеңне ач,
Кем соң карый сиңа җылырак?
Йөрмә әкияттәге ярны эзләп,
Чит яклардан урап бик ерак.

Үтә матурларны сайлама син,
Үтә матур, диләр, тиз уңа.
Кадерен бел үткән минутларның,
Гомер бит ул бигрәк тиз уза.

ТАКМАКЛАР

Әрәмәләр бигрәк куе —
Кермимен, чыгалмамын.
Синнән башка ярлар белән
Мәңгегә чуалмамын.

Әрәмә баланнарының
Җимешләре күп микән?
Озак көттем, ник килмәдең,
Әллә җаның юк микән?
Әрәмәлек бигрәк куе,
Керсәң, адашырсың да.
Ярын ташлап ятка китсә,
Бәлки, саташырсың да.
Әрәмәдә балан җыйдым,
Юкә җепләргә тездем.
Көтеп сине, зарык булдым,
Бик сагынсам да, түздем.
Әрәмәләр куе үсә
Суга якын булганга.
Сине уйлап җырлар җырлыйм,
Өзелеп сагынганга.

ҖЫРЛАП ЯШӘРГӘ ЯЗСЫН

Языйм әле җырларымны
Җырлыйсы килгән чакта.
Халык җырлап күңел ача,
Дусларым, безнең якта.
Җырлап калыйм, җан дусларым,
Әле җырлый алганда,
Мәхәббәт тойгыларымны
Матур көйгә салганда.
Җырлар җырлап яшәсәгез,
Картаймассыз гомергә.
Яшәргә язсын шатланып
Озак-озак гел бергә.

Җырлап күңелем юатам,
Бер ялгызым калганда,
Тормыш михнәтләре мине
Сагышларга салганда.
Күмим әле дусларымны
Моңга, җыр бәйләменә.
Шатлыклы җырларым сезгә —
Бүләк ял бәйрәменә.

ЯЛАН ЧӘЧӘКЛӘРЕ БИРЕРМЕН

Кышлар, язлар кайчан үтәр икән,
Җәйгә тиклем ничек түзәрмен?
Синең өчен генә чәчәкләрнең
Иң матурын тагын өзәрмен.

Җәйләр ерак диеп моңсуланма,
Җәйләр әле тагын килерләр.
Якты кояш нуры, җылы яңгыр
Җир өстенә чәчәк сибәрләр.

Сиңа охшаш чәчәкләрне эзләп
Хәтфә яланнарны буйлармын.
Чәчәкләрне назлап иркәләсәң,
Мине сөясең дип уйлармын.

Йолдыз алып төшеп бирер идем —
Оча алмыйм күккә, гүзәлем.
Мәхәббәтем, сиңа бүләккә дип
Ялан чәчәкләре өзәрмен.

ДӨНЬЯМНЫ ЯМЬЛӘНДЕРДЕҢ

Ак күбәләктәй очасың,
Сихри моңга уралып.
Сокланып гармун сузамын,
Мәхәббәттән нур алып.
Ак күбәләктәй очасың,
Җырлап-биеп, әйләнеп.
Йөрәгемә килеп кердең
Гомерлеккә бәйләнеп.
Башкасмны әйләндердең,
Үзеңә бәйләндердең.
Сагышта үткән кичләрне,
Көннәрне ямьләндердең.
Күңелемне сихерләде —
Бер көн торалмам синсез.
Гомерем сиңа бәйләнде,
Синсез дөнья да сансыз.
Татлы балдан да татлырак
Кайчак була ул әрем.
Мәңгелек күңел шатлыгым,
Гомерлек сөйгән ярым.

ПАР КҮГӘРЧЕННӘР ТӨСЛЕ

Үпкәлисең, сөйләшмисең —
Җаннарымны теләсең.
Ул миңа үлем җәзасы —
Син аны бик беләсең.
Ачу гомер кыскарта, ди,
Үпкәләшмичә яшик.

Назлы сүзләр белән генә
Бер-беребезгә дәшик.
Эшләреңне калдырып тор,
Кил, утыр яннарыма.
Әйтсәң бер назлы сүз, иркәм,
Хәл булыр жаннарыма.
Ачу тотмыйча сөйләшик,
Бозып яшәмик төсне.
Гөрләшеп, серләшеп яшик,
Пар күгәрченнәр төсле.

ТАШЛАР БУЛСАҢ, БАШЛАМА

Мин ташламам сине мәңге,
Син дә мине ташлама.
Саф күңелемне өзгәләп,
Ташлар булсаң, башлама.

Сагыш ярасы төзәлми,
Башкасы төзәлсә дә.
Сөю хисе һич сүрелми,
Аралар өзелсә дә.

Назларымнан читкә куймам,
Күңелемнән дә жуймам.
Күпме генә карасам да,
Күрепләр сине туймам.

Карап туймаслык чәчәгем,
Син — минем киләчәгем.
Үзкәсмә кадерлесең,
Юк ятка бирәчәгем.

АРТЫҢНАН КАРАП КАЛДЫМ

Алмагач ак чәчәктә —
Бакчаларга күз салдым.
Офыкларга күмелгәнче
Артыңнан карап калдым.
Кулъяулыгыңны болгадың,
Борылып ничә тапкыр.
Төшсәң сары сагышларга,
Хат язып мине чакыр.
Кош кебек очып барырмын,
Сагына калсаң, иркәм.
Назлы җил булып исәрмен,
Тәрәзәң ачсаң иртән.

СИКӘЛТӘЛӘР АША

Сикәлтәле була һәрчак тормыш,
Уйламадык, шома үтәр, дип.
Сикәлтәне шомартып атлыйбыз,
Шуның өчен дә без икәү бит.

Булса да еш өермә давыллар,
Рухыбыз каршы торырлык.
Көч таптык без, иркәм, синең белән
Ямьле, якты тормыш корырлык.

Бөтен авырлыкны җиңәрбез, дим,
Тик бер юлдан атларга кирәк.
Сикәлтәләр аша сикереп үтеп,
Пар тормышны сакларга кирәк.

ӘЗЕРСЕҢМЕ?

Бөдрә икән лә чәчләрең,
Кара икән кашларың.
Бер күрүдән син сылуны
Китте минем һушларым.
Күңел ышанмый һаман да,
Күзләремдә — күк томан.
Мин сине бик күптән инде
Беләмдер кебек сыман.
Мәҗнүн кебек гашыйк булдым,
Синең уйларың кемдә?
Сине, кадерлем, сөеклем,
Күрәсем килә көн дә.
Бәхеткә, шатлыкка күмче
Барасы юлларымны.
Йөрәгемне тәкъдим итәм,
Бир, иркәм, кулларыңны.
Әзерсеңме гомер юлын
Минем белән үтәргә?
Назларыңны бүләк итеп,
Бик бәхетле итәргә?

БЕРГӘ ҮТИК

Бөтен уем синең тур(ы)да,
Кичен йокларга ятсам.
Күз алларымда кебексең,
Иртән уяныл бассам.
Үзем дә аңлап бетермим,
Ни булды икән миңа?
Сизми дә калганмын икән,

Гашыйк булганмын сиңа.
Йөгерепләр менәр идем
Текә тау башларына.
«Яратам» дип язар идем
Шул тауның ташларына.
Син күбәләк кебек кызгә —
Кырларда очып йөргән.
Мин чәчәге шул яланның —
Сине шатлыкка төргән.
Бергә үтик тормыш юлын,
Ләззәтнең тәмен татып.
Бар дөнья безнең бәхеткә
Торсын әле шаккатып.

СУГЫШ ЯРАСЫ

Иң авыры дөньяларда —
Якыныңны югалту.
Сөйләп кенә кайгыларны
Мөмкин түгел аңлату.
Җәйләр үтте, кыр казлары
Очып китте күлләрдән.
Йөрәк сызлый, күңел елый,
Яшь түгелә күзләрдән.
Язлар җиткәч кошлар кайтыр,
Тик син генә кайтмассың.
Елмаеп ишекне ачып,
Бусагага басмассың.
Сугыш яралары калды
Йөрәгемнең түрендә.
Якты истәлегең, әткәм,
Күңелемнең күгендә.

БУЛМЫЙ ОЧЫРЫП

Уң кулыма кигән йөзегемне
Күптән инде сулга күчердем.
Туйда биргән бүләк яулыгыңны
Искән җилләр белән очырдым.

Әмма мәхәббәтне нишләтим соң?
Булмый гына оң(ы)тып, очырып.
Йөрәк, күңел сөярлек ярлар да
Адым саен тормый оч(ы)рап.

ҖЫР БЕЛӘН ӘЙТ СЕРЕҢНЕ

Алманы өзми кетәсең
Үзе алга төшкәнен.
Белгертмәскә тырышасың
Күзең миңа төшкәнен.
Мине күрсәң, яшерәсең,
Иркәм, күз карашыңны,
Әкрен генә эндәшәсең —
Ишетмим тавышыңны.
Кыю, батыр егетләрне
Ярата гелән кызлар.
Саф йөрәктән сөйсәң генә,
Күңелдә чыңлый кыллар.
Оялып, югалта күрмә
Гыйшык тоткан ярыңны.
Җырлар аша булса да әйт,
Сөйлә йөрәк зарыңны.

МӘҢГЕЛЕК ҖЫР

Гомер көзем килеп житте сымак,
Яшьлек язым калды еракта.
Үткән гүзәл яшьлек елларымны
Кайтара алмам инде юраң та.

Яшьлек елларым — йөрәк түрендә,
Мәңгелек җыр алар күңелдә.
Бакчада үскән купьеллык гөлгә
Яшь чакларымны охшатам гел дә.

ЙӨРМИМ ЯЛЫНЫП

Үрелмим мин йолдызларга:
Беләм буем житмәсен.
Инде биргән кодрәтеннән
Ходай мәхрүм итмәсен.
Көчем житкәнчә яшимен,
Ярышмыйм берсе белән.
Көнләшмим, кара да янмыйм —
Күңелем керсез гелән.
Тәкәбберләргә ялынып,
Йөрмим алдында биеп,
Булыр-булмаска баш иеп,
Дус булыйк әле диеп.
Масаеп та йөргәнем юк,
Чөймим күккә борынны.
Ходаем үзе күрсәтер
Үземә тиеш урынны.

ӘЙТӘЛМӘДЕМ ӘЙТЕР СҮЗЕМНЕ

Күк томаннар капладымы әллә
Шулчак минем күңел күземне?
Багалмадым йөзкәеңә туры,
Әйтәлмәдем әйтер сүземне.

Җылы сүзең, назлы күз карашың
Әле булса хәтеремдә, иркәм.
Хыялымда син янәшә генә,
Кичен ятсам, уянсам да иртән.

Бәлки, онытылыр тора-бара,
Дигән идем, ерак булса ара.
Асрылышу сагышыннан калды
Мәңге төзәлмәслек тирән яра.

КАДЕРЛЕ УФАМ

Башкортстанның йөрәге —
Кадерле гүзәл Уфам.
Ямь-яшел урамнарына
Көн дә сокланып узам.
Биек йортлар күтәрелә,
Зәңгәр күккә үрелеп.
Уфам көннән-көн яшәрә,
Матурлана күренеп.
Сокланып, сөеп яшибез
Шушы гүзәл калада.
Гүзәллекне, матурлыкны
Күрә сабый бала да.

Уфаның якты кояшы
Җылыта һәммәбезне.
Мәскәү матур Уфадан дип,
Ышандырмагыз безне.
Уфамда җан җылылыгы,
Иссә дә салкын җилләр.
Үз Уфам — бәхет тәхете,
Кирәкми башка җирләр!

БУЛГАНЫНА РӘХМӘТ УКЫЙМ

Тиңем белән яшәлгән һәр көнем —
Минем өчен үзе зур бәйрәм.
Күңелем бәхет күкләрендә йөзә,
Бергә җыелганда гаиләм.

Якыннарым яннарымда булса,
Өй эчебез тула җыр-моңга.
Шатлык яшем яшермим дә хәтта,
Сөенәмен ризык-сый мулга.

Кешеләрдән ким-хур яшәмимен,
Өстеннән дә очмыйм дөньяның.
Булганына рәхмәт кенә укып,
Тыныч яшәсәнә, дим, җаным.

Шакымасын кайгы ишегемне,
Хак Тәгаләм, үтенеп сорыймын.
Имин тормыш, исәнлек һәм саулык —
Һәммәбезгә шуны юрыймын.

САГЫНУ ЖЫРЫ

Далада йөрим уйланып,
Җил тарый чәчләремне.
Уйлар уйлап, җырлар җырлап
Таратам хисләремне.
Чит җирләрдә яшәү авыр,
Белмисез хәлләремне.
Җилләргә җырымны кушып,
Җибәрәм хәбәремне.
Туган ягымны саг(ы)нып,
Узып бара елларым.
Онытылмас мәхәббәтем,
Җырлы чишмә юллары.
Туган авылда чишмәләр
Тауларны чыга ярып,
Туктамый, чылтырап ага,
Күңелне моңга сарып.
Истә һәрбер карыш җире,
Сукмаклары, юллары.
Сагыну-сагышлар белән тулы
Читтә үткән елларым.

КҮҢЕЛДӘН ҖЫР ТҮГЕЛӘ

Җырлыйбыз да, биибез дә,
Моңга тулган өебез,
Җырламый ничек түзәсең,
Бигрәк моңлы көебез.
Җырламый һич яшәп булмый,
Җыр күтәрә күңелне,

Сөйгән ярың янда булса,
Яшәвс дә күңелле.
Тыңлый белсәң күңел биреп,
Жыр-моң бизи тормышны.
Юкка гына сөймибез лә
Сандугач — сайрар кошны.
Гөрләвекләр җырлап ага,
Ямьләтеп җылы язны.
Кошлар да кушылып сайрый,
Иш итеп моңлы җырны.
Ник туганга үкенгәндәй,
Яшәмик гамьсез булып.
Тормыш юлларыбыз үтсен
Өзелмәс моңга тулып.
Үкенмим мин үткәннәргә,
Үкенерлек түгел дә:
Гомер буе моңлы җырлар
Йөрәгемнән түгелә.

ТУГАНМЫН ЯШЬНӘР ӨЧЕН

Яшим әле, яшьним әле:
Туганмын яшьнәр өчен.
Күкрәп, яшьнәп яшәр өчен,
Җитәрлек куәт-көчем.
Ялкыным күзгә күренми,
Әмма мин яшим янып.
Сүнмәс учак кебек дөрли
Тынгы белмәгән җаным.
Йөрәк җылымны мин шулай
Җырым белән таратам.

Җырларда — сөю хисләрем,
Бар галәмне яратам.
Дәртем-дәрманым әлегә
Ташып тора күңелдә.
Җырларыма сезне кушам,
Истәсез, дуслар, гел дә.

БЕРКЕМ ОЗАТЫП КАЛМЫЙ

Дога кылып озатып калмый берәү —
Уңар микән инде юлларым.
Хәерле көн, изге юллар теләп,
Болгап калмый әнкәй кулларын.
Газиз әнкәм утырткан шомырткай
Ак чәчәкләр яз саен ата.
Исәннәр бит кайчан да бер очраша,
Китсә, кабат әйләнеп кайта.
Әнкәй күзен йомды мәңгелеккә,
Гомергә җитәр сагышы.
Бер күрешергә тилмереп үтәр
Калган көннәремнең агышы.
Әнкәй-бәгърем күчте бакыйлыкка,
Мәңгелеккә китте калдырып.
Кайтмас инде, күпме әрнесәм дә,
Гел көтсәм дә күзем талдырып.
Изге кешем, бердәнберем идең,
Серләремне сөйләр әнкәем.
Сагыну-сагышлардан өзгәләнеп,
Яшь күз нуркаең — бәбкәең.

ЯЛГЫЗ ҮТӘ КҮРМӘГЕЗ

Чәчегез бергә үрелгән,
Ялгыш сүтә күрмәгез.
Барасы киләчәк юлны
Ялгыз үтә күрмәгез.
Гөрләшеп, көлеп яшәгез,
Күңелле үтсен көннәр.
Гыйшыгыгыз дөрләп торсын,
Бәхетле үтсен төннәр.
Елмаеп яшәү гел генә,
Ул гомерне озайта.
Парлап үтәсе юлларны
Бәхет, шатлык озата.
Җил-давыл да кайчак кубар,
Түзем булырга кирәк.
Яннарында парың булса,
Чыдый ул, дуслар, йөрәк.

УЙНА, ДУСКАЙ, ГАРМУНЫҢНЫ

Уйна, дускай, гармуныңны,
Көйләрең синең моңлы.
Көе матур булса гына,
Җырлыйсы килә җырны.
Моңлы көйләр яши мәңге,
Гасырлардан гасырга.
Халык җырлый зур шатлыктан
Йә кайгысын басарга.
Сагыштан сызласа йөрәк,
Күңелдә туса шикләр.

Җырлар аша аңлаталар
Сөю хисен гашыйклар.
Кипмәсен моң чишмәләре,
Аксын дәрьялар булып.
Халык эчсен татлы суын,
Аксын дөньялар тулып.
Салып булмый үлчәүләргә
Халык моңының көчен.
Ачылсын яңа көйләрең
Ватан һәм милләт өчен.

СӨЯРГӘ КЕШЕМ БАРДА

Уйлый идем сөю хисе
Була дип тик яшьләрдә.
Миндә дә шул ут кабынды —
Белмим хәзер нишләргә.

К у ш ы м т а:
Сөйим әле сөялгәндә,
Сөяргә кешем барда;
Язмышыма рәхмәтлемен:
Сөенәм ишем барга.

Сөю бит ул — көчле давыл,
Ургыла ташкын булып,
Тойгы-хисләрнең чиге юк,
Ургыла ярдан тулып.

К у ш ы м т а.

ЧӘЧӘК ЧАГЫНДА ҖӘЙНЕҢ

Безнең арада дуслыкмы
Әллә олы сөюме?
Үзем дә аңлап бетермим,
Әллә яшып-көюме?
Сирень чәчәккә төренә
Язның матур мәлендә.
Минем дә күңел чәчәктә,
Мин дә сирень хәлендә.
Кояш чыкса, чәчәкләрнен
Ачыла таҗы балкып.
Сиңа насыйп булган чәчәк
Чыга ул үзе калкып.
Син миңа насыйп чәчәгем,
Таҗың-колачың җәйдең.
Очрадым да гашыйк булдым
Чәчәк чагында җәйнең.

ӘГӘР СӨЙСӘ

Янгыркаем, нигә инде
Явасың да явасың?
Җан сөйгәнем тагын килмәс,
Минс утка саласың.
Өченче көн дә, кичә дә
Явасың да явасың.
Инде көтеп зарык булдым,
Сөйгән ярым кайда соң?
Туктамыйсың атна буе,
Ник хәлемә кермисең?

Сары чәчәктәй саргайдым,
Син бит аны күрмисең.
Киртә түгел яңгыры да,
Сөю тылсымы тисә,
Йөг(е)рә-чаба килер иде,
Әгәр күңеле сөйсә.

КИРЕ КАЙТМЫЙ

Ничек тырышсаң да югалтмаска,
Якыныңны беркөн югалтасың.
Барыбыз да бер китәбез диеп,
Күңелеңне елап юатасың.
Туган ягын ташлап кошлар китә,
Әмма алар язын кайталар.
Якыннарың китә мәңгелеккә —
Кабер куенына яталар.
Күпме еласам да, кире кайтмый
Изгеләрдән-изге зат — апам.
Сизми дә ул, белми хәлләремне —
Ут-сагышларында мин янам.

МИН ДӘ ШУНДЫЙ БУЛГАНМЫН

Син тугансың салкын көздә,
Балан өлгергән мәлдә.
Шуның өчен язмышың да
Ачы булганмы әллә?
Тапканың — хәләл көчеңнән,
Хәрәмнән ерак тордың.

Тайпылмадың, абынмадың,
Туры юллардан бардың.
Сине Ходай яраткандыр
Бәхет түгел, эш өчен.
Авыр йөкне тарта-тарта,
Кулыңнан китте көчең.
Ярый әле шундый булдың,
Сокланып искә алам.
Сиңа охшап, әнкәм, шундый
Булганмын мин дә — балаң.

ЯШӘМӘДЕМ КӨЕП

Төшенкелеккә бирешмим,
Утырмыйм башны иеп.
Үткән гомер юлларымда
Яшәмәдем мин көеп.
Утырмыйм сорап Ходайдан,
Күктән яуганны көтеп.
Җәфаласа да күңелне
Ачы сагышлар өтеп.
Кечкенә шатлыгымны да
Тау итеп кабул итәм.
Һәрбер таныш кешемне дә
Мин бик тә якын итәм.
Туктап калмадым юлымда,
Яуса да бозлар коеп.
Яшимен дөнья ләззәтен
Күңелем белән тоеп.

СУСЫЗ ЧИШМӘ БУЛАЛМЫЙ

Тынгы тапмыйм йөрәгемә,
Нәрсәдер миңа җитми.
Газапланам, йоклый алмыйм,
Уйлар башымнан китми.
Әллә инде язып беттем,
Язарга сүз табалмыйм.
Иҗат чишмәм кипте мәллә,
Сусыз чишмә булалмый.
Язасын язып бетмәдем,
Кайчан бетәр язылып?
Чылтырап тагын агармы,
Иҗат чишмәм ачылып?
Күңелем нәрсәдер эзли,
Табалмый, эзләсәм дә.
Илһам килер, Алла бирсә,
Соңласа, көзләсә дә.
Чишмә чыга тауны ярып,
Чыкмый шул коры җирдән.
Ичмасам даруы да юк
Шул шигырь дигән «чир»дән.

ӨМЕТЕМНЕ ӨЗМӘДЕМ

Сиреньнәрдән чәчәкләреңнең
Биш таҗлысын эзләдем.
Килер сөю көне диеп,
Өметемне өзмәдем.
Очраттым бер асыл кошны,
Күңелем эзләгәнне.
Ничек сүз башларга белми,

Үзәгем өзгәләнде.
Үзем күрдем, үзем таптым
Күңел тарткан ярымны.
Алтын тауга алмаштырмам
Җандай күргән парымны.
Чишмәләр булып агармын,
Әгәр син суын эчсәң.
Дулкыннар булып кочармын,
Әгәр син каршы йөзсәң.
Чишмә булып чылтырармын,
Син моңын отып алсаң.
Нурларыңнан наз алырмын,
Кояшым булып янсаң.

ГОМЕРЛЕК БУЛА КҮРСЕН

Мәхәббәт керде күңелгә,
Үзем сүз куштым башлап.
Шул көннән соң күңелемнән
Чыгарып булмый ташлап.
Җаның сөйгән ярың белән
Аерылырга язмасын.
Өзелеп сөйгән үз ярыңны
Берүк ятлар алмасын.
Кая барсам да, иярә
Арттан күләгә кебек.
Тоямын: иркәм дә чынлап
Мине яраткан кебек.
Инде бу сөю-мәхәббәт
Гомерлек була күрсен.
Алда барасы юлларга
Ходаем гөлләр үрсен.

ЯШЬЛЕК ИСТӘЛЕГЕ

Яшьлек истәлеге итеп
Утырттык без кушкаен.
Инде күп еллар үтсә дә,
Онытылмый, дускаем.
Матур, зифа булып үсте
Без утырткан каеннар.
Аерылдык та, күрешәлми
Үтәләр айлар, еллар.
Күз яшьләремне яшерәм,
Күңелләрем тулса да.
Йөрәгемә бик якынсың,
Ара ерак булса да.
Каеннар үскәннәр биек,
Янәшә көн күрәләр.
Яшьлек мәхәббәтем булып
Төшләремә керәләр.

СӨЙГӘН ЙӨРӘК ЯЛГЫЗ БУЛМЫЙ

Сөйгән йөрәк ялгыз булмый,
Башың ялгыз булса да.
Сагышларга бирешми ул,
Әрнүләрдән сулса да.
Бирешә торган түгелбез,
Әле без менә дигән.
Күңелебез – гөлбакчада,
Чәчәк күлмәген кигән.
Иң көчле хис дөньяларда
Мәхәббәтнең давылы.

Юк аңа каршы торырлык
Име-томы, даруы.
Ышанычың калмаса да,
Өметең өзелмәсен.
Мәңге сүнмәс сөю утың,
Ялкының сүрелмәсен.
Гомер буе яшь-яшь кала,
Картаймый сөю хисе.
Яшәешкә канат куя
Гашыйклык, сөю көче.

ЮЛЛАР ДА ТӨРЛЕ БУЛА

Юллар була әллә ничә чатлы,
Төрле якка алып китәләр.
Кемнең юлы биек күктә булса,
Кемнедер тәмугка илтәләр.
Кемгә килә бәхетләр өелеп,
Кемне үтә ерактан урап.
Булмый икән, кояшың чыкмаса,
Бер Ходайдан ялварып сорап.
Әнкәем дә китте мәңгелеккә
Кайсы юлдан хәзер атлармын?
Изге догаларны кем өйрәтер,
Кемнән генә отып ятлармын?
Әткәй, әнкәй күрсәткән юлдан без
Адашмыйча атларга тиеш.
Үзгәртмичә гореф-гадәтләрен,
Калдырырга иде саф килеш.

ҖЫРЛЫЙК БЕРГӘ ГОМЕРГӘ

Очып килдең, сандугачым,
Күңелемә моң өреп.
Әллә ни эшләттең мине,
Йөрәк түремә кереп.
Сайрар сандугачлардан да
Моңлырак сөйгән ярым.
Кайчан гына җырласа да,
Миңа багышлый җырын.
Мәңгелек тормыш парымны
Очраттым язымда.
Җан сөйгәнем, мәхәббәтем
Янәшәмдә, янымда.
Әйдә, үзем дә кушылыйм,
Җырлыйк гомергә бергә.
Без килгәнбез бәхет өчен
Шушы хәерле җиргә.

ГАРМУНЧЫБЫЗ СЫЗДЫРА

Күңелкәем тулы шатлык —
Ник әле сөенмәскә?
Гармун сыздырып торганда,
Ник әле биемәскә?

Кушымта:
Гармунчыбыз, әй, сыздыра,
Без тыпырдап биибез.
Шатлык, бәхеттә яшәсен
Туып-үскән илебез.

Сикереп төшеп бер биюе,
Бер жырлавы — бер гомер.
Күпме генә бирелсә дә,
Жырлап үтсен бар гомер.

Кушымта.

Жырлыйк әле, биик әле,
Канатлансын күңелләр.
Биючеләр картаймый, ди,
Озын булсын гомерләр.

Кушымта.

Тормыш ямьле, дөнья матур,
Балкый туган илебез.
Сезне дә ямьгә күмәрбез,
Кунак булып килегез.

КҮҢЕЛЕҢ ТАРТМЫЙ ИКӘН

Асыл кошым, сандугачым,
Күңелемә якынсың.
Сизеп торам, тик син генә
Ни өчендер салкынсың.
Назлыйсың да иркәлисең,
Әмма күңелем тоймый.
Күңелең ятмаган ярны,
Күрәсең, сөеп булмый.
Яратмасаң — араны өз,
Әйләндермә башымны.
Очратырмын сөя белгән
Мин дә йөзек кашымны.

КАЙДА ҮСТЕҢ, ЧИБӘРКӘЙ?

Күзләрең — кара карлыган,
Иреннәрең — җиләктәй.
Чәчкәйләрең толым-толым,
Кайда үстең, чибәркәй?
Җемелдиләр үләннәрдә
Чык бөртекләре иртән.
Йөзеңдә чык бөртекләре,
Кояш нурлары, иркәм.
Сөйкемлесең, акыллысың,
Син, иркәм, оҗмах кошым.
Тәүге тапкыр күрүдә үк
Китте дә куйды һушым.
Һәрбер чыкта бәллүр төсе
Иртән кояш нурында.
Күңелдән чыккан җырларым
Син сөеклем турында.

ҖӘЙГЕ УРМАН

Илне сагынып кайткан кошлар оясы,
Җәйге урман — әкият дөньясы.
Мин үзем кошлардан өйрәндем җырларга,
Яратып йөрим урман-кырларда.

Агачтан агачка бер кош очып куна,
Ул да булса — сандугачым икән.
Өзелепләр сайрый — ни әйтергә уйлый,
Әллә зарын миңа сөйли микән?

Мин аңладым хәлеңне, сайрар кошчыгым,
Гыйшык утында син дә янасың.
Сөю-сагыш моңнарын көн-төне сайрап,
Минем күңелне утка саласың.

Сүндермикче өметне, сайрар кошчыгым,
Безнең урамда кояш чыгар ул.
Сагыш-кайгыларга түзә өйрәнгәнбез,
Чыдаган йөрәк мәңге чыдар ул.

ТУЙ ҖЫРЫ

Ак күбәләк — кәләше лә,
Бөтереләә әйләнеп.
Үзенең сөйгәне белән
Чәче чәчкә бәйләнеп.
Әйтерсең лә таң кояшы,
Нур чәчәләр күзләре.
Шушы матур туй көнендә
Иң бәхетле үзләре.
Булсын туйлар, килсен бәхет,
Килмәсен бәла-каза.
Түр башында кунак булып
Утырсын әле кода.
Утырсын әле иң түрдә
Кодагый да янәшә.
Кайна-кайнатагыз белән
Дус-тату булып яшәң.
Бала-чагалар өй тулып,
Шаулап торсыннар һәрчак.
Күңелләрне юатырга
Алар бит тере курчак.

ОНЫГЫМ

Баланың баласы, диләр,
Җиләктән тәмле.
Бәби гүләгәнгә шатбыз,
Өй эчебез дә ямьле.
Инде, сабый, бәхетле үс,
Зур булып, таза булып,
Яшә мәрхәмәтле булып,
Күңелең назга тулып.
Озын булсын, якты булсын
Үтәсе юлың, балам.
Тоеп яшә дөнья кадерен,
Алдыңда — иркен алан.

ЯШӘСӘҢ ИДЕ ЯШӘРЕП КЕНӘ

Яңа гына коеп яуган яңгыр
Юып узды бөтен тузанны.
Тойсаң иде шушы яңгырларның
Күңел сагышларын юганны.

Яңгырдан соң үләндәй булып
Купырыласа яшьлек елларым.
Бирешмәс тә иде йөрәккәем,
Өзелмәс лә күңел кылларым.

Яңгырдан соң үләннәрдәй булып
Яшәсәңче яшәреп кенә,
Булса иде җыерчыкларны,
Көмеш чәчне яшерер кенә.

Бар булмышы белән үзгәрешсез
Алыр идем яшьлек елларын.
Әйтер идем: миңа унсигез яшь,
Җуеп булса маңгай сырларын.

Гомеркәйләр эзсез генә узмый,
Үткәннәр ул мәңге хәтердә.
Сикәлтәле яшьлек юлларымнан
Теләр идем кабат үтәргә.

САУМЫСЫЗ, АВЫЛДАШЛАР!

Саумысыз, туганнар, дуслар,
Саумысыз, якташларым.
Мин бит монда туып-үстем,
Монда нигез ташларым.
Ничек кенә яшисез соң,
Нинди эш бетерәсез?
Бөтен эшкә дә вакытны
Ничек соң җиткерәсез?
Хәлләрегез ничек кенә,
Саусызмы-тазасызмы?
Шулай күңел ачарга
Вакытлар табасызмы?
Йорт-кураларыгыз төзек,
Урамда яшел үлән.
Тик сәлам бирергә юклар —
Калмаган күрше-күлән.
Шулай төзелгән дөньясы —
Гомер мәңгелек түгел.
Алда зур бәхетләр баглап,
Юанып яши күңел.

Шуның белән дә кызыктыр
Авылымның тормышы.
Ходай кушканча төзелә
Һәр кешенең язмышы.
Йортлар учагы сүнмәсен,
Саклансын нигез-ташлар.
Нәсел-ыру исән булсын,
Сау булсын газиз башлар.
Күрешеп торырга язсын
Бәйрәмнәрдә булса да.
Күңел гөлләре сулмасын,
Бакчаныкы сулса да.

ЗИФА КАЕННАРЫМ

Оялган кәләшләр сымак,
Каеннар баш игәннәр.
Иңнәренә бик килешле
Туй күлмәге кигәннәр.
Яфраклары шыбырдыйлар
Көзге ачы җилләрдә.
Коелалар берәм-берәм,
Алтын сибеп җирләргә.
Тибрәләсең, ак каеным,
Сары шәлеңне салып.
Ни эшләрсең салкын кышта
Япа-яланбаш калып.
Зифа каеннар шикелле
Озаклар яшәр идем.
Көзге мәлдә саргайсам да,
Язын яшәрә күңел.

СӨЙМӘСӘҢ, ӨЗ АРАНЫ

Басмада керләр чайкадым,
Төшердем сәгатемне.
Бер түгел, бик күп сынадым,
Кадерлем, гадәтеңне.
Үзең өзелеп сөям, диден,
Атна буе килмисең.
Мин сагынып көн дә көтәм —
Әллә шуны белмисең?
Минем йөрәгем таш түгел,
Кирәкми җәберләргә.
Йөрәк кылы тиз өзелә,
Чыдамый әрнүләргә.
Өмет салма йөрәгемә,
Сөймәсәң — өз араны.
Салма япь-яшь йөрәгемә
Төзәлмәслек яраны.

ТӨШЕРМӘ КАНАТЛАРЫҢНЫ

Омтылып яшә гел генә
Биеклеккә, тауларга.
Язсын сиңа кешеләрнең
Мәхәббәтен яуларга.
Төшермә канатларыңны,
Авырлыклар килсә дә,
Килгән сагыш газаплары
Йөрәгеңне телсә дә.
Дөнья да бер килеш тормый,
Була шул төрле көннәр.

Була шатлыктан исергән,
Йокысыз узган төннәр.
Болытлы көнгә алмашка
Чалт аяз көннәр туа.
Караңгы шомлы чакларны
Яңгырлы көннәр юа.
Озын, якты булсын иде
Безнең мөнәсе үрләр.
Дөньяны сөеп яшәсәк,
Тормышлар гелән гөрләр.

КӨННӘР ТӨРЛЕЧӘ КИЛӘ

Юллар йөртә төрле якка,
Арыта да кайчакта.
Дуслар да күбәеп китә
Акча барда, бай чакта.
Юлларның төрлесе була —
Уңган, уңмаган чагы.
Көннәр дә төрлечә килә:
Була карасы, агы.
Бәхет тә тормый елмаеп,
Гел генә колач җәеп.
Әллә Ходай мине сөйми,
Әллә үземдә гаеп.
Шулай да тырышкан булам
Яшәргә кешеләрчә.
Артык байлык җыймасам да,
Көн итәм эшчеләрчә.

СИНЕҢ БЕЛӘН АТЛАДЫМ

Сине өзелеп сөям, дидең,
Мин дә кире какмадым.
Житәкләшеп алга таба
Синең белән атладым.
Син елмайдың да күз кыстың,
Сөеп билемнән кочтың.
Тибрәлде күңел канатым,
Әйтерсең, күккә очтым.
Ничә ел инде атлыйбыз
Бергәләп озын юлдан.
Күңелле үтә гомерләр,
Тормаса да бал-майдан.
Үкенмим сине сөйгәнгә,
Сайлаганга яр итеп.
Ходаем сине яраткан
Миңа гына пар итеп.

МИН – АВЫЛ КЫЗЫ

Мин — авылның гади кызы,
Авылда туып-үскән.
Шуңа минем күңелемә
Сандугач моңы күчкән.
Мин жыр-моңсыз яши алмыйм
Бер көн дә, бер сәгать тә.
Балачактан кереп калган
Әллә инде гадәткә.
Мин жырлыймын котлап сезне
Туган көн, туйлар белән.

Мин, дусларым, сезнең алда
Иң изге уйлар белән.
Менә-менә, мин җырлармын,
Биек таулар үренә.
Моң булып үрелсен җырлар
Күңелегез түренә.

ТЫРЫШАМ БИРЕШМӘСКӘ

Сагышларга, авырлыкка
Тырышам бирешмәскә.
Торышыма карап дуслар
Мөмкин дә килешмәскә.
Эчем тулы ут булса да,
Тыштан көләм, елмаям.
Бу тиклем дә көч, түземлек
Бирә соң Ходам каян?
Яшерен генә сызам эчтән,
Зарланмыйм һичберкайчан.
Күңелем тәмам тулышса,
Бик сирәк серем ачам.
Серешне дә аңлатырга,
Чишәргә чын дус кирәк.
Тугры, ихлас булган дуслар
Сер саклаучылар сирәк.
Кемгә кирәк синең зарың,
Әче яшь тамчыларың.
Башкача күрсәтмә, Тәңрем,
Яшен-ут камчыларың.

ШИҢМӘС ГӨЛЕМ

Туган көнең белән котлап сине
Җырлыйм бүген шушы җырымны.
Бүләк итәм сиңа мәхәббәтем,
Күңел назым, йөрәк җылымны.
Бүген генә түгел, гомер буе
Урының булды йөрәк түрендә.
Үрмә гөлләр булып мәңгелеккә
Үрелдең син күңел түренә.
Мәңге шиңмәс гөл-чәчәгем, иркәм,
Гомерем буе сиңа сокланам.
Күңел гөлең гомергә яшь булсын,
Иркәләргә һич тә соңламам.

СӨЮ САФ БУЛСА

Ничек аңлатырга, ни өчен соң
Сөйгән яр ул була бер генә?
Әллә инде аңлата алмаслык
Ул матур хис, сихри сер генә.

Шатлык-көенече белән бергә
Сөю — тынгысызлык дөньясы,
Гомер буе озатып йөри синс,
Күңелнең юк мәңге тынасы.

Онытыр идем, оныта алсам,
Җавапсыз мәхәббәтне, сөюне.
Теләмәс идем сөю учагында
Газап чигү, янып-көюне.

Мәхәббәт ул матур була шунда:
Хисләр тигез, сөю хак булса.
Сөю гөле чәчәк атар күк(е)рәп,
Тойгылары әгәр саф булса.

ГОМЕРЛЕК ЯЛГЫШЫМ

Онытырсың дигән булдың,
Оныту җиңел дисеңме?
Онытыр идем гомерлеккә,
Оныталсам синең исемне.
Өметләрем күптән сүнде,
Күңел инде шуңа күнде.
Хыял дингезендә йөзеп,
Яшьлек кире кайтмас инде.
Сәгать телләре бик әкрен
Әйләнәләр шул көткәндә,
Көтү-сагыш җәзалары
Җан-бәгыреңне өткәндә.
Күз яшемнең һәр бөртеге —
Ул, җаным, синең сагышың.
Сине өзелеп сөюем дә
Булды гомерлек ялгышым.

БӨТЕРЕЛӘ ТИРӘМДӘ

Ап-ак мамык карлар кунган
Агачлар кәүсәсенә.
Коела алар иркәмнең
Дулкын-дулкын чәченә.
Кар бөртекләре очалар
Бөтерелеп тирәмдә.

Йә кочып ала, йә үбә —
Бөтерелә иркәм дә.
Син бит минем ап-ак карым,
Син тәүге сөйгән ярым
Диеп, мин дә аны кочаклыйм,
Минем сөйкемле парым.
Бөтереләбез икәүләп,
Яуган карга уралып.
Җитәкләшеп атлыйбыз,
Мәхәббәттән нур алып.

ҖУЕЛМЫЙ ХӘТЕРДӘН

Гомерем буе яраттым
Шул табигать кочагын,
Коешлы, хәтфә япанда
Үтте лә балачагым.
Шаулап торган каенсарым,
Алтын арыш келәме,
Күз алдымда яланымның
Хәтфә яшел үләне.
Ә җиләкләр, ә җиләкләр —
Кызыл мәрҗән төймәләр.
Җуелмый һич тә хәтердән
Печән чапкан өмәләр.
Гомернең гүзәл вакыты —
Бала, яшүсмер чагым.
Чыкмассың мәңге исемнән,
Сөекле туган ягым,
Күңел түрендә саклана
Кадерле бала чагым.

БУЛМЫЙ ШУЛ ТӨЗӘТЕП

Идел буйларына бардым,
Карап тордым суларга.
Ялгышларны нигә инде
Искә алып уйларга.
Кага-кагына ярларга,
Дулкыннар югалалар,
Саубуллашып минем белән,
Еракка юл алалар.
Дулкыннарга ияреп
Яшьлек китә суларга.
Нигә искә төшерергә,
Үткәннәрне уйларга?
Кызганыч та, үкенеч тә
Яшьлекнең ялгышлары.
Кайтарыплар булсын иде
Шул дулкын агышларын.
Булмый шул төзәтеп
Яшьлегем ялгышларын.
Туктатып та булмый икән
Бу гомер агышларын.

«ИЗГЕ АЙ»

Сагынып сезне, дусларыбыз,
Ерак җирдән киләбез.
Сез дә безне бик сагынып
Көтәсез дип беләбез.
Иң мөһиме — җырлар белән
Алдыгызда «Изге ай».
Шатланып килеп җитәбез

Килеп чыккан саен җай.
Мөселман кардәшләребез,
Без сезне яратабыз.
Сезне күреп, җырлар җырлап
Сагышны таратабыз.
Ярый әл дә җыр яраткан,
Моң сөюче дуслар бар,
Күңелләргә моң салырдай
Сайрап торган кошлар бар.
Күңелемдә моңым сүнмәс
Сез, тамашачым, барда.
Очрашып торырга язсын,
Үтмәсен гомер зарда.

БЕЛМӘДЕМ НИ УЙЛАРГА

Язмыш безне очраштырды
Шушы озын юлларда.
Бәхетемме, язмышыммы —
Белмәдем ни уйларга.
Бер күз аттың, очкын салдың
Яшь, гамьсез күңелемә.
Тәкъдим иттең йөрәгенне
Икенче килүеңдә.
Кирс какмадым тәкъдимең,
Баш идем, күзем йомдым.
Җаныкаема урын тапмый
Сөю утында яндым.
Иң бәхетле җир йөзендә
Мин дә син — без икебез.
Яшәрбез җырлап, гөрләшеп,
Имин булсын илебез.

КИРӘК ШИФАЛЫ ҺАВА

Чыгып басам бакчабызга
Кояшлы таңнарымда.
Җемелди чык тамчылары
Гөлчәчәк таҗларында.

К у ш ы м т а:
Таң нурлары, таң сулышы
Гашыйк йөрәккә дәва.
Кирәсең мәхәббәткә дә
Кирәк шифалы һава.

Карыймын да чәчәкләргә,
Ислимен сөйгәнемне.
Белсә сөйгәнем дә ул дип
Җан атып көйгәнемне.

К у ш ы м т а.

Өзеп алдым да чәчәкләр,
Киттем иркәм янына.
Синең өчен, дим, җәл түгел:
Бирер идем җаным да.

К у ш ы м т а.

Очкын кабынды күзендә,
«Синнән башка яши алмыйм,
Сөям! — диде. — Үзем дә,
Артыңнан тотам калмыйм».

К у ш ы м т а.

ТӨШЕМ ДӘ, ӨНЕМ ДӘ БЕР

Әзер идем йөрәгемне
Сиңа ярып бирергә.
Ә син никтер минем янга
Теләмәдең килергә.
Буш өметләргә ышанып
Узды яшь гомерләрем.
Башка бер ярны да якын
Итмәде күңелләрем.
Күпме сөюләрдән, наздан
Мәхрүм үтте төннәрем.
Узды ялгыз, ямансулап,
Сагышларда көннәрем.
Инде күптән сүнде өмет,
Башланды гомер көзем.
Яшьлек чагымдагы кебек
Нур чәчеп тормый күзем.
Хәзер инде миңа бары:
Көнем дә, төнем дә бер.
Яшим истәлекләр белән,
Төшем дә, өнем дә бер.

ТАЛДЫРМА БЕЛӘГЕМНЕ

Сайлый-сайлый төймәләрне,
Тезәм бию көйләрен.
Биесеннәр туган көндә
Дер селкетеп өйләрен.
Гармун күрекләре сөйли
Минем уй-теләгемне.

Сөям диеп әйтче, иркәм,
Талдырма беләгемне.
Яшә, иркәм, сау-сәламәт,
Бәхетле булып гел дә.
Ходай биреп озын гомер,
Котларга язсын ел да.

ҖЫРДАН МӘҢГЕ СҮРЕЛМӘМ

Күңелемнән чыккан җырлар сезгә,
Туганнарым, якын дусларым.
Фикерләрем күңелемдә булса,
Моңны сездән отам, кошларым.
Күңелемдә булган хисләремне
Җырым аша сезгә җиткерәм.
Шушы моңнар һәм җырларым белән
Күп йортларга барып мин керәм.
Җыр-моң бит ул чишмә суы кебек,
Ургыла да күңел төреннән.
Гомер көзем җиткән чагында да
Мәңге сүнмәм, җырдан сүрелмәм.

МӘХӘББӘТНЕ САКЛАСАК

Бер күз сирпеп карадың да
Мин гашыйк булдым үлеп.
Бирергә әзер идем мин
Ярты җанымны бүлеп.
Гүя син матур гөлчәчәк —
Туялмыйм һич тә карап.

Сыйпыйм иркәм чәчләреңне,
Толымнарыңны тарап.
Үссен, гомергә сулмасын
Күңелдә гөлчәчәгем.
Бул син иркәм, күңел назым,
Гомерлек киләчәгем.
Үкенмибез, гомер буе
Бер сукмактан атласак.
Бергә булырбыз мәңгегә,
Мәхәббәтне сакласак.

ЕЛМАЙМЫЙ БӘХЕТ КОШЫМ

Кышлар үтеп китми салкыннарсыз,
Күз көннәрс булмый яңгырсыз.
Дөнья шулай төзелгәндер инде —
Гомерләр дә үтми ялгышсыз.
Йә ялгыштан гашыйк буласың да
Төзәлмәслек яра табасың.
Гашыйк булып янып-көясең дә
Кайгыларга башың саласың.
Өмет учагым сүнмәгән әле,
Һаман көйри йөрәк түрендә.
Миңа насыйп асыл таш ятадыр,
Бәлки, суда йә тау үрендә.
Өмет учагым сүнмәгән әле,
Килер бәхет, килер бер заман.
Язмышымны Ходаем үзгәртер,
Шул өметтә яшим мин һаман.

ЭЗЛӘМӘСӘҢ ДӘ

Бәхетемне эзләп тә йөрмәдем,
Үзе килеп басты каршыма.
Югалып калмадым мин дә, шөкер,
Колачымны җәйдем каршылап.
Карамый икән язга, кышка да,
Күңел кинәт чәчәген ата.
Көтмәгән җирдән гашыйк буласың,
Гүя яшьлек әйләнеп кайта.
Рәнҗемәгез бу якты дөньяга,
Ала калса тормыш өттерсп,
Бәхет килә кемгә бик тиз генә,
Кемгә килә озак көттереп.
Бәхетнең дә чираты бар икән,
Һәркемнең дә үз сәгате бар.
Ходай теләсә, эзләмәсәң дә,
Чыга икән үзеңә насыйп яр.

ЯШӘҮ ЯМЕ

Илназ Мөсәлләмов көе

Буем җитмәгәнен беләм,
Үрелмим йолдызларга.
Тормышка ашмасын беләм,
Төшмим мин хыялларга.
Өйрәндем мин дә яшәргә
Үз көчемә таянып.
Ачу килгән чагында да
Сөйләшәмен шаярып.
Курыкмыйм һич авыр эштән,

Тотынам җиң сызганып.
Икеләнеп торганым юк,
Үз-үземне кызганып.
Шулай яшим, көч җиткәнчә,
Сикермим тау үренә.
Әгәр тиеш булса, Ходай
Мендерер үз түренә.

ИРТӘНГЕ ЧЫК

Кояш нурында елтырый
Иртәнге көмеш чыклар.
Кая калды аякларны
Чык белән юган чаклар.
Кояш нурларына иртән
Чәчкә тажы ачыла.
Үлән йолдызларын — чыкны —
Җыеп алам учыма.
Авылкаем, онытмадым,
Истә гүзәл кырларың.
Минем сәламнәрем булып
Ишетелсен җырларым.
Истә һаман урманыңның
Һәр агачы, яфрагы.
Гомер буе онытылмый
Чыклы үлән, туфрагы.
Рәхәт яшим чит җирләрдә,
Юатам күңелемне.
Үз-үзеңне булмый алдап,
Яратам үз илемне.

ЯШЕРМИМ ХИСЕМНЕ

Синең өчен генә җырлыйм,
Сине күңелем сөя.
Син дә битараф түгелсең,
Шулай күңелем тоя.
Матур сүзләр әйтер идем
Күзеңә туры карап.
Булмый гына — ояламын,
«Сөясеңме?» — дип сорап.
Мин бәхетле булыр идем,
Син янәшә атласаң.
Мине сөеп, гашыйк булып,
Сөю хисен сакласаң.
Яшерә алмыйм хисемне,
Түгелә йөрәгемнән.
Ходайдан яшермәгәнне,
Яшерим аны кемнән?

ГАЗИЗ ӘНИЕМӘ

Сагынасың, беләм, әнкәй,
Нишлим соң, шулай кирәк.
Гелән күрешеп торсак та,
Сагына икән йөрәк.
Сагынсаң да, түз, әнкәем,
Мин йөрим изге юлда.
Лаеклы яшәргә кирәк,
Язмыш бит безнең кулда.
Очып кайтам авылыма,
Әнкәем көтә мине.

Сагышта үтә көннәре —
Шунсы өтә күңелне.
Мин бит синең бердәнберең,
Син дә, әни, бергенәм.
Җаным тыныч булыр иде,
Янәшә булсаң гелән.
ҮстерДең җылы кочакта,
Күз нурларыңны сибеп.
Изге теләкләрең теләп,
Яратып, назлап, сөеп.
Өзелә, әни, үзәгем,
Син елап озатканда.
Чиксез шат мин, каршы алсаң
Колач җәеп, кайтканда.
Елап калма, әни, җаным,
Изге теләкләр телә.
Кайткач, бергә чәй эчәрбез
Күчтәнәчләрем белән.
Син бирдең канатлар миңа,
Талпынырга, очарга.
Кошлар сайраганын тыңлап,
Матур моңнар отарга.
Бер сайрар кош һавада да
Сайрый сагыну көен.
Миннән сәлам тапшырырга
Эзлидер әнкәм өен.
Китми булмый, тормыш шундый,
Китәргә туры килә.
Исән йөреп кайтсын балаң —
Уңышлар юрап телә.

МӘХРҮМ ИТМӘ

Мәхрүм итмә мине, Ходай,
Бәхет дигән өлештән.
Нәрсә бар тәмлерәк тагын
Бәхет дигән җимештән.
Бәхетнең юк азы-күбе,
Бәхет үлчәүгә сыймый.
Ничек бәхетле булса да,
Бәндә бәхеткә туймый.
Ни әйтсәң дә, бәхетне бит
Ходай үзе өләшә.
Үзеңә телә бәхетне,
Бәхетледән көнләшмә.
Күпме булса да күләме,
Бәхетнең чамасы юк.
Маңгайга язылган була,
Бәхетне сайлыйсы юк.

КҮҢЕЛДӘ ӨМЕТ КӨЙРИ

Күңел гөлем бөреләнде,
Әмма чәчкә атмады.
Сөйгән ярым китте ерак,
Кире әйләнеп кайтмады.
Янып-көйде күңел гөлем
Сагыштан-сагынудан.
Арыдым ялгыз тормышта
Канатым кагынудан.
Ә шулай да күңелемдә
Сүнмәс өметем көйри.

Бәхет кошым бик якында,
Гүя тирәләп йөри.
Күңелемдә өмет көйри,
Гомер көзем җитсә дә.
Йөрәк һаман сөю көтә,
Яшьлек үтеп китсә дә.

МӘХӘББӘТ СҮРЕЛМИ

Мәхәббәт ул — якты кояш,
Балкый мәңге күңелдә.
Мәхәббәткә караганда,
Берни түгел үлем дә.
Сөю тойгысы сизелә
Караштан, тын алудан.
Яшерәсең күз карашың
Тартыну, оялудан.
Мәхәббәт сүнмәс беркайчан,
Кояш нуры сүнмәсә,
Йөрәгемдә сөю яшәр,
Күңел гөлем шиңмәсә.

ТОМАНДА ҮТӘ ГОМЕР

Бакчабызда ике агач,
Икесе дә алмагач.
Ни кызыгы яшәүләрнең,
Сөйгән ярың булмагач?!
Төне, көне — барысы бер,
Томанда үтә гомер.
Йөрәк сызлый — ничек түзим,

Ходай сабырлык бирсен.
Йөрәккә дәва бер генә:
Сөйгән ярыңның назы.
Җылытмый ялгыз йөрәкне
Хәтта кояшлы язы.
Дулкынлана, күңел тынмый,
Көмнөдер һаман көтә.
Өмет итеп көтә-көтә
Гомер йомгагын сүтә.

МӘХӘББӘТ АЛМАГАЧЫ

Утырттык без кавышканда
Мәхәббәт алмагачы.
Яшәргә язсын парлашып,
Ходаем аерганчы.
Гыйшыгыбызны яңартып,
Яз саен чәчәк ата.
Йөргән юлларга, кар булып,
Ап-ак чәчәкләр ята.
Безнең кебек пар килгәннәр
Кайда бар тагын, кайда?
Зәңгәр күктән безгә карап,
Сокланадыр ул Ай да.
Юкка түгелдер: сандугач
Куна гел алмагачка.
Мәхәббәтнең бөтен сере
Саклана шул агачта.
Бәхет алмагачы җимеш
Бирә безгә ничә ел.
Берүк, бәхет алмагачын
Сындыра күрмәсен җил.

Шул алмагач кебек матур
Чәчәктәй гомеребез.
Әзербез без үләргә дә
Беребез өчен беребез.

ШӨКЕР КЫЛЫП ЯШИМ

Уйламаган идем бу кадәрле
Бәхет тияр диеп өлешкә.
Бик ризамын, шөкер кылып яшим
Өлешемә тигән көмешкә.
Өстәлемдә ап-ак йомшак күмәч,
Чәем кайнап тора чәйнектә.
Якмасам да, өй эчем җып-җылы,
Тора балкып кояшым күктә.
Бәхет өчен шул да җитә икән:
Булса ябынырга юрганым,
Яннарымда, хәлләремне аңлап,
Минем өчен өзелеп торганым.
Мин бәхетле, иркәм, синең белән,
Бәхетлесең син дә минем янда.
Шатлык, тазалыклар, озын гомер,
Тигез тормыш көтсен безне алда.

НИШЛӘТТЕҢ МИНЕ, ИРКӘМ?

Назлап үптең күзләремне,
Нишләттең, иркәм, мине?
Шул минуттан башлап, җаным,
Он(ы)талмыйм һич тә сине.

Әллә җир йөзе әйләнде,
Әллә башым әйләнде:
Сине очратканнан бирле
Бөтен дөньям ямьләнде.
Әллә дөньяга ут капты,
Кояш төштеме җиргә?
Нәрсә булды йөрәгемә,
Яна, туктамый бер дә.
Күз алдына да китермим
Тормышны хәзер синсез.
Синсез, иркәм, тиңдер миңа
Яшәве туган илсез.
Сизәм, син дә гомер юлын
Үтә алмассың тиңсез.
Тормыш юллары төенле,
Чишә алмассың минсез.

ВАКЫТ УЗМАСЫН ДИЕП

Сәгать теле түгел гомер,
Булмый гына туктатып.
Гомерләрнең кад(е)рен белик,
Бушка узмасын вакыт.
Тырышсаң да бирешмәскә,
Йөрәк кузы сүрелә.
Каш өстендә буразналар,
Чал чәчләр дә күренә.
Бәхет тә ак күмәч түгел,
Бирми беркем дә телеп.
Бәхет тасмаң бер өзелсә,
Ялгый алмыйсың тегеп.
Булса икән гомер гөлен

Яшәртеп сулар сибеп,
Сакларга кирәк яшьлекне
Күзең алмасы кебек.
Биргән гомернең кадерен
Белеп яшәргә язсын.
Үткән якты тормышыбыз
Истәлек булып калсын.

СИНЕҢ ӨЧЕН ГЕНӘ

Һәр яшәгән көнем синең өчен,
Синең өчен генә, сөеклем.
Үз йөрәгем үземә аңлашылмый —
Ничек сөеп була бу тиклем?!

Бал-май кебек гашыйк йөрәгемә
Һәрбер сүзең, һәрбер сулышың.
Хәйран калам изге күңелеңә,
Үрнәк миңа бөтен булмышың.

Син булмасаң, кемне сөяр идем
Шушы тиклем, иркәм, өзелеп?
Синнән башка берәүгә күз салмам,
Торсалар да алда тезелеп.

Ходай үзе безне кавыштырды,
Яшәмибез шуңа көенеп.
Без туганбыз бер-беребез өчен,
Яшибез без сөеп-сөелеп.

ТАЛЬЯН МОҢЫ

Гармуннар моңы дулкыны
Яңгырый еракларга.
Өздереп гармун сузсалар,
Талпынам шул якларга.
Яшьлек елларым чагыла
Тальян гармун моңында.
Йөрәгемә дәва — гармун,
Чыңлап торса янымда.
Искә төшсә тальян моңы,
Өзелә бәгырьләрем.
Сусап тальян моңнарына
Үтәрме гомерләрем?
Яшьлек дустым — тальян гармун,
Кайтчы әйләнеп тагын.
Сихри кичләрне күм моңга,
Ямьләнсен туган ягым.
Яшьлек дустым — тальян гармун,
Кайтчы кабат әйләнеп.
Керсен мәңгелек моң булып,
Күңелемә бәйләнеп.

ТҮЗИМ БЕРАЗГА

Сусагандыр жаның назга,
Бәлки, кайтырсың язга.
Кайтам дигәч, бер кайтырсың,
Түзим инде беразга.
Көтән көткән асыл кошым,
Очып кайт яннарыма.
Күк күгәрчен кебек гөрләп,

Килеп бас алларыма.
Һәркемнең теләдер җанын
Аерылышу газабы.
Аерылуга түзәр идем,
Кавышу булса азагы.
Очып төштең яннарыма
Әллә соң зәңгәр күктән?
Кайларда йөрдең адашып,
Мин сине көттем күптән.
Вакытлыча аерылуга
Түзәрмен, сагынсам да.
Ялындырсаң, кабат көтмәм,
Тезләнеп ялынсаң да.

КАР БӨРТЕКЛӘРЕ

Бөтерелеп ап-ак карлар
Эриләр учларымда,
Гүя мин дә югаламын
Иркәмнең кочагында.

К у ш ы м т а:
Гүя бәхет бөтерелә,
Кар бөртекләре булып.
Иркәм кочып бер назласа,
Бәхетем арта тулып.

Кар бөртекләре уйныйлар,
Очып чәчкә кунялар.
Алдамый ул, сине генә
Сөя, дигән булалар.

Кушымта.

Ышанам да, ышанмыйм да,
Әмма күңелем тоя.
Күк йөзеннән Ходай безгә
Бәхет карларын коя.

Кушымта.

Сөю тойгысын сиздерми,
Эче тулы сер икән.
Әмма үзем өзелеп сөям,
Барыбер әсир итәм.

Кушымта.

ЯРАТАМ ДИЯРГӘ АШЫКМА

Гөлләмәләр бүләк итмә җыеп,
Иснәп карамыйча исләрен.
Яратам диярга син ашыкма,
Сынамыйча сөю хисләрең.

Күңел бит ул — бер могҗиза,
Гашыйк була алмый һәркемгә.
Җаның теләмәгән ярлар белән
Яшәп булмас кебек бер көн дә.

Сыналмаган сөю — сөю түгел,
Мавыктыргыч бер уен гына.
Йөрәккәем бозын берничек
Эреталмаслык бер куен гына.

Сөя калсаң, сөй чын күңел белән,
Үзем тоярмын мин җылысын.
Саклап яшәрбез без гомер буе
Мәхәббәтнең кайнар сулышын.

ЯРАТА БЕЛСӘҢ

Беркайчан да картаймассың,
Җырлап-биеп яшәсәң,
Һәрвакыт йөгереп йөрсәң,
Җиң сызганып эшләсәң.
Яратсаң туган илеңне,
Яратсаң туган җирне,
Шушы яраткан җиреңдә
Эшләсәң түгеп тирне.
Изгелек кылып яшәсәң,
Мохтаҗга ярдәм кылсаң,
Яшәрсең син сау-сәламәт,
Гел шат күңелле булсаң.
Тәләк-уйларның пакьлеге —
Тазалыкның саклыгы.
Гомереңнең якты юлы —
Күңелеңнең аклыгы.

НИК ҖИБӘРДЕМ?

Гомер юлларын үткәндә
Адаштым юлларымда.
Ник җибәрдем кулларыңны
Булганда кулларымда.

Үзем дә аңлап бетермим,
Ялгышты башым нигә?
Күрә торып җан ярымны
Алыштым соң мин кемгә?
Төзәтеп булмый ялгышны,
Мөмкин дә түгел икән.
Барны юкка алыштырып
Йөрү — буш шөгыль икән.
Моңдаш кошым — сандугачым —
Сайрады талларымда.
Кадерләренне белмәдем
Булганда яннарымда.
Төзәтеп булмый ялгышны,
Үкенсәң, үкенмәсәң.
Саф сөю саклана, бары
Ятларга үрелмәсәң.

БӘХЕТНЕ ТОЕП ЯШИМ

Бәхетле булып дөньяда
Кемнең яшисе килми?!
Бик күпләр бит чын бәхетнең
Нәрсә икәнен белми.
Чын бәхетнең ни икәнен
Мин беләм, белеп яшим.
Бәхетне татып өлгердем,
Урта булса да яшем.
Янымда назлы ярым бар,
Мине өзелеп сөйгән.
Безнең мәхәббәткә карап,
Гөлләр дә башын игән.

Сөю җимешләре йөрсә
Тирәләп безнең янда,
Сайрап торса бакчабызда
Бәхет кошлары таңда,
Кояш күктә янып торса,
Вакытында яңгыр яуса,
Яңа яуган ап-ак карлар —
Олы бәхет болар бар да.

КАЙТЫРСЫЗ ӘЙЛӘНЕП

Кыр казларым, кыйгак-кыйгак,
Нигә түбән очасыз?
Китәбез дип саубуллашып,
Гүя җирне кочасыз.
Без дә моңсу, сез киткәнгә,
Караңгы көз җиткәнгә.
Гомер көзләре ямансу,
Әллә язны көткәнгә.
Килер әле көткән язым,
Озак түгел барасы.
Тик бер фасыл — ак кыш кына —
Көз белән яз арасы.
Сез бит мәңгегә китмисез,
Кайтырсыз бер әйләнеп.
Китәр инде сез кайткачтын
Яз көннәре ямьләнеп.
Безнең дә күңел яшәрер,
Көткән яз яшелләнгәч.
Күңелдәге тойгы-хисләр
Мәхәббәткә әйләнгәч.

МАКТАРЛЫК ТА ШУЛ

Сөйгәнемне мактыйлар,
Мактарлык та шул үзе.
Изге җанлы, киң күңелле,
Нур чәчеп тора йөзе.
Син кадерлем, бердәнберем,
Мин сөям сине генә.
Җаным белән тоям: син дә
Сөясең мине генә.
Кеше язмышны сайламый,
Язмыш сайлый кешене.
Изге күңелләрне сөйгән
Сайлый синең ишене.
Иркәм сөя һәммәбезне,
Без дә аны сөябез.
«Таза булып, озак яшә,
Кадерлебез», — диябез.

ОЧРАДЫ ЮЛЫМДА

Йөрәк — ул серле бер йозак,
Ярамый төрле ачкыч.
Йөрәк түре биек җирдә,
Юктыр менәрлек баскыч.
Ачкыч була берәү генә,
Тик берәүнең кулында.
Ачкычлы бер изге күңел
Очрады ла юлымда.
Килеп керде дә йөрәккә,
Уйламый да чыгарга.
Минем кебек көйсез затка

Җыенамы чыдарга?
Чыдамаса ачмас иде,
Кермәс иде күңелгә.
Әллә икебез бертөсле:
Килгәнебез юк телгә.

ИҢ ИЗГЕ КЕШЕЛӘРЕМ

Нәнәем минем акыллы,
Нәнәем минем матур.
Бабаем да шундый уңган,
Бабаем булган батыр.
Безне дә алар өйрәтә
Уңган, эшчән булырга.
Йокыдан торгач та һәрчак
Иртән дога кылырга.
Без дә аларны сөябез,
Хөрмәт итәбез гел дә.
Алар белән тормыш матур,
Күңелле үтә көн дә.
Озын гомер бирсен Ходай
Бабама, нәнәемә.
Кочарга язсын аларны
Оныгым — нәниемә.
Язсын аларга яшәргә
Озак-озак парлашып.
Дөньябыз булыр түгәрәк,
Яшәсәк аралашып.
Әти-әни, өлкәннәргә
Булыйк без мәрхәмәтле.
Кечкенә изгелеккә дә
Алар да бит рәхмәтле.

ҚАРАМЫЙЧА БЕЛӘККӘ

Кемдә бәхет — бер олы күл,
Кемдә кечкенә елга.
Төрлечә бара шул тормыш,
Ел туры килми елга.
Язмышы да әллә нинди,
Туры килми теләккә.
Тәкъдир кыенлыклар сала,
Карамыйча беләккә.
Аяз күгем, якты юллар,
Бәхетләр көтсен алда.
Авыр чакта таянырга
Булсын сөйгәнем янда.
Сыңар уч бәхетемне дә
Кабул итәм куш итеп.
Көзен килгән зур бәхетем,
Югалма кышын китеп.

КЫШКЫ КОШЛАР

Салкын кыш урталарында
Кошлар мохтаҗ ярдәмгә.
Битараф калмагыз, дуслар,
Икмәк китмәс әрәмгә.
Узып китмәгез, дусларым,
Күрмәмешкә салышып.
Кошлар җим сорап йөриләр,
Карап безгә, ялынып.
Һәрбер тереклек иясе
Яшәү өчен көрәшә.

Кошлар түгел, кешеләр дә
Авырлыкка бирешә.
Мәрхәмәтле, изгелекле
Булыгызчы, дусларым.
Салкыннарны исән-имин
Чыгар кышлап кошларым.

СӨЕКЛЕ НӘНӘЕБЕЗ

Бисмилласын укый-укый,
Йокыбыздан уята,
Назлы карашлары белән
Күңелләрне юата.
Оныкларын гел иркәләп,
Сөеп кенә үстерә.
Авыр сүзләр ишетсә дә,
Үпкәсен тиз бетерә.
Һәрбер биргән киңәшләре
Үлчәүсез алтынга тиң.
Ачык йөзле, киң күңелле,
Һәрвакыт колачы киң.
Куллары да алтын аның
Бер белмәгән эше юк.
Шуның өченме үзен дә
Яратмаган кеше юк.
Үз әнием кебек, син дә,
Нәнәкәем, якынсың.
Яшәеш, гомеребездә
Юл яктырткан ялкын син.

ЯРДӘМ БУЛЫР

Чыпчыклар, бәләкәчләрем,
Сырып алган куакны.
Иртән-иртүк уяналар,
Каршылыйлар кунакны.
Чырык-чырык чыркылдыйлар,
Чыкканымны көтәләр.
Алар таныйлар бит мине,
Ярма өмет итәләр.
Күтәрмәгә чыгып басам,
Шундук очып киләләр.
Үземнең дә аларны бик
Яратканны беләләр.
Тамаклары тук булганда,
Казага ирешмәсләр.
Йөрәкләрендә май булса,
Суыкка бирешмәсләр.
Һәммәбез дә бер генә уч
Ярма сипсәк шуларга,
Ярдәм булыр кошчыкларга
Кышны исән чыгарга.

АЛЫШТЫРДЫ СӘМӘЙГӘ

Көне-төне сәмәй куа
Саимә карчык мунчада.
Бөтен алкаш, тамак кипсә,
Чаба, ди, шул мунчага.
Бер чирек сәмәен кичә
Тоттырды ул Ямайга.

Өйдән казын урлап Ямай
Алыштырды сәмәйгә.
Кара тавыгын күтәреп
Килгән түбән оч Хатыйп,
Эләктереп бер шешәне
Китте шунда ук кайтып.
Кайда Хәбирнең күркәсе,
Кетәктә иде кичтән?
«Саимә казанында кайный», —
Уйлап алды ул эчтән.
Ташый авылның ир-аты
Каян нәрсә табала.
Алыштыра көмешкәгә,
Ач утырса да бала.
Черегән мунча идәне —
Кайгыга калган Саимә.
Шундук китерделәр такта,
Шома — егылма, тайма.
Хуҗасы булмаган йортлар
Киттеләр хәзер худка.
Идән тактасы сәмәйгә,
Черек бүрәнә — утка.
Саимәне әйтәм, бик үткер,
Янып, суда да батмый.
Басугамы, фермагамы —
Кая барса, буш кайтмый.
Ташый авылның ирләре
Саимә карчыкка мөлкәт.
Бу чирен гүргә кергәнче
Туктатмас инде мөртәт.

ҚАРЧЫКЛАР ЗАРЫ

Өй алдында ике карчык
Утыра ләчтит сатып.
Қайчагында вакыт табып,
Тыңлап торам шаккатып.
Әсма уңмаган кияүдән,
Асиясе — киленнән:
Қөннәр буе алъяпкычын
Чишә алмый биленнән.
Қияүдән дә уңмаган бит,
Иреннән дә уңмаган.
Имеш, яратып бармаган,
Аны Хәтми урлаган.
Үзе бер бәхетсез булды,
Шул ук язмыш кызында.
Бер күшеккән чебеш-кияү
Дөя кызы кырында.
Қүрше Ямал Сәкинәсе —
Шәбәргән каз бәбкәсе.
Қияүнең менә дигәнен
Табып биргән әткәсе.
Эшләгән урыны — базар,
Салым җыя, ди, Ямал.
Қалымның яртысын давай,
Юкса, абзаң — дуамал...
Бер-ике сәгатькә генә
Барып килә, ди, эшкә.
Қалган сәгать-минутлары
Бакчада үтә эштә.
— Минем кияү йөргән була
Папка күтәргән булып,

Купшы чыпчык, әтрәк-әләм,
Безне үртәгән булып.
Бер бәхеткәең булмаса,
Булмый шул сатып алып.
Куып та чыгарыр идең,
Кыз нишләр ирсез калып?
Асия елый, зарлана:
— Син миңа әйтәсеңме?
Мин чыгып китәмме, димең,
Яки син китәсеңме?
Адәм генә дә түгел,
Киленем — кара елан.
Үтә гомерем кызганып,
Малайга карап, елап.
Эшләп алган фатирымда
Безгә урын юк хәзер.
Башлап бер сүз әйтер хәл юк,
Кабып йотарга әзер.
Эшләми дә, каян ала —
Кесәсе тулы акча.
«Табармын закон сезгә,— ди, —
Акча миндә бер букча».
Җисеменә туры килә —
Исеме дә Кобара.
Авыз ачып бер сүз әйтсәң,
Куркә кебек кабара.
Саф һава сулап торалар
Картлар баскыч төбендә.
Кобара кайта лып-лычма
Корбан бәйрәм көнендә.
Җитмәсә култыклашкаешар
Ямал кияве белән.

Ике карчык эчтән генә
Калдылар ләгънәт теләп.
Икенче көнне бу парны
Алып китте «кара карга».
Белмим: тәкъдир, карчыкларны
Төртеп төшерде ярга.

СӘГЫЙТЬ ҺӘМ ФӘГЫЙТЬ МАҖАРАСЫ

Ике күрше — Сәгыйть, Фәгыйть —
Дус яшәде гомергә.
Нигез ташы бер авылда,
Туып-үсте бер җирдә.
Шәһәрдә дә алар күрше
Яшиләр, ди, бер йортта.
Йорт эшләрен башкарырга —
Икесенә бер кортка.
Бер заводта эшләделәр,
Дачалары да бергә.
Күпме көчен түкте Сәгыйть
Шушы кадерле җиргә.
Сәгыйть, төяп арбасына,
Тирес ташый фермадан.
Фермага ук барып тормый,
Фәгыйть ташый күршедән.
Кич җиттеме, черки талый,
Көндез кояшы өтә.
Фәгыйть бабай су да сипми,
Яңгыр яуганны көтә.
Сәгыйть курыкмый кояштан,
Исе китми черкигә.

Йокларга да яратмый ул,
Эшли бирә бер көйгә.
Сәгыйтьнең үсә кыяры,
Җыеп бетәрлек түгел.
Фәгыйть күреп, күзе тонды,
Котыра көнчел күңел.
Ниһаять, эшкәябышты
Фәгыйть карт та таң белән.
Эше дә тора өелеп,
Түтәлс кый чүп-үлән.
Фәгыйть тутыра тиресне
Кыярлары төбенә.
Бидрәләп су да сибә
Өч мәртәбә көненә.
Көнләшүдән Фәгыйть бабай
Бер биш яшькә картайды.
Әллә артык сыйлаганга
Кыярлары мортайды.
Әллә инде хәрәм тирес
Килешмәде кыярга.
Фәгыйть күпме тырышса да,
Кыяры юк җыярга.

ГӨЛЛӘР КЕБЕК ЯШИМ

Әбекәй дип эндәшәсез,
Нишләп мин әби булыйм.
Урманны да, кырларны да
Йөгерә-чаба буйлыйм.
Идән юам, керләр юам,
Базарга да йөгерәм.

Киленем эштән кайтканчы,
Бөтен эшкә өлгерәм.
Кич җиттеме — җилдерәмен
Театрга, концертка.
Аягымда биек үкчә,
Нишләп булыйм мин кортка?
Шаян сүзле, шат күңелле
Булып яшим гомергә.
Язлар саен чәчәк аткан
Гөлләр сыман күренәм.

АЧЫ БУЛА БАЛАНЫ

Дуслаштыра да аракы,
Аракы талаштыра.
Менә дигән сөеклесен
Пәригә алмаштыра.
Эшлим дисә, эш бармый,
Йоклап үтә гомере.
Эт җыймаслык авызда сүз,
Борын-бите җимерек.
Гомер буе әрәмтамак
Яши ул дөнья куып.
Пенсияләрен дә талый,
Әти-әнисен буып.
Ходай сакла, бирмәсәләр,
Йодрыклар төйнәүле.
Сөйгән оныгы нәнәйнең
Гомер буе көйләүле.
Мәктәпкә дә йөрделәр
Нәнәсе белән бергә.

Портфелен аңа тоттырса,
Аунады ятып җиргә.
Гомер буе саклап-яклап
Үстерделәр баланы.
Балан чәчәге матур да,
Ачы була баланы.

ИБЛИС ИЯЛӘШСӘ...

Тиз батасың, чыгалмыйсың,
Хәмер — ул тирән сазлык.
Тонган күз, чөгендер танау,
Һәрвакыт башы салмыш.
Вакыт узганын да тоймый,
Буш минут юк, сәгате.
Көн саен башын төзәтә —
Шул аның бар сәләте.
Кемгә бәйләнергә белми,
Йөри шунда сугылып.
Тип-тигез җирдә абынып,
Башын яра, егылып.
Күз көеге, бер бичара
Кирәкми бер кешегә.
Шатлыгы да, кайгысы да
Бәйләнгән бер шешәгә...
Егып салмый бер кеше дә
Аракыны авызга.
Эчкә иблис ияләшсә,
Әйләнәсең явызга.
Чыгалырмын дип уйлама,
Сазлыкка кереп батсаң.

Алданып шайтан суына
Изге җаныңны сатсаң.
Бар гомерен алыштырса
Елан суы — хәмергә,
Яшәгән еллар ялгышы
Илтеп кертә кабергә.
Тирән аракы күлендә
Чумып-чумыплар йөзә.
Йөзә-йөзә, һушы бетеп,
Газиз гомерен өзә.

ТАЗА БУЛАСЫҢ КИЛСӘ...

Бакча алдым, һич үкенмим:
Бөтен дару бакчада.
Хәтта ютәл даруын да
Сатып алмыйм акчага.
Утырттым бакчама суган,
Бер түгел, икс тутәл.
Тозга мана-мана ашыйм,
Төшмәсен, диеп, ютәл.
Сарымсак утырттым күздән,
Бер елга җитсен, диеп.
Суык-мазар тия калса,
Чир урап үтсен, диеп.
Иң кадерлесе — бәрәңге,
Дәва, диләр, күп чиргә.
Уңсын диеп, тирес салам,
Бәрәңге үскән җиргә.
Бәрәңге утырттым бик күп,
Иң әйбәт сортын гына.

Белмим, ничек бетерергә
Колорад кортын гына?
Кишер чәчтем — олы түтәл,
Бик уңды, эре үзе.
Каротин күп, ди, үзендә,
Дәвалый икән күзне.
Петрушка, сельдерей, укроп
Үсте быел бик харап.
Киптереп куям күп итеп,
Тора ул кышка ярап.
Ул чөгендер чәчтем — дөнья,
Үстеләр эре булып.
Чөгендер пешереп аша,
Барса бавырың сулып.
Көтәм жылы яңгырларны,
Җылы җилләр искәнен.
Түземсезлек белән көтәм
Кыярларым үскәнен.
Ашказанына да дару бар,
Ул булса — кыяр икән.
Шултикле уңды кыярым,
Эчемә сыяр микән?!
Помидорны, борычны да
Сөйләпләр торасы юк.
Организмга файдасын,
Беләм, сорыйсы да юк.
Кабак, ташкабак, патиссон
Тәгәрәшеп үсәләр.
«Менә кайда дару!» — дияр
Табибларым, күрсәләр.
Эре башлы кәбестәләр
Тезелеп утыралар.

Кишер кырып кушып, тозлап,
Мичкәгә тутыралар.
Бөтен дару да бакчада —
Табынмыйбыз акчага.
Урман тулы юкәләр...
Төшмәс бер дә ютәлләр.
Яланда үсә үләннәр,
Иренмә тик җыярга.
Бәйләм-бәйләм җепкә бәйләп,
Чөйгә элеп куярга.
Шушы кагыйдәләрне гел
Онытмасаң, үтәсәң,
Таза булырсың таш кебек,
Бал да бераз өстәсәң.

***

Эчемне кырып тормасын,
Әйтәсе сүзне әйтим.
Ирекле заман турында
Әз генә сөйләп үтим.
Байлык артыннан мин кумыйм,
Яши бирәм үземчә.
Балда, майда йөзмәсәм дә,
Тормыш болай түземчә.
Кирәк җиренә дә хәзер
Керә алмыйсың акчасыз.
Ярый яшелчә үстерәм,
Нишләр идем бакчасыз.
Җыеп алып кайтам көзен —
Яшелчәм балкон тулы.

Акча түләп алынмаган
Витамин эчем тулы.
Саный-саный тиешәрне,
Яши бирәм бер көйгә.
Кием алсам, даруга юк,
Дару алсам — киемгә.
Сабыны да эреп тора,
Оегы да тишелә.
Бу дөньяның авыр эше,
Йөге өскә ишелә.
Яшим шулай шөкер кылып,
Булганына канәгать.
Ходай ризалыгы өчен
Яшим кылып гыйбадәт.

КЕМГӘ ГЕНӘ КЕМ ХАҖӘТ

Бик нык чирләгәч, беркөнне
Киттем мин больницага.
— Бу атнага талон юк! — ди. —
Бар киләсе атнага.
Кем белсен, кайчан чирләсен —
Язылыр идем алдан.
Сөтле, мәтрүшкәле чәйдән,
Файда тапмадым балдан.
Киләсе атнаны көтеп,
Танау тыгылды тәмам.
Атна үткәч, табиб әйтә:
— Хәлең бит, апа, яман:
Синдә бит гайморит чире,
Нигә килмәдең алдан.

Томау төшә башлагач та,
Шундук киләсең калган.
Бар, аппаратта, — ди, — тикшерт,
Өч йөз сум гына тора.
Җәяүләп кенә барасы,
Ерак та түгел ара.
Бушка да ясарга була,
Әгәр ай ярым көтсәң.
Ай ярым үткәнне көтеп,
Бөтенләйгә үк китсәм?
Кемгә кем хаҗәт соң хәзер
Яшәсә ни, китсә ни?
Бер кеше дә җавап бирмәс,
Янып-көеп бетсәң ни.
Бер бушка ашаучы кимер
Хөкүмәткә зур файда.
Пенсия акчасы җитми,
Байлар йөзсә дә майда.

ИРЕКЛЕК ХИКМӘТЛӘРЕ

Бирделәр безгә ирeклек
Беталмыйбыз сөенеп.
Типтереп яши башладык,
Яшәмибез көенеп.
Йоклыйбыз йокы туйганчы,
Торып ашыйсы да юк.
Җәфаланып иртүк торып
Эшкә барасы да юк.
Эшкә барасы булырга,
Эшләргә эше дә юк.

Эшләр идек — бүлмә салкын,
Ягар идек — мич тә юк.
Иртән торып битне югач,
Уйлап утырам озак:
Ничек акча юнәтергә,
Кайдан табарга азык? —
Башым тулы уйлар белән.
Кулыма сумка тотып,
Чыгып китәмен урамга:
Булмасмы берсен отып.
Әйбер алып, әйбер сату
Гадәткә керде хәзер.
Андый эшләр элеккечә
Тоелмый инде сәер.
Урыны да юк басарга,
Барам дисәң базарга.
Почмак саен полиция —
Белми кемне таларга.
Тун сатсаң да, җеп сатсаң да,
Фәлән мең налог — тариф.
Мондый гыйбрәтле хәлләрне
Күрмәгән иде тарих.
Кайтып керәмен өемә,
Арыплар, хәлдән таеп.
Сумка тотып йөреп кенә
Булмый икән ул баеп.
Халык ни эшләргә белми
«Ирексез»тән арынып,
«Типтереп» яшәп ятабыз,
Чын тормышка зарыгып.

***

Аю — урманның хакиме,
Җәнлекләрнең патшасы.
Җыйган аларны киңәшкә:
Бүген кемне ашыйсы?
Мөмкин түгел ит алырга,
Хакының юк чамасы.
Кесәдә юк беребезнең
Сукыр тиен акчасы.
Кем тәмле, йомшак, симез —
Бүре абзый карасын.
Үзем бирермен чамалап,
Кемгә нинди калжасын.
Тәүге башлап диде бүре:
«Бер икс-өч куянны.
Аннан карарбыз боланны:
Куян ашап туяммы?»
Болай да куркак куяннар
Җиргә сеңделәр ятып.
Зур мөгезле горур болан
Тик басып калды катып.
Бераз шулай басып торгач,
Калтыраган тавыш белән
Сүз башлады болан агай
Күзе тулы яше белән.
«Мин ни эшләп симез булыйм,
Сөягем белән тирем.
Һәм чыкмый калган җаным —
Ул ничә төрле чирем.
Безгә көчегез җитә шул,
Чөнки без ерткыч түгел.

Хәрәм аш та ашамыйбыз,
Йом(ы)шак һәм саф күңел.
Иң симезе арабызда
Аю агай түгелме?
Озакламый дөнья куяр:
Иртәгәмс, бүгенме?»
Аю китте дә котырып,
Ачу чәчте үкереп:
«Тагын мине кыстырсагыз,
Бстерермен үтереп.
Сез — дөньяның мәхлуклары,
Шуңа болан, куянсыз.
Сезнең язмышыгыз шундый,
Шуның өчен тугансыз».

***

Төрле бизәккә бизәлгән
Күрше әби капкасы.
Үзе дә купшы киенгән,
Кызыл кашлы алкасы.
Өйләренә килеп төшә —
Әби йөри сөенеп.
Башка инде беркайчан да
Яшәмәс ул көенеп.
Әби тәмам арыды бит
Мал-туар, кош-корт карап.
Ул, үзенә калганда,
Дөньяны көтте харап.
Әбиемнең бердәнбере,
Сөекле матур улы,

Алып кайта уңган килен,
Булачак бит дүрт кулы.
Мендәр тотып әби чыкты
Каршыларга киленне.
Тоттырды алъяпкыч аңа:
Кысып бәйлә билеңне.
Көтеп алган уңган килен
Бераздан бәбиләде.
Әбекәем алъяпкычын
Кире үзе бәйләде.

ГАЗИЗЛӘРДӘН-ГАЗИЗ ӘНКӘЙЛӘР

Сугыш вакыты. Эшкә яраган бар кеше бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле эштә. Башта мине, бишекне бәләкәй арбага салып, әнкәсм үзе белән уракка йөрткән. Соңрак инде, сырган юрганга төреп, күтәреп яслегә илтәләр иде. «Ботка булса да ашап торырмын, яслегә илтмәгез!» дип, юл буе елый идең», — дип сөйләгәне исемдә әнкәйнең.

Беркөнне сәкедә аш эчеп утырабыз (безнең якта «аш ашыйбыз» түгел, «аш эчәбез» диләр). Умачлы аш инде бу. Солы оныннан. Умачның кылчыгы кадала тамакка, мин шул умачларны йота алмагач, төкереп, әнкәй күрмәсен дип, артка ташлап утырам. Шушы вакытта председатель килеп кермәсенме! Һәм миңа: «Кызым, ник ипи ашамыйсың?» — ди. Аңласагыз, ул бу сорауны юкка гына бирми инде. Әнкәем соңыннан: «Нишләргә дә белмәдем, өскә эссе су сиптеләрмени. Бәхеткә каршы, син аңа күзләреңне тутырып карадың да бер сүз дә эндәшмәдең», — дип сөйли иде.

Ниһаять, сугыш туктады. Сугыш беткәндә, миңа өч яшь ярым булса да, ул шатлыклы көнне хәтерләмиммени өчендер. Бәлки, әнкәем сөенмәгәндер дә, чөнки әткәем егерме алты гына яшендә сугыш яланында мәңгелеккә ятып калган.

Сугыш бетсә дә, интегүләр, җәфа чигүләр бик озакка барды. Ерак бабай сугыштан исән-имин кайтты. Инәкәй (әнкәемнең әнисе, мин аны бәләкәйдән үк «инәкәй» дидем), әнкәй, әнкәйнең ике сеңлесе, мин — шактый ишле булганбыз. Ашарга юк, ул бер ындыр бәрәңге ничә кешегә ярты елга көчкә җитә.

Шуннан инде әнкәй белән икәүләп әткәем авылына — Этәйгә — күчеп китәргә карар кылдык. Анда безнең кечкенә өебез бар иде.

Этәйгә күчкәч, әнкәй иң башта ындыр тирәли үр казыды. Киртәләр, коймалар корырлык хәл юк инде ул. Әнкәй үр казый, мин карап утырам. «И әнкәй, дөньяны көтәбез дә инде без»,— дип әйтәм икән. Ул елларда сабын юк, мунча юк. Сирәк кенә кешенекен ягабыз. Өскә ябынырга инәкәем суккан бер кат җәймә. Язын бәрәңге утырттык. Ачбыз, ашыйсы килә. Әнкәй, мин бик үтенеп сорагач, бераз гына бәрәңге чокып алды, бәрәңге дип инде, борчактан чак зуррактыр. Пешереп ашаган идек, агуландык. Ул косабыз, ул башыбыз әйләнә. Күрше апаларның сыеры бар, алар безгә сөттер, каймактыр биргәлиләр, азрак хәл кереп китә иде.

Шулай беркөнне әнкәй каядыр китте. Мин тышка чыккан идем, керәм дисәм, ишек ачылмый гына бит. Кояшлы, үзе салкын көн. Аякка киярге юк, кар өстеннән яланаяк йөгерәм. Аяклар туңды. Әнкәйне эзләп йөгердем күршеләргә, әнкәй аларга кермәгән. Аннан өч өй аркылы Нәсыйха апаларга йөгердем. Ярый әле әнкәй аларда иде. «Нигә

килдең?» — дип тиргәп тә алды. Аннан инде минс күтәреп алды да кайтып киттек.

Бер җәйне тирес кирпече суккан булдык. Аларны да урлап алып киткәннәр. Ягарга бернәрсә юк, бик еладык инде ул кирпечләр өчен. Урман бар, әмма чыбыгына да тидермиләр. Әнкәем бер бәйләм чыбык җыйган да алып кайтып килә икән, урманчы күреп, шуны да алып калган. Шуңа кыш көннәре икешәр гаилә берләшеп яши идек.

Әнкәй көндез эштә. Төнлә аны кәнсәләрдә дежур торырга, ягъни «кеше куарга» чыгаралар: бурыч түләргә кирәклеген әйтеп йөрергә кушалар. Һәркем заем түләргә тиеш: йон, йомырка, сөт, налог, тагын нәрсәләрдер.

Мин инде берүзем калам, шул биш-алты яшьләрдә булганмындыр. Әнкәй еш кына шулай дип искә ала иде: «Ишекне биклим дә тәрәзә янына килеп тыңлап торам, ә син «бисмилләрахманрахим» дип, тәрәзәдән тәрәзәгә йөрисең».

Әнкәем гел: «Минем иң этләнеп торган чагым Этәйлә булды», — дип сөйли иде. Ә интегәсе чаклар әле алда булган икән. Ашарга юк, ягарга юк, киярга юк, бер кат ситсы күлмәк, ул да ничә ямаулы. Үлән, тоз, су — шул иде ашаган бар ашыбыз.

Шулай беркөнне бушка киемнәр өләшеп йөриләр, америкаллар ярдәм җибәргән, диләр. «Кызыма да бирегез әле»,— дип сорый әнкәй. Бригадир бирдертмәскә әйтә, «икенче килгәндә бирербез» дип бытырдый. Аны тыңламадылар, бирделәр. Бер башлык та бирделәр әле тагын. Инде аңа сөенүем, рәхмәтләр укуым! Тегеләрнең һушы китте, шушы бәләкәй генә бала ничек шулай сөйли, теләкләр тели белә дип.

Ә беркөнне яңгыр коеп ява, ашарга кирәк бит инде, киттем үлән җыярга, алабута эзләргә. Маңма

булып чыланып кайттым. Әнкәй, төшкелеккә кайтып, үләнне турарга гына утырган иде, бригадир абзый килеп керде. Ул, ачы итеп тиргәнә-тиргәнә, тактаны идәнгә атып бәрде, янәсе әнкәйне эшкә куа инде. Мин ач көе елап утырып калдым, әнкәй эшкә чыгып китте.

«Заманы шул иде», — диярләр кемнәрдер. Ә мин явызлыкны заманга сылтамас идем. Явыз кеше — ул бу заманда да явыз. Сталинны гаеплиләр, Сталин бит күрәзәче түгел ике мең чакрымнан күрергә.

Әнкәйнең Зәйтүнә исемле сеңлесе сугыш вакытында, унбүрт чакрым йөреп, ун класс бетергән. Ул вакытта ун класс беткән кешеләр бик белемле булып исәпләнә иде. Шуңа чәчү вакытындамы, урып-җыю вакытындамы аны үлчәүче итеп куйганнар һәм дә эш хакына капчык ярым арыш биргәннәр. Әлбәттә, шуңардан әнкәйгә дә өлеш тигән. Әнкәй Исәнбайга барып, алып кайтты шул арышны. Күршеләргә кереп, ярма ташында ярып, миңа аш пешерде. Инде ул ашның тәмлелеге! «Кайчан соң, әнкәй, ашны эчеп бетерәбез?!» — дип кабатлыйм да кабатлыйм. Әнкәйнең тәмам ачуы килгәндер инде, башка берне түкеп тә алды. «Ул ашны хәзер бетергәч, яңадан нәрсә ашарбыз соң, сиңа нигә хәзер үк эчеп бетерергә кирәк?» — ди. «Мин савытын ялар идем, ярмасын»,— дим.

Яңадан кәҗәбез дә булды. Сөте бик юк иде инде. Әнкәй көтүче савып эчә дип әйтә иде.

Күрше апа сөтен, маен, иреннән яшереп, безнең базга кертеп куя. Чөнки аның ире икенче бер яшь кыз белән йөри, диләр иде. Мин ач булсам да, тими идем аның сөтенә, кешенекенә тияргә ярамаганны аңлый идем.

Җәй көне әнкәй мине үзе белән печәнгә ияртеп бара, чөнки колхоз печәнчеләрне аш пешереп ашата иде. Алай ит булмаса да, үлән ашаган белән бер түгел инде.

Шулай беркөнне яңгыр явып кына үткән иде, юл аркылы чыгып барганда акча таптым. Саный белмим, кызыллы-яшелле акчалар. Кызылын күрше кызы сорап алды, ул миннән күпкә зур иде, мөгаен, акча саный белгәндер. Яшелләре бер сумлык акчалар икәнен белдем әнкәйдән. Акча төсен күргән юк инде ул. Әткәй сугышта үлгәнгә кырык сум акча бирәләр иде, әмма аны кулга бирмиләр, налогка тотып алып калалар. Беркөнне магазинга шикәр китергәннәр дигән сүз чыкты. Теге ике берлекне тоттырып, әнкәй мине дә җибәрде лавкага. Барып керсәм, шикәр сатылып беткән, капчык төбендә комы гына калган. Сатучы шуны миңа үлчәгән булды. Яулыгыма салдым да почмагына төреп бәйләдем. Их, тәмләп карыйсы килә. Тәмен беләсе килә шикәрнең! Түзмәдем, яулыкны чишеп, телемне генә тидереп карадым. Башым әйләнеп киткән кебек булды, шушындый да тәмле ризык бар микәнни дөньяда, дип уйладым. Кайткач инде, әнкәсм сатучыны тирги башлады: «Бала-чаганы алдап, оятсыз, аз үлчәгән»,— ди.

1947 нче еллар иде микән җәй көне әнкәемнең нык итеп үкчәсе шеште. Сызлавына һич чыдый алмый елый, ә бригадир эшкә куа. Авылда врач юк, районга да барып булмый, ачлы-туклы кыш чыккан атлар көне-төне эштә. Әнкәй ай ярым җәфалангач, ул шеш үзе тишелеп акты.

Элек бит кыш кыш төсле, җәй җәй төсле иде. Без, бала-чага, Базы буенда кояшта кызынып, су кереп рәхәтләнәбез генә. Базының теге ягында җиләклек, менә шулар дәвалагандыр инде кышын туңып чыккан тәннәребезне-җаннарыбызны.

Әткәемнең энесе Котдус абзыкай әнкәйне бик ихтирам итә иде. Гомумән, әткәйнең туганнары әнкәйне гел үз күрделәр, әнкәй дә аларны бик ярата иде. Әнкәй яраткач, мин дә аларны бик яраттым. Шул Котдус абзый (мин аны «төпчек абзыкай» ди идем): «Җиңги, син монда җәфа чигеп торасың, әйдә Свердловскига киттек, мин сине эшкә кертермен, тамагың тук булыр, соңрак кызыңны да үз яныңа алырсың»,— дигән. Тик әнкәйнең паспорты юк, ЗАГС язуларын өй түбәсенә меңдереп куйган да, тычкан ашап бетергән. Җибәрмим беркая да дип, председатель дә кырт кискән. Әнкәй: «Бирмәсәгез бирмәссез, мин барыбер Этәйдә тормыйм, Исәнбайга кайтып китәм»,— дигәч кенә, авыл советында эшләгән Кәшифә апа документларын тутырып биргән.

Бу — мин беренче класска укырга кергән 1949 нчы ел. Әнкәй фуфайка тектерде, өстә фуфайка бар барын, тик яланаяк. Беренче мәртәбә ипи салдык, инде ул ипинең тәмлелеге!

Укып йөрибез, шулай беркөнне җыр дәресе булды. Үзебезнең укытучы Исламов абый каядыр киткән, аның урынына избач булып эшләгән Фәния апа керде. «Кемнәр җырлый белә?» — дигәч, минем белән утырган Фәвәдә «Әйт әле, күбәләк» дигән җырны җырлады. Аннан соң мин кулымны күтәрдем. «Җырла, Виниса»,— диде.

Ал урыйлар, гөл урыйлар
Атларның муенына;
Син керсәң дә, мин кермәем
Ятларның куенына,—

дип җырлап бетүгә, Фәния апа көлә-көлә класстан чыгып та китте. Кайткач: «Мин бүген дәрестә

җырлаган идем. Ялгыш җырладым бугай,— дидем әнкәйгә. —

Кулымдагы йөзегемнең
Исемкәе — К(ы)лара,
Яшәсен Совет власы,
Көннән-көн алга бара,—

дип җырласам, дөресрәк булыр иде, әйеме, әнкәй?» — дидем.

Мин беренче классның беренче чиреген бетк әч, без Исәнбайга күчеп кайттык. Ул да булса, әнкәй шәһәргә китәргә җыенган икән. Аннан ул, кире Этәйгә кайтып, әткәйнең туганнарына ияреп Свердловскига китәчәк.

Исәнбайда беренче төнне үк төш күрәм, әнкәйне төрмәгә ябалар икән дип. Куркып, кычкырып елап уяндым. Әнкәй сикереп торып кочагына кысты да кычкырып елый башлады. Кемнең бердәнбер баласын ташлап китәсе килсен инде. Аны елап озатып калдык инәкәем белән.

Әнкәй китүгә кызамык белән шултиклем дә каты авырдым, ничек терелгәнмендер. Аякка кияргә чабата бар иде, оекбаш та. Күлмәгем генә тузды. Төпчек апа үзенең итәген бирде, агапа (әнкәйнең уртанчы сеңлесе) кулдан күлмәк тегеп кидерде.

Кыш көннәре салкын, ягарга юк. Агапа фермада сыер сава. Мин көн саен төнлә чана тартып салам урларга бара идем. Салам җылысы гына күпмегә җитә инде.

Яз җиткәч, ындырны чокый башлыйбыз. Черегән бәрәңге эзлибез, кәлҗемә дия идек, ул шултиклем дә тәмле сымак иде.

Беренче май бәйрәмнәре исемдә аеруча уелып калган. Демонстрация шундый күңелле. Кызыл флаглар җилферди. Иң зур шатлык шул:

демонстрациядән соң безне җыеп ашаталар иде. Ипи, аш, чәй бирәләр! Бервакыт күрше малае Тимерҗан да олы мис күтәреп килгән булган. Ул әле укырга кермәгән иде. Мисен корсагына каплаган, башын коймага терәгән, елый: укымагач, аңа аш юк, бәлки, аңа игътибар да итмәгәннәрдер.

Әнкәемне төпчек абзыкай эшкә керткән, эшли башлаган. Эш авыр, акчаны бик аз түлиләр дип, хаты килде. Бер класс белеме дә булмагач, нинди яхшы эш инде аңа. Күпмедер вакыттан әнкәйнең посылкасы килде. Инде шултиклем дә матур ситсы салган. Агапа аңардан барыбызга да күлмәк текте. Әнкәй тагын, тагын җибәреп торды посылкаларны. Посылкалар килсә дә, посылка әнкәй түгел бит инде. Шултиклем дә сагындык, инәкәй белән икәүләп елап та алабыз.

Ел ярымнан артык вакыт үтеп китте. Урамда бала-чагалар уйнап утырабыз. Басу капкасында кемләр күренде. Гайнесафаттәй йөгерә. «Фатыйматтәй, сөенче, кызың кайтты!» — дип кычкыра. Мин сөенгәнемне дә хәтерләмим, чөнки каршысына йөгереп бара алмадым, бик зур чуан чыккан иде, атлый да алмый идем. Башта әнкәйне йөгереп барып Галия кочаклады. Галия — күрше кызы. «Нигә башта Галияне кочакладың?» — дип, мин үпкәләгән булдым. Әнкәй бизәкле косынка бәйләгән, өстендә матур күлмәк, фуфайка. Шикәр, чәй алып кайткан иде.

Әлек отпуск унике көн генә иде. Аның өч көне кайтырга, өч көне барырга. Хәзерге кебек тыз-быз чапмыйлар иде машиналар. «Башта поездда, аннан «Сөләйман» дигән пароход белән Сарапулдан Груздевкага ике тәүлек кайтам», — дип сөйли иде әнкәй. — Груздевкадан — унсигез чакрым җәяү».

Җәйге каникул вакытында әнкәй мине дә алып китә иде шәһәргә. Бөтенләйгә үз янына алыр иде,

торыр урыны юк, үзе дә кеше өстендә генә. Бер бүлмәдә өч кеше яшиләр. Уку елы башлануга тагын авылга кайтып китәм.

Бишенче класска да җиттем. Аганаңы кияүгә биреп җибәрдек. Ягарга утын юк. Салам юлы ябылды. Аптырап, утынга барырга булдым. Киттем Почманкулга, күпме ботак-сатак кайткандыр инде, өйне җылыттык. Шуннан соң утынга бару гадәткә кереп китте. Бер көн ерак бабай барса, икенче көнне — мин. Әнкәй белән агапа аңа үгиләр, димәк, мин дә үги.

Мин җиденче классны бетәсе елны әнкәйгә тулай торактан урын бирделәр. Җиденче классны тәмамлагач, әнкәй мине үзе белән бөтенләйгә Свердловскига алып китте.

Тулай торак бүлмәсендә алты кеше, алты карават иде. Мин — җиденче, Нәзирә апаның малае — сигезенче, Полина апаның әнисе — тугызынчы. Бер тавыш-гауга куптарган кеше юк, барыбыз да дус, тату идек, Аллаһыга шөкер. Әнкәй мине русча белмәгәнгә рус мәктәбенә яңадан җиденче класска бирде. Русчаны аңласам да, сөйли белмим. Дөрес әйтмәсәм, рус балалары көләләр. Укытучылар да аптырыйлар икән: математика шундый авыр фән, чикләвек кебек чертләтә, ә сөйли белми, диләр икән. Әмма немец телен, географияләрне инде шәп белә башладым. Шулай җидене, сигезне тәмамладым. «Уралобувь» аяк киеме тегә торган фабрикага тегүче булып урнаштым. Кичке мәктәпкә укырга йөрим. Ярты ел эшләгәннән соң разрядымны күтәрделәр. Акчаны да ару гына ала башладым. Әнкәем пилорамада эшләде. Бу хезмәтне ул җиңел дип санады. Килгән елларда нык авыр булды дип гел сөйли иде. Хәзер экскаватор казый җирне, ә элек, йорт сала баш-

ласалар, көрәк белән чокыганнар котлованнарны. Шулай ике елданмы безгә әнкәй белән икебезгә ун квадрат метрлы бүлмә бирделәр. Аңа шултиклем сөендек, трамвай тукталышы да якын.

Элек йортлар күп төзелә иде. Завод тагын йорт төзеде, эшчеләргә фатир бирделәр, зур бүлмәләр дә бушады. Әнкәйгә ияреп, заводка бүлмә сорарга киттем. Әнкәй авызын ачарга да өлгермәде, директор: «С Хабировой вопрос решен, нет комнаты», — димәсенме. Хәзер минем авыз ачылды. «Подождите,— мин әйтәм, — вы что на своего рабочего кричите? У вас на двоих с женой четерхкомнатная квартира, а нам на двоих — десять квадратных метров! — дим. — Сколько лет на маленьком диване сплю!» Парторг кул селти, ымлый: «Җитегез чыгып, булыр», — дип пышылдый. Ике көн үткәчме, әнкәй кош тоткандай сөенеп кайткан. «Хабировага унсигез метрлы 36 нчы бүлмә дип исемлек элгәннәр проходнойга», — ди. Инде шатлыгыбыз эчебезгә сыймый. Аннан суыткыч та алдык. Аны ул вакытта бик зур танышлык белән генә алып була иде. Телевизор алдык. Газ да бирделәр, эссе су да.

Гомумән, без үзебезне бик бәхетле итеп тоя идек. Эшлим, укыйм. Арый идем инде. Шул вакытларда сәламәтлегем бик какшады.

Ирләре сугышта үлгән тол хатыннарга фатир бирергә дигән карар чыкты. Мин дә йоклап ятмадым, әнкәй русча белмәгәч, бар җиргә дә мин йөри идем.

Унынчы классны тәмамладым, Аллаһыга шөкер, аннан соң инде берьеллык бухгалтерлар курсы беттем. Тик бухгалтер булып эшләмәдем, бу эшкә күңелем ятмады. Болай да эшләгәнем үземә җитә.

Бу чор тормышымны бәйрәм итеп кабул иттем мин. Дусларым күп, барысы да әйбәтләр. Элек тәмәке тартып, аракы эчеп йөргән кызлар юк иде бит, булса да, миңгә бер булгандыр.

Бераздан техникумга да кергән идем, бәхетсезлеккә каршы диләрме, башым нык сызлый башлады. Врачлар: «Сиңа укырга ярамый», — диделәр. Уку белән хушлашырга туры килде. Озак көттермәделәр, әнкәсмә үзе эшләгән заводтан бер бүлмәле фатир бирделәр. Әмма ул тукталышка ерак кына иде. Шуңа без аңа бик үк сөенмәдек тә.

Отпуск алып, әнкәем авылдан урап килде. Инәкәебез нык чирләгән, ни дисәң дә сиксән яшь, дөнья көтүе авыр карт кешегә. «Мин инәкәй белән эткәйне карарга кайтып китәм»,— диде әнкәй. Пенсиягә чыгарга бер ел чамасы гына калган иде аңа. Мин инде озакламый фатирны алыштыру чарасын эзли башладым. Ул вакытларда торакны сату-алу мөмкин түгел, алыштырып кына була иде. Көч-хәл белән алмаштырып, 1974 нче елны Уфага кайттым. Хәзер инде әнкәем, инәкәем янына сагынган саен кайтып килә башладым. Отпускымда туристик юллама белән җылы якка бардым, санаторийларга йөрештердем.

Уфага килгәч, «Гидравлика» заводына эшкә урнашкан идем. Әллә урын алыштыру килешмәде, гел генә авырый башладым. Ул вакытта больничный бик биреп бармыйлар. Температураң югары гына булмаса, ничек кенә чирләсәң дә, эшләргә кирәк. Эшче куллар дефицит иде ул чакта. Шулай да, сәламәтлегем бик какшап киткәч, операция эшләтергә туры килде. Аннан соң дүрт ай санаторийда булдым. Әле килеп уйлыйм да, үз гомеремдә тазалыкка һич туймадым, димен.

Әнкәем полиартриттан җәфалана башлады.

Инәкәем дә авырып китте, хәтерен җуйды. Беркем дә мәңгелек түгел шул, сиксән сигез яшькә җитеп, инәкәем бакыйлыкка күчте. Миңа инде аяк астында җир убылган кебек булды. Кайгымны әзрәк булса да таратыйм дип, отпуск алдым да Мәскәүгә китеп бардым. Юк, андый зур кайгыны Мәскәү генә басамыни инде.

Әле дә елый-елый язам шушы юлларны. Ел да, менә утыз ел була ул үлгәнгә, хәер бирәм, Коръән укытам, ул минем гел исемдә. Инәкәй үлгәч, ерак бабай: «Инде ничек мин берүзем торырмын», — дип елый башлады. Әнкәй, аны кызганып, тагын авылда торып калды. Үги булса да, жәл бит. Ерак бабайны үзенең кызы да чакырган иде, анда бармады. Үз дөньяң үз дөньяң бит инде, тагын ун ел әнкәем ерак бабайны карады. Ул, үпкәсенә салкын тиеп, йөз яшькә җитәргә ничәдер ай калганда вафат булды. Ерак бабай алты яшендә ятим калган. 1914 нче елны пленга эләккән, алты ел Германиядә яшәгән. Аннан — Гражданнар, Икенче бөтендөнья сугышлары, кыскасы, бик күп кыенлыклар күреп, туксан тугыз ел яшәде.

Хәзер инде әнкәй бөтенләйгә минем янга Уфага күчеп килде. Шулай да җәйгелеккә күршеләрен, дусларын сагынып авылга кайтып китә иде.

Мин шигырьләр дә яза идем. Язам да әнкәемә укып күрсәтәм. Белеме булмаса да, күңеле белән тоя иде ме: «Монысы — җыр инде, монысы — шигырь, җырга бармый», — дия иде. Хәтере бик яхшы иде шул. Мин бер әйтсәм, шундук отып та ала иде. Кайсы илнең башкаласын сорама, белә иде, хоккей карарга ярата, кино артистларын исемләп белә иде. 2005 нче елның 14 нче маенда әнкәем дә дөнья белән хушлашты. Дүрт айдан сиксән сигез яшь тулган булыр иде аңа.

Әнкәем, мәрхүмә, хәтерен дә югалткан иде соңга таба. Сорый иде: «Минем исемем ничек, белмисеңме?» — дип. «Синең инәң юкмыни соң ул?» — дигән чаклары да бар иде. «Миңа рәшәткә алып булашма, әнә, келәтне илт тә куй»,— дия иде.

Гәүдәгә бәләкәй генә булса да, ул үзенә буйсынганны ярата иде, бик таләпчән булды. «Миңа бит инде алтмыш яшь, син һаман да мине өйрәтәсең», — дисәм, «Бәй, Виниса, сине кемдер тәрбияләргә тиештер бит»,— дия торган иде. Мин тиз онытучанмын, шуңа да мине: «Менә бу башың белән ничек ун ел укыдың?» — дип шелтәли иде.

Әнкәем әткәемә гомергә тугры булып калды. Кунакка да бергә бара идек. Свердловскига күчеп киткәндә миңа ундүрт яшь кенә иде, мине гел үзе белән иярттеп йөртте. Бер чит ирнең дә әнкәйгә кулын салганын күргәнем булмады.

Ялгыз көннәр, ялгыз төннәр,
Зарыгып үткән еллар...
Абындырса да, екмаган,
Алга әйдәгән юллар.
Шатлыгың да, борчуың да
Мин инде ул, мин — кызың,
Икәү бергә җитәкләшеп
Үткәнбез гомер юлын.
Багышлагансың үзеңне
Миңа, җан җимешеңә.
Шундый гына бәхет синең
Тигәндер өлешеңә.

Шушы шигырь юлларын язган идем әнкәемнең сиксән яшенә. Дөнья булгач, төрле чаклар була, катырак бәрелгән чаклар да булгандыр инде, алай үзем беренче тиргәшә башламый идем.

Әнкәем бик изге, ярдәмчел иде. Үзе таләпчән, кискенрәк кеше булса да, бәлагә дучар кешеләрне бик кызгана, ярдәм итәргә һәрчак әзер иде. Артык та гадел булды, урлашканны, алдашканны бер дә яратмады. Әнкәемнең бер гөнаһы да юктыр Ходай алдында, дип уйлыйм, үземчә. Инде урыннары оҗмахта булсын безнең өчен җан атып гомер кичкән газизләрдән-газиз әнкәйләрнең!

БӘХЕТ ЯЗМЫШТА ИКӘН

Сугыштан соңгы еллар. Ач та түгел, тук та түгел чагыбыз. Кием дә шул бер генә кат. Бар да түгел, юк та түгел. Өстә бер күлмәк тә бер фуфайка. Шуңа күпләр, мөмкинчелеге булганнар, җиңел тормыш эзләп, читкә чыгып китәләр. Әлбәттә, читтә дә затлы сарайлар ишеген киң ачып безне көтеп тормый. Шәһәрнең дә үз кыенлыклары күп. Бәхетеңә, әгәр була калса, тулай торакта бер койка.

Ничек кенә дөнья авыр булмасын, күңел ачарга да вакыт табыла иде. Шулай беркөнне Даян исемле егетнең туган көнен билгеләп үтәргә булдылар. Ул бүлмәдә яшәгән егетләрне, күрше бүлмәдәге кызларны чакырды. Кичә бик күңелле үтте. Артык күп эчмәсәләр дә, шәраб кайберәүләрнең башына тиз китте, күрәсең. Исерештеләр. Таралышырга вакыт җитү белән кызлар үзләренә чыгып китте, егетләр — үзләренә. Ул вакытларда тәртипле иде кызлар да, егетләр дә.

Даянның беренче тапкыр исерүе иде. Ул, башы әйләнә башлагач, урынына ауды да йоклап та китте. Төнлә кинәт кенә уянды да, йомышын йомышлау теләге белән ишекне ачып, бәдрәфкә таба атлады. Гөнаһ шомлыгына, бу төнне тулай торакта

бөтенләй ут юк иде. Ул стена буйлап ишекләрне капшый-капшый сыйпанып килде, үзләре яшәгән бүлмәгә җиттем дип уйлап, ишекне ачты да койкага менеп ятты.

Йокылы-уяулы Дания стенага карап ятканда, кемдер артына килеп ауды. Ул нәрсә булганын аңламый да калды. Салкын төннәрдә кызлар өшесәләр, бер-берсенең янына килеп сыенышып яту гадәте булганга, «Асиядер, тагын өшегәндер дә йокы аралаш килгәндер» дип уйлап, аның да өстенә юрганын ябу теләге белән борылган иде ... ушы китте. Караса, аның янында Асия түгел, Даян ята. Тәрәзәдән төшкән тулган ай нуры яктысында ул егетне тиз таныды. Хәер, Даянны ул, арты белән кап-кара морҗадан төшеп килгәнен күрсә дә, таныр иде. Кыз күптән бу егеткә күз салып, аңа булган мәхәббәтен беркемгә дә әйтми, белгертми яшереп йөри иде. Тормышка ашмас хыялы иде аның өчен ул. Дания үзе төскә дә әллә кая китмәгән: бәләкәй генә буйлы, җирән чәчле, сипкелле бер кыз булу өстенә артык оялчан да иде. Шундый егетне эләктереренә өметен өзеп, аңа күз салганына үкенеп, онытырга да тырышып караган иде... Тик мәхәббәтне тыеп, боерык биреп кенә онытып булмый шул! Ничек кенә тырышса да, Даян аның татлы теләге булып хыялында, йөрәгенең бер түрендә урын алып яши бирде. Ә бүген көтмәгәндә-уйламаганда үзе килеп янына ятты...

Дания төскә чибәр булмаса да, бик зирәк иде. Тиз төшенеп алды бу хәлне: бу аның өчен күктән төшкән бәхет. Шушындый пәһлеван кебек чибәр егетне кайчан очратыр?! Ул Даянның өстенә япты, кочагына алды һәм, кыймылдарга да куркып, шым гына ята бирде. «Инде кызлар гына уянмаса ярар иде», — дип уйлады. Менә бит, Ходай аның теләген

ишеткән. Бәхетне үзе китереп тоттырды... Шулай шатланып уйланып ята торгач, изрәп йоклап та китте.

Көн яктыра башлады. Эшкә барырга вакыт җитте. Иң беренче Соня уянды. «Әнә, күрегез, тын күлгә шайтан ияләшә», — дип сөйләнеп шыпырт кына башка кызларны уята да башлады. Кызлар, бу хәлне күреп, телсез калдылар. Әлбәттә, Даниягә шундый адымга барыр дип һич көтмәгәннәр иде. Алай гына түгел, «Бу сары чебешкә кем карасын инде?!» — дип үзалларына гына аңардан көлеп тә йөриләр әле. Менә сиңа мә! Кемгә караган? Шушы чәкүшкә буйлы Даниягә, гарьләнеп үләрсең!

Даян, уянгач, үзе дә аңламый, күзләрен шар ачып, бер Даниягә, бер кызларга карап торды. Ничек инде ул кызлар бүлмәсендә? Ничек килеп кергән? Кем керткән?.. Аннан төнлә торып бәдрәфкә чыкканын исенә төшерде. Исерек башы белән бүлмәне бутаганын аңлады да, беркемгә берни дә әйтми, тиз генә сикереп торып, чыгып та китте.

Инде көндезгә бу хәлне бөтен завод халкы белә иде. Табигатьтән тыйнак, аз сүзле, эчми, тартмый торган бу егет бөтен кызлар хыялында булды. Ә Даянга нишләргә? «Нишләдем? Барысына да шушы аракы гаепле...» — дип үз-үзен өзгәләде ул. Бу оят иде аның өчен. Бигрәк тә Даниядән кыенсынды. Очраганда аңа күзен дә күтәреп карарга оялды. «Яхшылар исәбендәмен, җитмәсә, партия әгъзасы. Парткомга бу хәбәр барып җитсә, хушлаш та куй партбилетың белән...» — дип уйлап, куркып та йөрде. Ә партбилет белән хушлашу ул елларда ун елга төрмәгә утыру белән бер иде.

Шулай йөри торгач, бер ай чамасы вакыт үтеп тә китте. Партком да чакыртмады, партбилеты да үзендә калды. Бар да тынычланды. Тик Дания генә

тынычлана алмады. Көннән-көн әкрен генә үзеннән читләшә башлаган егетне кыз, үзе әләктерергә кирәклеген аңлап, хәйләләргә булды. Беркөнне алар Даян белән күзгә-күз очраштылар. Ни булса да шул булыр дип уйлап, күзен күтәреп карарга да оялып басып торган Даянга Дания сүз башлады: «Безнең бит балабыз була. Ни уйлыйсың?» — диде. Егетне яшен суккан кебек булды. Тәмам башы буталды. Ул шунда кызга беренче тапкыр игьтибар белән карады. Бик сөйкемле икән бит. Нишләп ул моңа кадәр аны күрмәгән? Моңлы карашлы зур соры күзләре, алсу төсле күбәләк канаты кебек иреннәре кабатланмас гаҗәеп матур. Беренче тапкыр күргәндәй, Даян аңа бакты. Дания үзенчә чибәр иде. Ул аның тыйнак матурлыгына гашыйк булды.

Әйе, Дания беренче карашка гына шулай күзгә ташланып тормый. Акылы белән дә, уңганлыгы белән дә ул күпләрдән өстен. «Бәләкәй булса соң, алтын зур буламы?! Үзе житез, үзе эшчән, исеме почет тактасында», — дип уйлады Даян да. Җитмәсә, исемнәре дә бик якын. Тыйнак, оялчан булулары белән дә бик охшаш иде алар.

Шулай итеп, болар, туй үткәреп, бергә яшәп тә киттеләр. ЗАГСка да керделәр. Бераз торгач, завод бер кечкенә бүлмә бирде үзләренә. Ул бүлмәгә чын күңелдән сөенделәр. Ул аларга патша сарае кебек тоелды. Бәбиләре дә туды.

Дания бик әйбәт хуҗабикә дә, уңган, акыллы хатын да, хәстәрле ана да булып чыкты. Ашарга һәрвакыт әзер. Кер юылган, үтүкләнгән. Өй эче ялт итеп тора. Нәрсә әйтәсең инде?! Өстәвенә, бик тыныч, сабыр, итагатьле. Мондый хатын турында кемнәр генә хыялланмый икән?! Даян эштән кайта, ашый да баласы белән мәш килә.

Дания, буш вакыты булса инде, кул эше белән булаша. Бәйләргә дә, тегәргә дә өйрәнде. Тора-бара фатирлы да булдылар. Тагын ике балалары туды.

Даян бер генә тапкыр да үкенмәде Даниягә өйләнгәненә. Киресенчә, ул бик рәхмәтле иде теге саташкан көненә. Бәхет чибәрлектә дә, буйда да түгел икән. Бәхет язмышта икән.

ӘЛ ДӘ СИН БАР

Газинур бәләкәйдән бик тырыш һәм акыллы булып үсте. Җиде классны тик «бишле»гә генә тәмамлап, таныклык алу белән туп-туры авыл хуҗалыгы училищесына укырга керде. Анда да ул үзен сынатмады, тик яхшы билгеләргә генә укыды. Диплом да алгач, аңа үзләреннән ерак кына урнашкан чит бер районга эшкә китәргә юллама бирделәр. Башта аның үз авылына кайтып, әти-әнисенә дипломын күрсәтеп, алар белән рәхәтләнеп утырып сөйләшәсе, шатлыгы белән уртаклашасы килде. Аны әти-әнисе дә сагынып көтеп торалар иде. Дипломны күргәч, әнисе сөенеченнән елап та алды.

Үзләренчә табын корып, дөнья хәлләрен сөйләшеп утырдылар да йокларга яттылар. Иртән-иртүк егет юлга чыгарга тиеш иде. Ул хыялый уйларга чумып озак кына йоклый алмый ятты. Төрле уйлар килде башына: «Ничек эшли башлармын икән? Ничек каршы алырлар? Иялəшеп китеп булырмы?» Ни әйтсәң дә, чит авыл, чит район бит.

Иртән уянса, әнисе елый. Нәрсә булган?

— Әни, нәрсә булды сиңа? Әллә авырыйсыңмы? — дип, ул әнисен барып иңбашыннан кочып алды.

— И-и, балакаем, Герман безгә сугыш башлаган. Сине дә алып китәчәкләр бит инде. Әтиеңне дә... Сиңа да 18 яшь бит... — дип, улының күкрәгенә капланып үксеп-үксеп елады.

Сугыш чыккан! Бөтен хыяллары бер мизгелдә өзелде, өмете киселде яшь егетнең. Ичмасам, берәр ел булса да эшли алмады бит... Шулай итеп, ул беркая да китмәде.

Берничә көннән аларга повестка китерделәр, сәгать иртәнге унга ул районга хәрби комиссариатка барып җитәргә тиеш иде. Икенче көнне әтисе Газинурны, атка утыртып, районга озата китте, ә әнисе авыл башында исән-имин кайтуын теләп, елап калды... «Елама, әни, Герман ул үз башына котыра. Без җиңәбез аны, кайгырма, мин кайтырмын», — дип кенә егет әнисен юата алды. Андый чакта юатырлык җылы сүзләр табуы да авыр шул. Һәм ул үзенә сүз бирде. Әйе, Газинур әнисе хакына, туган иле хакына көрәшергә һәм исән калырга тиеш иде... Юккамыни ул ничә ел буе тырышыптырмашып ачлы-туклы укып йөрде?! Аны алда әле зур уңышлар, эшләр көтәчәк. Ничек кенә авыр булса да, ул кире кайтуга өметен югалтмады...

Озак та тормый Газинурның әтисен дә сугышка алдылар. Бу хакта ул әнисеннән хат алгач кына белде. Вакыт шулай уза торды, көнне төнгә, айны айга ялгап, олы газаплы дүрт ел үтеп китте. Сугыш вакытындагы интегүләрне, аерым берничә китап итеп язсаң да, язып кына бетерерлек түгелдер.

Ниһаять, 1945 елның 9 нчы мае — Җиңү көне — җитте. Яу кырыннан исән калган солдатлар кайта башладылар. Әйе, исән калганнар. Тик аларның күбесенең тәнендә җаны гына калган иде. Аяксыз-кулсыз калганнарны да тыны белән тартып алырдай булып көтте якыннары. Бер генә тапкыр

да яраланмаган кеше бик аз калгандыр бу сугышта. Шулай, бер ямьле көнне, җәй уртасында, Газинур да хәрби киемдә елмаеп әнисе каршысына килеп басты. Әнисенең никадәр сөенүен сөйләп кенә бетерерлек түгел. Әйе, Газинур сау-сәламәт кайтты, тик әтисе генә яу кырында ятып калды.

Дүрт ел эчендә, ир-ат кулы тимәгәч, йорт-каралты тирәсендә дә эшләр күбәйгән, җимерелә башлаган урыннарны төзәтәсе бар иде. Газинур кайтып керү белән, кулына чүкеч, кадак тотып, шап-шоп килеп төзәтергә кереште. Тик әнисенә озак булыша алмады, аны районга чакырттылар. Авыл хуҗалыгы белгечләре ул вакытта бармак белән генә санарлык иде шул, алтын бөртегенә тиң иде.

— Энем, күләгәдә ял итеп ята торган вакыт түгел. Илне аякка бастырырга кирәк. Сине «Октябрь» колхозына председатель итеп җибәрергә булдык. Син инде малай-шалай түгел, менә дигән егетсең. Әйдә, җиң сызганып эшкә тотын, — диде райком секретаре Газинурга.

Елап озатмады Газинурны әнисе бу юлы, хәтта горурлык чаткысы да сизелә иде йөзендә. Егет икенче көнне иртүк китәргә җыена башлады. Солдат котомкасына бер чәркә, бер стакан, кашык, бер-ике телем икмәк салып, җәяүләп кенә чыгып китте ихатадан. Унбиш чакрым араны тиз үтте. Ике сәгать эчендә барып та җитте. Туп-туры идарәгә барып керде. Авылның аксакалы Әхмәлетдин абзый тәмәкедән саргаеп беткән тешләрен күрсәтеп, колач җәеп каршы алды Газинурны.

— Менә, энем, сиңа пичәт, менә чутлар, эшлә генә. Мин картайдым, минем белемем дә юк. Бик әйбәт булды килүең. Өй дә әзерләп куйдык үзеңә. Анда бер кеше дә тормый. Юыштырдык, чистарт-

тык килүеңә. Ярар, бүгенгә ял ит, йортыңа урнаш, — дип, өен күрсәтергә алып китте.

Бәләкәй генә иске йортка барып керде алар. Бу өйдә күптән беркем дә тормаганга, ихатасын яшел чирәм каплап алган иде. Эче бик чиста итеп җыештырылган. Әллә нәрсәсе булмаса да, якты, нурлы булып күренде өй Газинурга. Бер сәке дә аварга торган бер өстәл генә иде. Яшәү шарты булмаса да, мичнең казаны бар иде. Шунда ук ашарга да пешереп була. Әлбәттә, Газинурның мич ягып, ашарга пешереп торырга вакыты да булмады. Бәхетенә, күрше апасы Мәһидә кергәләп ярдәм итеп торды. Үзе генә нәрсә эшләр иде икән?! Авыр сугыш елларын үткән, ач-ялангачлыгын да татыган халык өчен өстәлдә бәрәңге белән икмәк, илдә тынычлык булу зур бәхет иде.

Шулай көн артыннан көн үтте, көз дә якынлашты. Ялгыз яшәве авыр иде Газинурга. Өйләнергә карар итте. Авылга килеп урнашкан көнне үк укытучы булып эшкә урнашырга килгән бер Зөлфидә исемле бик матур кызга күз салган иде ул. Озын-озакка сузмый кызга кияүгә чыгарга тәкъдим дә ясады. Октябрь бәйрәмендә кечкенә туй ясадылар. Дөньялары, авырлык белән булса да, икесенең тырышлыгы белән җайга салынды.

Колхозга булдыклы рәис килгәч, авыл хуҗалыгы да тиз күтәрелә башлады. Кибетләргә чәй, шикәр, кәнфит кебек ширбәтләр кайтты. Мондый сый-хөрмәтне инде күптән күргәне юк иде авыл халкының. Күпләр Газинурга бик рәхмәтле булды.

Ә Газинурның тагын да күбрәк беләсе, югары белемле буласы килде: авыл хуҗалыгы институтына укырга керде. Зөлфидә дә педагогия училищесын тәмамлаган иде. Ул башлангыч классларны укытты.

Күрше Маһидә апалары бик әйбәт кеше булып чыкты. Апалары кебек якын күреп, кулыннан килгәнчә ярдәм итеп йөрде. Аның Маһинур исемле 4—5 яшьләрдәге бик матур кызы да бар, ул да әнисенә ияреп гел кергәләп йөрде.

Беркөнне Газинур төшке ашка кайткан иде. Өстәл артыннан торып, чыгып китәргә җыенганда, әнисенә ияреп тагын да Маһинур керде. Газинур кызны алдына күтәреп утыртты да аркасыннан сөеп торганда кечкенә бөкресе барлыгын сизде.

— Маһидә апа, Маһинурны врачларга күрсәткәнең булдымы? Аны әле соң түгелдер күрсәтергә? — дип сорап куйды.

— Әй, Газинур туганым, соңдыр инде, — дип көрсенеп сөйли башлады ул. — Бик бәләкәй чагыннан ук бит инде ул шулай. Әй, йөрәгем гел сыкрап кына тора инде аның өчен...

— Нигә аны башта ук миңа әйтмәдең соң?

— Колхоз хәтле колхозны тартып барган кешегә вак-төяк йомыш кушып буламыни?

— Бу бит, Маһидә апа, вак-төяк йомыш түгел. Кыз баланың язмышы бит.

— Шулай да соң. Кыенсындым инде әйтергә. Кызымны саклый алмадым дип үземне менә шулай туктаусыз өзгәләп йөрсәм дә...

— Ни булды соң?

— Каһәрле сугыш гаепле инде барсына да. — Маһидәнең күзләре яшьләнде. — Маһинур туган гына иде әтисен сугышка алганда. Ул киткәч, бер айдан «кара кәгазь» китерделәр. Әтисе үзенә бер тамчы судай охшаган кызын үзе үстерә алмады... Ә миңа нишләргә? Ир юк. Янымда аның әнисе — сукыр карчык та яшь бала. Мәрхүмнең күзе бөтенләй күрми иде. Кайгымнан тәгәрәп-тәгәрәп еладым да, каенанам карамагына баламны кал-

дырып, колхозга эшкә йөрдем. Бер яшь чамасы булганда сәкедән егылып төшеп аркасын имгәткән балакаем. Сукыр кеше бала карый аламыни инде?! Ничек егылганын да күрмәгән. Башта мин дә белмәдем, «Тамагы ачка елыйдыр инде», — дип уйладым. Тора-бара, бөкресе үсә башлагач кына, сорашкан идем. «Әйе, бер бик каты егылган иде шул. Әллә имгәнгән булганмы?» — ди.

— Ә врачка бармадың инде...

— Юк инде. Ул вакытта каян врач булсын?! Күбесе сугышта.

Газинур Маһидәнең сөйләгәннәрен игътибар белән тыңлап торды да, тирән көрсенеп, урыныннан кузгалды. Ишек төбенә басып киемен кигәндә бер Маһидәгә, бер Маһинурга карап:

— Алай да, күрсәтергә кирәк. Бәлки, әле соң түгелдер. Мин уйлап карармын, — дип, эшенә чыгып китте.

***

Газинур да, Зөлфидә дә бик яраттылар Маһинурны. Газинур кая гына барса да йә күчтәнәч, йә бүләк алып кайта иде аңа. Маһинур үзе дә, алар өйдә булса, үзләренә чыгып та тормый, шунда ук куна да кала. Икенче көнне әнисе аның артыннан кергәндә шаяртып: «Әллә сезгә генә күчсенме? Чыгып та тормый бит сездән...» — ди. Шулай алар бер гаилә кебек тату яшәделәр. Газинур Маһинурны төрле врачларга да йөртеп карады. Кызганычка каршы, инде соң иде.

Бераз яшәгәч, тормыш бераз яхшырды, җайга салынды. Бар да әйбәт кебек. Бар да җитә, ризык та, кием дә бар. Тик тулы бәхет өчен бала авазы гына

җитми иде. Тып-тын өйне яңгыратып сабый көлгән тавышны ишетәсе килә башлады Газинурның.

Беркөнне ул Зөлфидәгә: «Табибка күренергә кирәк, — дигән уен белдерде. — Нидидер чир булса, дәвалап була бит...» Хатыны берсүзсез риза булды. Район больницасы табибы, анализларны карагач: «Барысы да әйбәт, таза. Үзегездән генә тора эш», — диде елмаеп. Инде ни әйтер икән дип куркып көткән парны тынычландырып кайтарып җибәрде.

Көн артыннан көн һәм шулай берничә ел үтеп китте. Тик гаиләдә үзгәреш булмады. Зөлфидә чарасызлыктан әби-сәбиләргә дә йөрештерде, төрле үлән сулары да эчеп карады. Аның да Газинурны бәхетле итәсе килгән иде. Яшь балаларга ничек яратып караганын күреп, эче әрнеде. Беркөнне Газинур Зөлфидәне шәһәр дәваханәсенә илтеп күрсәтергә булды. Баш табиб: «Тикшерү үтәргә кирәк, болай гына бернәрсә дә әйтә алмыйбыз. Сезгә, монда калып, анализларыгызны бирергә кирәк булачак», — дигәч, Зөлфидә торып калды, Газинур кайтып китте.

Унбиш көн чамасы үткәч, Газинур хатынын алырга китте. Барып җитү белән тагын баш табибка керде. Ул аны бу юлы күңелсез генә кыяфәттә каршы алды. Газинурның йөрәге нәрсәдер булганны сизеп жу итеп китте. «Операция ясарга кирәк, яман шеше бар, — диде ул. — Күпме яшәр, әйтә алмыйм. Төрлечә була: кем ничек...» Бу куркыныч хәбәрне ишетәсе дә килмәде Газинурның. Йөрәгенә ук булып кадалды. Тик бу турыда хатынына ләм-мим. Хәтта никадәр кайгырганын йөзенә дә чыгармаска тырышты. Ул Зөлфидә яткан палатага елмаеп килеп керде. Зөлфидә, барысын да белеп, әйтмәсәләр дә, сизеп тора иде инде. Ул да иренә

никадәр борчылганын күрсәтмәде. Эчендә ут янса да, елмаеп каршы алды да елмаеп озатып калды.

Операцияне җиңел үткәрде Зөлфидә. Берничә көннән хәле дә әйбәтләнде. Бала турында Газинур бүтән бер сүз дә кузгатмады. «Баласыз яшәгән кешеләр бар, яшиләр бит, без дә яшәрбез...» — дип уйлады. Аның өчен Зөлфидәнең исән калуы мөһимрәк иде. Хәзер алар бөтен мәхәббәтләрен Маһинурга биргәләр иде. Озын куе керфекләре, зур коңгырт күзләре, сызылып торган кара кашлары, бит очындагы чокырлары әллә кемне дә яраттырырлык иде. Тик аркасындагы бөкресенең үсүе Маһидәне генә түгел, Маһинурны да, Газинур белән Зөлфидәне дә борчуга сала бирде.

***

Бик зур булмаса да, өр-яңа йорт та салып куйды Газинур. Йорт-җиһазлары да тергезделәр. Тагын дүрт ел үтеп китте. Зөлфидә кабат авырый башлады. Чак кына эшләсә дә, хәле бетә иде. Маһинур да зур, акыллы булып үсте. Зөлфидә апасына гел ярдәм итәргә тырышты. Апасын кызганып еласа да, үзенә сиздермәде. Киресенчә, бар булмышы белән караңгы көнен яктыртып, аның күңелен күтәрерлек җылы сүзләр әйтеп юата белде.

Җәйне күрә алмады Зөлфидә ул елны. Агачлар чәчәкләрен койганда якты дөнья белән хушлашты. Газинур бөтенләй бөсгып калды. Яшәвенең ямен югалтты. «Авыр кайгы бер елга бара, аннан соң әкренләп онытыла», — ди халык. Онытылмаса да, бераз тынычландырадыр. «Үлгән артыннан үлеп булмый, калган кешеләргә алга атларга кирәк», — дип уйлап, Газинур да бераз тынычлана төште. Иң

якын кешеләре булып Мәһидә белән Мәһинур гына калды. Алар аның иң авыр көннәрендә һәрвакыт янында булдылар.

Мәһинур мәктәпне бишле билгеләренә генә тәмамлады. Сыйныфташлары төрлесе төрле якка, кайсы белем алу теләге белән, кайсы тизрәк эшкә урнашырга ниятләп, авылдан чыгып киттеләр. Ә Мәһинур, гариплегеннән оялып, канаты каерылган кош сыман авылда торып калды. Газинур чын күңеленнән кызны кызганды. Акыллы кызның белемсез калуы аның эчен пошырды.

— Мәһидә апа, — диде ул беркөнне, — әйдә мин Мәһинурны авыл хуҗалыгы техникумына илтим.

— Юк инде, Газинур туганым, ул чирләш баланы анда җибәреп интектермим. Әле менә, укымасам да, кешедән ким яшәмим. Кулымнан бөтен эш килә, — дип кырт кисте дә куйды Мәһидә.

— Читтән торып укырга да була бит... Син дә мәңгелек суы эчмәгәнсең, дөньяны белеп буламыни?! — дип үгетләргә тотынды Газинур салмак кына сөйләп. — Соң Мәһинур савучы булып эшли алмас бит. Инвалидлык пенсиясе бик аз. Аңа бит яшәргә кирәк. Кеше белән аралашырга кирәк. Ул бит чирле түгел. Бер җирен дә авырта дигәне юк. Читтән торып укыса, мин дә ярдәм итәрмен. Бухгалтерлыкка булса да укысын. Шушы тиклем дә акыллы кыз нишләп өйдә бикләнеп утырырга тиеш әле?! Ризамы?

— Риза, әл дә син бар, Газинур туганым, безнең бәхетебездән. Нишләр идек?! — дип шатлыгыннан Мәһидә күз яшьләренә ирек бирде.

Сүзендә торды Газинур, алып барып укырга кертте Мәһинурны. Дөресен генә әйткәндә, аның үзенең дә кызны еракка җибәрәсе килмәде. Ул аңа һәрвакыт сокланып, яратып карый иде, күңеле

башкаларны күрмәде дә. Дөрес, димләүчеләр, күз салучылар да күп булды Газинурга. Ул берничек тә беркемгә дә игътибар итмәде. Тик бер Маһинур гына булды күңелендә. Үзен шелтәли дә иде кайчак: «Шушы яшь кенә кыз нишләп минеке булсын, ди, инде. Мин, карт юләр, һаман шуны аңлый алмыйм...» Андый уйларын куарга да тырышып карады, тик мәхәббәтне күңелдән тартып өзеп ташлап кына булмый икән шул. Бу хис инде тамыр җәйгән, йөрәге белән күңелен генә түгел, бөтен күзәнәген биләп алган иде.

Маһинурга калса, инде аның йөрәгенә әллә кайчан кереп утырган иде Газинур. Маһидә дә моны тиз сизде. Әни күңеле сизгер була бит. Ул инде: «Нишләп шушындый сөлек кебек чибәр ир бөкреле гарип кызга карасын, ди?! Бу турыда уйларга да ярамый...» — дип фикер йөртә иде. Кыскасы, өчесе дә үз уйларын эчтән генә уйлап йөрделәр.

Җәй үтеп китте, Бөек Октябрь бәйрәмнәре дә килеп җитте. Туйлар чоры башланды. Ни әйтсәң дә, түземлекнең дә чиге була. Газинур беркөнне колхоз йомышы белән шәһәргә китте. Кичкә әйләнеп тә кайтты. Күчтәнәчләр, бүләкләр төяп кайтты ул. Бүләкләр күбрәге Маһинурга иде. Тиз генә булган тәм-томнарын өстәлгә куеп, чәй әзерләде дә Маһидә белән кызын кунакка чакырды. Алып кайткан бүләкләрен бирде.

«Киеп тә күрсәт инде, Маһинур, әйдә!» — диде әнисе, кызы өчен сөенеп. Маһинур оялып кына зәпзәңгәр, борчаклы күлмәкне алды да кигән күлмәге өстеннән генә киеп тә куйды. Стенада эленеп торган көзге алдында бөтерелеп алды. «И-и, кызым, рәхмәт әйт инде абыеңа сине шулай зурлаганы өчен, бигрәк килешә үзеңә», — дип, Маһидә Гази-

нурга карап куйды. Ә ул кулмәкләренә сөенүдән көзге алдында әле бер ягын, әле икенче ягын әйләнә-әйләнә караган Маһинурга сокланып утыра иде. Кокеткалы күлмәкне Газинур абыйсы юкка гына алмаган. Ул аркасындагы бөкресен бөтенләй белендерми, тигезләп тора иде. Маһидә апасын да буш калдырмады Газинур, матур бизәкле, чуклы шәл бүләк итте. Әле аның андый бүләкне үз гомерендә беркемнән дә алганы булмады. Маһидә эчендәге шатлыгын яшерә алмады. Кызы өчен дә, үзе өчен дә бик сөенде. Ә Газинур аларның шатлашканын күреп шатланды. Чәй эчә-эчә гөрләшеп сөйләштеләр дә сөйләштеләр. Тик менә Газинур гына белмәде ничек сүз башларга. Эчендә булган тойгыларны ничек ачып салырга соң? Бераз утыргач ул:

— Маһидә апа, син үзең дә сизеп йөрисең инде, күреп торам. Мин Маһинурны үлеп яратам, ул да мине, сизеп торам, — дип сүз башлады.

Бу сүзләрне ишеткәч, Маһинур кып-кызыл булып башын иде.

— Газинур туганым, ул әле бала гына бит.

— Маһинур, әлбәттә, яшь инде, — дип дәвам итте Газинур. — Мин дә бик үк карт түгел әле. Аңа 18 яшь тулгач, язылышырбыз. Үзем укытырмын. Синең дә, Маһидә апа, өең иске. Кышларын салкын. Җәфа чигеп яшисез. Кыскасы, сезне үземә яшәргә чакырам. Бу өйгә без барыбыз да сыябыз. Тик каршы гына килмәгез.

— Мин каршы килмим дә соң... — дип, Маһидә көтелмәгән тәкъдимнән уйланып калды, аннан сөенеченнән елап ук җибәрде. Чынлап та, соңгы елларда алар кызы белән бик җәфаланып яшиләр иде. Кешеләрнең менә дигән кызларына да мондый кияү тәтеми, менә сиңа бәхет! Бит күпме

яшьләрен түкте ул шушы баласы өчен. Житмәсә, үзен дә бергә яшәргә чакыра.

— Төш түгелме бу, туганым?

— Өн бу өн, Маһидә апа. Чынлап әйтәм. Минем бу авылда сездән башка якын кешем юк. Үзебезнең авылда әнием генә калды. Аны да үземә яшәргә чакырган идем, ризалашмады. «Әле көчем бар чакта үземнең нигеземдә, атаң салган йортта яшим», — ди. Кыскасы, өем сезнең карамакта. Бүгеннән күченә аласыз...

Әнә шулай башланып китте аларның тормышлары. Авыл халкы өчен бу көтелмәгән хәл булды. Тел чарлаучылар да күп иде. Кемдер Газинурны бу адымы өчен мактады, кемдер ошатмады. Бигрәк тә аңа күз салып йөргән хатыннар көнләшүләреннән нишләргә дә, ни сөйләргә дә белмәделәр. Бер ел үтүгә ничә еллар бала көтеп зарык булган Газинурның тупылдап торган малае туды. Бу бала бик газиз булганга, Газиз дип исем куштылар. Ниһаять, Газинур бәхетнең ни икәнен татыды, ә Маһинур иренә назлы карап: «Әл дә син бар», — дип әйтергә ярата иде. Бу сүзләргә аның тулы бәхете дә, якты киләчәккә өмете дә, изге мәхәббәте дә, чиксез рәхмәте дә сыйган иде. Әл дә син бар!

ЯЗМЫШМЫ БУ?

Мәктәптә дүртле һәм бишле билгеләренә генә укыса да, Ириса уку йортына керә алмады. Зур гына бер заводка токарь станогына өйрәнчек булып эшкә урнашты. Тиз өйрәнде ул эшкә. Күп кенә эш хакы да ала башлады. Янында эшләгән иптәшләре белән дә тиз арада уртак тел тапты. Бик мавыгып

эшләде ул. Эшкә, бәйрәмгә баргандай, канатланып бара иде. Шунда ук үзенә ахирәтләр дә тапты. Кыскасы, институтка укырга кералмаганенә Ириса һич кенә дә үкенмәде. Алай да югары белем алырга өмете сүрелмәгән иде. Гомер озын, әле укырга өлгерермен, дип үзен юатты.

Беркөнне иптәш кызы белән киногэ барырга булдылар. Билет соңгы сеанска гына калган иде. Үзләренең рәтен табып кереп утыру белән, Ириса янәшәсендәге урында утырган кешегә күз сирпеп алды. Аның янында бер матур егет утыра иде.

Яшьлек бит! Дәртле чак. Аны күрү белән ул: «Илаһым, ул шундый сөйкемле! Озын буйлы... Куе бөдрә сары чәч, зур зәңгәр күзләре, кызларга гына хас ап-ак йөз...» — дип уйлап алды. Ириса да бар булмышы белән артистлардан ким түгел иде. Карлыгач канатыдай сызылып торган кашлары... Куе озын керфекләре... Зәңгәр күзләре генә дә ни тора! Төпсез күлмени? Озак карап торсаң, аңа кереп батарсың төсле... Әйе, бар шундый күзләр. Ириса да шундый сихри карашлы иде. Ә егет бик мут булып чыкты. Янында утырган гүзәл кызга ул шунда ук игътибар итте дә сүз дә башлады:

— Сезнең белән танышырга буламы? Минем исемем Андрей. Сезнеке ничек? — дип сорады егет Ирисадан.

— Ириса, — диде кыз, зур күзләре белән егеткә төбәлеп.

— Сеанс беткәч, сезне озата барырга буламы?

— Була, — дип җаваплады елмаеп кыз.

Аның шул елмаюы егетнең йөрәген сихерләде дә инде.

Ириса кинотеатрдан бик ерак тора иде. Апасының гаиләсе ишле булгач, аны бер таныш ялгыз әбигә фатирга кертте. «Әбигә дә ярдәм итәрсең,

иптәш тә булырсың», — диде апасы. Әби дә куш-куллап риза булды. «Үзе мөселман баласы, татарча сөйләшергә кеше булыр», — дип сөенде әби. Фатир дип, бер зур гына барак өендәге бүлмә иде инде ул. Янәшәдә генә зират. Шуңа да төнге сәгатьләрдә кайтканда бик куркыныч иде берәдә йөрүе. Ириса егетнең тәкъдименә сөенеп тә куйды әле.

Сеанстан соң Андрей озата барды кызны. Егет шундый тыйнак тотты үзен! Аның тыныч холкына карап сокланырлык иде. «Менә, эчмасам, егет! Моның белән җирнең читенә дә китеп була. Бик ышанычлы күренә», — дип уйлады Ириса аның белән янәшә барганда.

Иртәгә кич тагын очрашырга сөйләштеләр. Бу ике яшь йөрәк тора-бара бер-берсенә гашыйк булды. Шундый мәхәббәт, шундый сөю романнарда гына була торгандыр... Тик Ирисаның әтисе белән әнисе ни әйтер? «Әгәр Андрей миңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясаса, риза булмаслар инде» дигән уй борчыды аны. Чынлап та, әнисе белгәч, кызы өчен сөенмәде. «Шушы төсең, шушы буең белән татар егете таба алмассыңмыни?!» — дип кызын бик каты тиргәде. Ни эшләсен соң, йөрәккә боерык биреп булмый. Ул беркемнең дә сүзенә карамастан, Андрейны өзелеп яратты. Шундый яратты, араларына җил дә кермәслек иде. Тагын бераз йөргәннән соң өйләнешергә сүз дә куешты яшьләр.

Андрей Ирисаны дусларына бер дә күрсәтмәде. Аларга белгертмәскә тырыша иде. Андрей авыл егете булгач, кыз аның әти-әнисен дә бер дә күрмәде. Егет алар хакында артык сөйләми: «Авылда торалар», — дип кенә әйтте. Шуңа да Ириса аның тормышы турында бернәрсә дә белми иде. Мәхәббәттән башы әйләнгән кызны егетнең үткәне

бөтенләй кызыксындырмый иде. Аның янында булу гына да Ириса өчен олы бәхет булды.

Андрей, Ирисаны озатып кайткач, йоклый алмады, түшәмгә карап бик озак кына уйланып ятты. «Нинди гүзәл кыз! Кыз түгел, алиһә бит бу! Ә мин кем? Ул кем икәнлегемне, нинди юлга төшкәнемне белсә, миңа сәлам дә бирмәс иде бит...» — дип өзгәләнде.

Андрей үзенең упкынга төшкәнен сизми дә калды. Әйе, аның тормышы чыга алмаслык упкынны хәтерләтә иде. Кемнәрне генә рәнҗетмәде ул үз гомерендә, кемнәрне генә кыерсытмады! Күпме рәнҗеш!.. Күпме күз яше!.. Моның ахыры бер килеп чыгарын, хәерле булмасын ул үзе дә аңлый иде. Тик бу юлга бер кергәч, тиз генә тайпылып чыгып китеп булмый икән. Котылгысыз иде. Көннәр үтү, еллар үтү белән моның афәткә алып барганын төшенгән саен, ул ныграк кайгыра. Һәм туктаусыз үкенә иде.

«Ничек болай булды соң әле?» — дип, шул упкынннан чыгар юл эзләгәндәй, үткәнен искә төшереп газаплана иде. Башта шешәдәш дуслары, аннан башкалары барлыкка килде. Авылдан чыгып киткәндә ул бит аракының тәмен дә татымаган саф күңелле егет иде. «Эчмим», — дисә, дуслары буынга төшеп кыстап эчерделәр. Эчкән кешене эштә дә тотмыйлар бит инде. Эчәргә аракы кирәк. Каян алырга? Урлашырга гына кала. Әйе, башкаларга ияреп, урлашты да Андрей, кеше дә талады. Тик урланган, таланып алынган акчалар аңа бәхет китермәде... Эчүгә, кәрт сугуга китә барды. Җыелышып, төне буе эчтеләр, акчага кәрт суктылар. Откан чаклары да булды аның, отылган чагы да. Шулай булгач, иртүк торып эшкә барып буламы? Кичә дә төн буена кәрт суктылар. Андрейның

түләргә акчасы калмагач, «Красоткаңны саласың инде», — диде Король ыржаеп.

Бу сүзләрне ишеткәч, Андрейның йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Корольгә каршы килүнең нәрсә икәнен аңлаганга, бераз уйланып утыргач, ул: «Ярар», — диде. Йә зур акчага, йә үлемгә иде аларның бу уеннары... Икенче төрле юл юк иде. Ирисаны кәрткә салганда, «Бәлки, җиңәрмен», — дип өметләнде. Башкача чарасы калмаган иде Андрейның. Әлбәттә, ул отылды. Кыз шушы көннәрдә бер айлык ялга китәчәген, «кара касса»да уйнаганын, аннан күп кенә акча алырга тиешлеген әйткән иде Андрейга сер итеп кенә. Бу аларның туйларына дигән акча булганга, ул егеттән берни дә яшерми иде. Ириса авылга кайтып, әтиәнисе белән сөйләшеп, аларның ризалыкларын алып килмәкче булды.

«Җомга көнне отпуск акчасы алам. Каршы алырга килерсең, яме», — диде Андрейга. Егет башын гына какты, ни өчендер ул бик боек иде, гадәттәгечә, матур итеп көлмәде. Бу хәбәрне ул башлыкларына җиткерергә тиеш иде... Иртәгәсе көнне Андрей иртән-иртүк туп-туры Король янына китте. Ирисаның күп кенә акча алачагын һәм төнлә зират аша эштән кайтачагын, тик бу эшкә үзенең катнашмаячагын әйтте.

— Акчасын алсагыз алыгыз, тик үзенә, зинһар, тимәгез, — диде Андрей ялварулы кыяфәттә.

— Без үзебез беләбез нишләргә! Ул безнеке хәзер... Нәрсә кызганасың аны, әллә синең гомереңә кызлар җитмәсме? — диде Король мыскыллы көлеп. — Әллә үз гомереңне бирәсеңме аныкы өчен? Ә?

Андрей ни әйтергә дә белми Корольнең почмактагы караватына барып ауды. «Вәт эләктем, —

дип уйлады ул, — үземнең гомеремне куркыныч астына куюю җитмәгән, инде Ирисаның да гомерен бизмәнгә салдым». Күңелен төпсез куркыныч бер бушлык биләп алды. Көне буе ятты ул анда. Ашамады да, эчмәде дә. Нинди уйлар гына килмәде аның башына?! Күңеленә бик авыр иде. «Ничек котылырга бу кабахәтлектән? Ничек бу залимнәр белән аралашып киттем соң мин?» — дип уйланып ята торгач, йоклап китте.

Король кайтып кереп аны уятканда, сәгать төп-төгәл кичке унбер иде. «Тор, нишләп ятасың? — дип кычкырды Андрейга. Аннан кисәтеп куярга да онытмады: — Кара аны! Алдаша калсаң...»

Ириса эшли торган завод ерак кына булса да, Андрей ун минутка алданрак барып җитте. Төнге уникe туларга ун минут калган. Бу вакыт эчендә ни кичергәнен аңлатырлык түгел иде хәле. Шушы мизгелне мәңгелеккә туктатасы килде Андрейның. Әллә көзге ачы җилдән, әллә куркыныч билгесезлектән егетнең бөтен тәне калтырады.

Менә сәгать уникe дә тулды, проходнойдан эшчеләр чыга башлады. Күп тә үтмәде елмаеп Ириса да килеп чыкты. Чыкты да сөйгәненең кочагына ташланды. Андрейның бөтенләй кәефе юк иде. Ә Ирисаның, киресенчә, күңеле күтәренке иде. Кулындагы акчасы өчен дә бик сөенгән иде. Ни дисәң дә, туй үткәрергә уйласалар, кемгәдер ялынып, бурыч алып йөрмәячәкләр. Көлеп-елмаеп, егетенә әллә ниләр сөйләде, тик Андрей аны бөтенләй ишетмәде. Сорауларына да җавап бирә алмады, борчылуы йөзенә чыккан иде. Кыз моны сизде, әлбәттә, тик игътибар итмәскә тырышты, чөнки бик бәхетле тойды үзен сөйгәне янында. Көзнең ачы җиле дә аны ишетмәде. Баганадан төшкән ут яктысына җиткәч, Ириса ябалаклап ява башла-

ган беренче карның бөртекләрен учына төшереп, «Кара әле, нинди матур!» — дип сокланды. Ә Андрей, киресенчә, бернәрсәне дә күрмәде. Аның өчен бөтен нәрсә шыксыз иде, көне дә үзәккә үтәрлек суык, төне дә куркыныч караңгы булып тоелды.

***

Атлый торгач, алар зиратка да килеп җиттеләр. Каберлек агачларга, вак куакларга күмелеп утыра. Кайбер агачлар әле яфракларын да коеп бетермәгән иде. Ай яктысы булмагач, шактый караңгы иде биредә. Зиратка кереп, бераз баргач,ерактарак куаклар артында яшеренеп торган дусларын абайлап алды Андрей. Килеп җиткәннәрен аңлатыр өчен җиңел генә сызгырып куйды. Аннан: «Мин хәзер», — дип, куаклар арасына кереп югалды. Ириса да аларны, ара ерак кына булса да, күреп алды. Шунда аны яшен суктымыни, әллә нишләп китте. Шулай да ул үзен тиз генә кулга алды. Бу шәһәрдә кеше үтереп йөрүче шайка барлыгын ишетеп белә иде. Ни буласын күңеле сизеп, ул тирә-якка күз ташлады. Шунда кыз үзеннән ерак түгел генә өсте бер-ике аркылы такта белән капланган бер тирән чокыр күреп калды. Дөресрәге, иртәгә күмеләсе мәетнең кабере иде бу. Ул озын-озак уйлап тормады, шунда сикерде. Төшкәндә ниндидер йомшак әйбергә басты. Ныклап караса, ни күрсен, кабер эчендә яңа гына үтереп ыргытылган, әле тәне дә суынмаган калын гына гәүдәле ир ята иде. Ул кычкырып җибәрүдән чак тыелып калды. Ничек кенә аңардан курыкса да, бу мәеткә караганда тегеләр куркынычрак иде. Моны бөтен йөрәге белән тойды Ириса. Шуңа

тизрәк яшеренергә кирәк иде. Ул кабер төбендә бөгәрләнеп яткан бу мәетнең астына ничек тә булса качып калырга кирәк дигән уйга килде. Ирисага каян куәт килгәндер, ул аны турайтып, астына көч-хәл белән кереп яшеренде. Озак та үтми тегеләрнең тавышлары ишетелде. Йөгереп килсәләр, кыздан җилләр искән иде.

— Кая? — дип акырды Король.

— Шушында көтеп калды... — дип Андрей мыгырданды.

— Көтсә, шунда булыр иде, алдадыңмы?

— Юк, алдамадым... билләһи, менә.

— Тапмасак, син дә беттең... — дип, Андрейга суккалап та алдылар.

Аның авыртынудан ыңгырашып куйган тавышы ишетелде.

— Өч сум өчен теге ирне манчыдык, өч йөз белән кызны югалттыкмыни инде... — дип үртәнде Король.

Ириса шунда гына аңлады Андрейның ни өчен үзен күңелсез тотканын. Алар ул яткан кабергә якын гына торалар иде. Кыз тын алырга да курыкты. Тапсалар, эш харап иде. Бирегә үрелеп кенә карамасалар ярар дип коты очты кызның. Бәхетенә күрә, берсе дә бирегә килеп карамады. Кыз бала шунда үзләре үтереп ташлаган мәет янына төшеп ятар дип алар башларына да китермиләр иде.

— Барыгыз, басып тормагыз, ерак китмәгәндер, сибелеп эзләгез! — дип акырып боерды тагын Король. — Ә син, аны тапмасак, икенчене үзең табып кулга тоттырырсың. Аңладыңмы? Синең өстеңдә кала. Инде өч йөз генә булмас! Мин сине процентка утыртам... — дип бик каты итеп сүгенеп куйды. Барысы да ашыга-ашыга кызны эзләп киттеләр...

Әлбәттә, Андрейның Ирисаны бу ерткычларга

бирәсе килмәгән иде. Күңеле белән: «Тапмасалар ярар иде», — дип уйлап тегеләргә эзләшкән булып йөрде... Аны чокыр янында калдырып китүе дә юкка түгел иде. Бу кабернең Ириса өчен качу урыны булырын башта ук шәйләде шул. Тик анда мәет ятканын белми иде. Барысы да сибелеп эзли башлагач, Андрей каберне килеп карады... Тик ул да анда кызны күрмәде. Кабер төбендә караңгы иде...

Ириса озак кына тыңлап ятты. Каядыр киттеләр. Бер тавыш та калмады. Тынлык урнашты. Шулай да чокырдан чыгарга курыкты. Хәер, чокыр да бик тирән һәм аншан, теләсә дә, чыга алмас иде. Ул көннс төне буе кар яуды. Әзрәк туңдырып та җибәргәнгә яуган кар эреп бетмәде, җир өстендә ятып калды. Ириса төне буе туңып калтыранды. Теше-тешкә тимәде. Туңудан аяк-кулларын сизми башлады...

Иртән, әле караңгыда, бер ир эшкә китеп барганда нindидер бер ыңгырашкан тавыш ишеткәндәй булды. Сагаеп тирә-ягына каранды, тик беркем дә юк. Тагын тыңлады, тагын көчсез генә тавышның ярдәмгә чакырганын ишетте. Бу ир ни кичергәндер, тик зират эченнән килгән моңлы ише тавышны ишетү йөрәге нык кеше өчен дә куркыныч хәл иде. Ә инде Ириса турында әйтеп торасы да юк! Кабер төбендә ни кичергәнен үзе генә белә иде...

— Коткарыгыз, зинһа-ар... — дигән тавыш көчәя төште. Бара торгач, ул кырыйдагы чокырны күреп калды. Якын килеп караса, төбендә нәрсәдер барлыгын шәйләде. Чокырның төбен әзрәк кар каплаган.

Ул йөгереп барып зират коймасының бер ягын көч-хәл белән тартып чыгарды да Ириса яткан кабер янына сөйрәп алып килеп, әкрен генә

аска төште. Төште дә өстә яткан карны ашыгып-ашыгып кулы белән ача башлады. Ниһаять, чистартып бетте. Караса, ир кешенең җансыз гәүдәсе ята иде. Тагын ыңгырашкан тавыш ишетте. Үлекне бераз этәреп караса, бер кызны күреп калды. Ириса тәне туңудан селкенә дә алмый ята иде. Ул, тизрәк аны чокырдан тартып чыгарып, үз киемен җиргә салып, өстенә хәлсезләнгән Ирисаны яткырды да ашыгыч ярдәм машинасын чакырырга йөгерде...

***

Дәваханәдә бу баланың тере калуына бар да аптырады. «Ничек тере калган, ничек туңып үлмәгән?» — диештеләр, ике аягын, ике кулын туңдырган, куркудан чәче ап-ак булган кызны күргәч. Ирисаның хәле бик авыр иде, үзе тере калса да, ике кулын беләзегенә кадәр, ике аягын тезенә кадәр кистеләр. Табиблар ничек кенә аны терелтергә тырышсалар да, туңган аяк-кулларын саклап алып кала алмадылар.

Унтугыз яшендә ул гарип булып калды. Ярты ел буе дәваханәдә ятарга туры килде аңа. Ул яшәвенең ямен бөтенләй югалтты. Бөтен уй-теләкләре, хыяллары бер төн эчендә челпәрәмә килде. Бу тиклем бәхетсез язмышка ничек түзәргә соң? Хәзер ничек яшәргә соң? Асылыныр иде, куллары юк. Югары каттан сикерер иде, аяклары юк... Чарасыз калган Ириса көне-төне елады...

Дәваханәгә кызның әти-әнисен дә чакырдылар. Әнисе кызын күрү белән йөрәге тотып егылды. Бер килсә килә бит. Гүя бәхетсезлек аларның ишекләрен шакып түгел, тибеп килеп керде. Шул

кайгыдан әнисе аякка баса алмады... Шул ук дәваханәдә дөнья куйды.

Кыз әтисе кулына калды. Ириса гаиләдә иң кече бала, иң яраткан кызы иде Гаязның. Ялгыз калган ирне кайберәүләр, кызганып: «Ничек карарсың инде? Картлар йортына бир булмаса», — дип үгетләделәр. Ни йөрәге белән газиз баласын анда бирсен, ди, инде. Гаяз ул хакта хәтта уйларга да курыкты. «Үзем исән-сау чакта беркая да бирмим. Ничек тә торырбыз әле», — дип кырт кисте.

***

Ирисаларның күршесендәге иске генә бер йортта Зәлбилә исемле бер тол хатын яши иде. Ул көн дә, матур күлмәкләрен киеп, кыз янына кереп йөри башлады. Гел, тәмле-тәмле күчтәнәчләр алып кереп, Гаяз белән Ирисаны сыйларга тырыша иде. Кыз янында сәгатьләр буе утырып, җылы сүзләре белән юатып чыгып китә. Бигрәк тә, Гаяз өйдә чакта керергә тырышты. Әтисенә күз салып йөргәнен кыз да сизде һәм беркөнне: «Әтием, сиңа берүзеңә генә дөнья көтәргә бик авыр. Әллә шушы Зәлбилә апаны үзебезгә торырга чакырабызмы? Минемчә, ул бу тәкъдимгә каршы килмәс. Ни дисәң, үзенең дә өе иске, кыенлык белән көн күрә. Бездә аңа да, безгә дә җиңел булыр иде», — дип әйтеп әтисен күндерде. Әлбәттә, бу тәкъдимгә Зәлбилә сөенә-сөенә риза булды. Шул ук көнне әйберләрен алып кереп тә куйды.

Башта Зәлбилә бик әйбәт кебек күренде. Йөгерә-йөгерә өй җыештырды, кер юды. Ирисага да ярдәм итте. Әтисе көне-төне эштә булгач, кыз Зәлбилә карамагында калды. Тик бик озакка бар-

мады Ириса өчен бу бәхет. Зәлбиләәкренләп үзгәрә башлады. Бераздан гарип курчак аны бөтенләй ялкытты. Элек сәгатьләр буе юатып, җылы сүзләр сөйләп утырганын, күчтәнәчләр алып кереп ярарга тырышуын бөтенләй онытты. Үзен бу өйдә хуҗаларча тота башлады. Ирисаның янына кереп хәл дә белми, юньләп ашатмый да иде.

Ириса көннән-көн күзгә күренеп ябыга башлады. Әтисе дә, кызы кинәт ябыкканга хафаланып, эштән кайткач та янына утырып хәлен сораша иде. «Ничек хәлең, кызым?» — дип сораса, Ириса беркемгә дә зарланмый: «Ярыйсы», — дип кенә җавап бирә. Барысын да сөйләп әтисен борчыйсы килмәде аның.

Яшь гомере, уй-хыяллары челпәрәмә килүдән, ачы язмышыннан, шушы хәлгә таруыннан йөрәге туктаусыз әрнесә дә, көннәр буе богып утырса да, зарланмады. Еш кына елап алса да, әтисенә күрсәтмәде, аңа болай да авыр икәнен ул яхшы аңлый иде. Шуңа Зәлбиләнең дә төртмә сүзләр әйтеп әрнеткәнен әтисенә әйтмәде. Барысын да йөрәгенә җыйды, эченә йотты. Аның саен Зәлбилә зәһәрләнеп җанын өтә торган сүзләрен ычкындыра иде. «Йөрмәсләр шпаналар белән чуалып... Кем гаепле синең шулай утыруыңа? Үзең гаепле... » — дип әрнетә торды.

Тора-бара Ирисаның хәле бөтенләй начарайды һәм бөтенләй урыныннан тора алмый башлады. Инде ашатырга теләсәләр дә, ашамады. «Болай, газап чигеп, кеше интектереп, имгәк булып яшәүдән үлгәнең мең артык», — дип уйлады үзе.

Кичтән Ирисаның тәне ут кебек янды. Хәле бик авыр булса да, ыңгырашмады. Ул су гына сорап эчте дә түшәмгә карап ята бирде. Утны сүндереп, йокларга яттылар. Йоклар алдыннан Гаяз тагын

килеп: «Берәр нәрсә кирәкмиме, кызым?» — дип аның хәлен сорашып китте. Тик Ириса эндәшмәде. Юк дигәнне аңлатып башын гына боргалады.

Бик иртә уянды Гаяз икенче көнне. Торды да кызының караваты янына килде. Ириса тын алмый иде инде. Маңгаена кулын куеп карады, тәне дә суынган иде.

Ириса үлгән көнне дә яңгыр катыш кар яуды. Әле гомер итә дә башламаган, шулай булуына да карамастан, бу дөньяның ачысын инде татып өлгергән кызны әнисенең янәшәсендәге каберга салдылар...

Барысы да кайтып китте, Гаяз ике кабер арасында үксеп елап калды. Күпме елагандыр, ул үзе дә белми. Бөтен әрнүен шунда түгеп калдырасы килде аның. Бозлы яңгыр катыш яше бите буйлап кызының каберенә акты да акты. Ирисаны, төпчек кыз булгач, бик иркәләп, назлап кына үстергәннәр иде. Ак туй күлмәге киярга язмаган Ирисага, ак кәфенгә төрергә язган икән... Гарип булса да, безнең арада яшәсен, кара гүрләрдә ятканчы якты җир йөзендә яшәү артыграк дип, яшәтергә дә тырышкан иде әтисе, тик булмады. Язмышмы бу, ялгышлыкмы? Аңлый алмады. Кызының гомеренә кул салучыларга бик каты рәнҗеде Гаяз... Җирне тырнап, әрнеп-әрнеп елады.

***

Бер атна чамасы вакыт үткәч, телевизордан яңалыклар карап утырганда, биш кешедән торган җинаятьчеләр төркемен суд җәзага тарттырганын күреп калды Гаяз. Кылган җинаятьләре өчен Король кушаматлы Костя исемле егеткә — 15

ел, калганнарына 10 ар ел бирделәр. Алар арасында Андрей да бар иде. Тик Гаяз нәкъ шушы җинаятьчеләр кызының башына җиткәнне белми иде.

АЙСЫЛУ

— Азат, кара әле күк йөзенә, нинди куркыныч кара калын болытлар томалаган, абау, бигрәк караңгы, әйеме, — дип, кыз күккә карап алды да, егетенең куенына ныграк сыенып утырып, күзләрен йомды.

— Әйе, Айсылуым, караңгы шул, — дип егет үзенә сыенган кызны, һәр яманлыктан ышыкларга теләгәндәй, бишмәтенең итәге белән каплап кысып кочаклап утырды. — Бүген, безгә юри үч иткән кебек, ай да юк, ичмасам... — Шулай берберсенә сүзсез генә сыенышып утыргач, егет уйланып дәвам итте: — Бу күк безнең аерылышуны сизәдер ул, Айсылу! Шуңа караңгыланып яңгырга тулышып торгандыр. Елыйсы киләдер аның да... Иртәгә соңга мин армиягә китәм... Уйлап кына кара, өч елга аерылышабыз. Ул минем өчен бер озын гомер кебек тоелачак инде.

— Минем өчен ун гомер кебек булачак. Әнием әйтә: «Аерылу газабы калган кешегә ун мәртәбә авыррак, киткән кешегә — бер генә процент», — ди.

— Юк, синсез миңа да ун мәртәбә авыррак булачак... Их, Айсылуым, сине ничек яратканымны белсәң, синсез ничек түзәрмен инде?

— Син түзәрсең ул, анда солдатлар күп, дуслар табарсың үзеңә. Мин монда нәрсә эшләрмен, сыерлар арасында сагыштан саргаеп бетәрмен инде...

— Һе, чагыштырдың, солдатлар күп, имеш. Солдатлар бит син булмыйсың...

— Булмаганын беләм лә ул... Шулай да аралашырга, сөйләшергә кешеләр бар инде, ә менә мин монда нәрсә эшләргә тиеш? Шул сыерлар белән, алар бит сөйләшә белмиләр. Син дөнья күрергә чыгып китәсең... Ә мин монда нәрсә күрәм?! Авылда яшьләр юк, клубы да ачылмый. Хет, ичмасам, аена бер генә ачылса да, ни булыр иде... Аена бер генә булса да кино китереп күрсәтсәләр дә җиңелрәк булыр иде, башкаларның тормышын күреп булса да юаныр идек...

— И Айсылу, туган җир туган җир инде ул, үз телеңдә рәхәтләнеп сөйләшеп була... Мин чит бер җирдә үз телемне дә ишетми яшәячәкмен. Син миңа хат язып торырсың, яме, ә мин сиңа көн дә язармын. Минс көтәргә сүз бирәсеңме, Айсылу? Мин кайткач та, өйләнешербез, Алла боерса...

— И юләрем син! Ул турыда сүз дә булырга тиеш түгел. Әлбәттә, көтәчәкмен, — дип Айсылу, егетнең куеныннан чыгып, торып утырды.

Сызылып таң беленә башлады, капка төбендә эскәмиядә бер-берсенә елышып утырган ике яшь йөрәкнең серләшеп сүзе бетмәде. Әллә ни турында сөйләшмәсәләр дә, бер-берсенә якын, тансык иде алар. Азатның китәсе, Айсылуның җибәрәсе килмәде. Бу аерылышу таңын аларның икесенең сузасы, тагын озаграк утырасы килде. Тик Азатка районга военкоматка барып килергә, ә Айсылуга эшкә китәргә вакыт җитеп килә иде...

— Мин хәзер кайтып, чәй генә эчеп, әз генә ятып торам да иртән-иртүк военкоматка сыпырам. Бүген әни «прощальный»га кунаклар җыя. Сине дә чакырам... Килерсең бит!

— Чакырсаң, киләм...

— Кич үзем килеп алырмын сине, яме. Бүген минем икетуган Риф абыем да кайта. Офицер ул! Әнинең бертуган апасы — Гөлсимә апаның улы. Алар гомер буе районүзәктә тордылар. Ул апасы әнидән күпкә олы, яшь чагында, әле әни туган гына булган, укырга дип киткән дә шунда кияүгә чыгып төпләнгән. Аның улы, Риф абый, әнидән чак кына кече. Риф абый егет чагында безгә элек еш кайтып йөргән. Аннан, чит-як җирләрдә хезмәт итә башлагач, бөтенләй кайтканы булмаган. Мин бик бәләкәй чакта гына килгән булган. Тик мин аны хәтерләмим. Дөресен әйткәндә, аны бер дә күргәнем юк. Барысы да мине аңа охшаган диләр. Ул килсә, минем карт чагымны күрәсең инде... — дип көлеп куйды Азат. Айсылу да аңа кушылып көлде. — Әле ул да отпускыга кайткан. Күпләрнең башын әйләндергән ул яшь чагында, шулай булса да, өйләнмәгән ул, бер гарнизоннан икенчесенә йөреп гомере үткән... Хәзер инде Мәскәүнең үзендә яши. Бүген военкоматка баргач, аларга керәм дә бергә кайтабыз...

— Мәскә-әү-дә?! Менә кемнәргә рәхәт! Безнең кебек, гомере буена берни дә күрми яшәмиләр...

— Менә, Алла бирсә, кайту белән өйләнешербез дә сине аларга кунакка алып барырмын. Мәскәүне карарбыз. Мавзолейны карарбыз... Ленинның үзен күрербез...

— О-о, шәп, чынлапмы? — дип Айсылу, хыялының тормышка ашасына алдан сөенеп, Азатны үзе кочаклап алды. — Мин ул Мәскәүгә барачак минутларны күз алдына китереп сине көтәрмен, яме...

— Ярый, сандугачым, синең дә эшкә барыр вакытың җитеп бара.

— И-и, бер дә хушлашасы килми бит, шундый рәхәт итеп сөйләшеп утыра идек...Ниләр эшләрмен

инде, син киткәч, сагынудан үлмәсәм инде... Ярый, хуш әлегә, кичкә каләр.

***

Кич белән егет озак көттермәде, кыз артыннан килеп тә җитте.

Азатлардан Айсылулар бик ерак тормыйлар иде, һәдигәнче барып та җиттеләр.

Айсылу, оялып, кермәскә дә иткән иде, шуны сизгән кебек, алъяпкычын бәйләгән, яңа матур күлмәген кигән Гөлсинә дә килеп чыкты.

— Менә, әни, булачак киленең оялып тора әле керергә, — диде Азат, әнисе каршы чыкканга сөенеп.

— Тыйнак кызлар шундый булырга тиеш тә ул, балам. Ярый, керегез, без алай бик күп кеше җыймадык, шул туганнар гына, балам. Районнан түткәй белән улы килде, ваянный ул, бик күптәннән кайтканы юк иде аның. Ярый, әйдәгез, керегез! — дип, Айсылуны аркасыннан сөя-сөя әйдәләп алып керде.

Өйгә кергәч, Айсылуның каушаудан хәле бетеп, аяк буыннары йомшарды, тыны кысылып киткән кебек булды. Ул өстәл артында утырганнарга күз генә сирпеп алды да, барысының да аларга төбәлгәнен күргәч, күзен күтәреп тә карарга оялып басып тора бирде.

— Әйдә, уз, балам, түргә, әнә, икегезгә икс урын, утырыгыз, — дип Гөлсинә, кызның тагын аркасыннан йомшак кына кагып, урынын күрсәтте.

Айсылу бигрәк тә Риф абыйсыннан оялды. Җитмәсә, урыннары да нәкъ аның каршысына туры килде. «Бу бик зур кешедер инде, кара нин-

ди киемнәре, хәрбиләрнеке, ә погоннары ялтырап торалар», — дип уйлады ул шундый зур дәрәҗәле кеше алдында утырганына кыенсынып.

Ул елларны авыл җирендә телевизорлар юк иде әле, киносын да елга бер мәртәбә дә генә китереп күрсәтәләр иде. Андый затларны Айсылуның кинода гына күргәне бар иде. Аның өчен иң бөек кеше Ленин иде. Аннан кала укытучылар... «Нинди чибәр абый! Әллә Азаттан да чибәррәк. Тик олырак кына...» — дип уйлады Айсылу.

Шул минутларда Рифнең дә мие аша нинди генә уйлар үтмәде. «Бу нинди хур кызы, зәңгәр зур күзләр, дулкынланып торган калын озын толымнар... айдай ап-ак йөз... Исеме дә бик матур, җисеменә туры килә... Чынлап та, бу кыз — Ай сылуы. Җирдән түгел, күктән төшкәндер...» Үзе Айсылудан күзен дә алмады, үзенең аңа бер күрүдән гашыйк булганын аңлады. Кыз аның һушын алды. Айсылу күзен күтәреп карыйм дисә, тагын шул күзләр белән очрашты. Моны башкалар да сизмәде түгел, әлбәттә. Азат та сизде. Моны күреп, йөрәге урыныннан купты, эче поша башлады, үз-үзенә урын тапмады. Айсылуны алып чыгып кына китәр иде, «Табынны ташлап китү әдәпсезлек булыр», — дип уйлады. Бигрәк тә энисен рәнҗетүдән курыкты. Аның юкны бар итеп, тырышып-тырышып әзерләгән табыныннан китсә, энисе алдында да, аны озатырга килгән кунаклар алдында да яхшы булмас иде. Шуңа да ул тешен кысып түзде. Азатның ни өчен йөзе үзгәреп, күңеле боегып киткәнне Рифнең энисе Гөлсимә дә сизеп алды һәм астан гына улына төртеп алды. Бераз шулай түзеп утыргач, Азат кинәт кенә басты да, барысыннан гафу үтенеп, Айсылуны җитәкләп ишеккә таба атлады.

— Барыгыз, балакайларым, соңгы кичегез, озакка аерыласыз, гөрләшеп калыгыз! — диде Рифнең әнисе дә, аларның чыгып киткәненә куанып, югыйсә, ике арада тавыш чыкмагае дип куркып утыра иде.

Риф абыйсының бу кыланмышы болай да аерылу сагышына чумган Азатның яшь йөрәгенә ук булып кадалды. Айсылуга әйтеп калдырасы сүзләр дә ничектер буталдылар. Ни генә әйтсә дә, урынсыз әйткән кебек тоелды. Үзенең күзләренә яшь тулды.

— Мине көтәрсеңме, бәгърем? Исән булсам... әйләнеп кайтырмын... Туй ясарбыз гөрләтеп... Бездән дә бәхетле пар булмас әле, менә күрерсең...

Айсылуга да бу хәл нык тәэсир иткән иде. Ул егеткә берничек тә җавап бирә алмады. Бердән, аерылу сагышы җанын өзгәләде, икенчедән, Рифнең әрсез карашы күңеленә тынгы бирмәде, бу хәлнең ахыры куркытты. Җавап урынына башындагы яулыгын чишеп алды да, йөзенә каплап, үксеп елап җибәрде. Азатка да авыр иде, Айсылуны кочагына алды да сүз табалмый тынып калды...

— Әйдә, Азат, мине озатып куй инде, төне дә бигрәк салкын, җиле үзәккә үтә, әзрәк йоклап та алырга кирәк, күзләргә йокы куна алса...

Егет кызны озата китте. Юл буена тын гына бардылар да, Айсылу бер сүз дә әйтми кереп китте, Азат авыр уйлар белән өенә юнәлде...

Әлбәттә, Айсылуны төне буе йокы алмады, ә Азат турында бөтенләй дә әйтеп торасы юк. Барысын да уйлап көяләнде: дөнья йөген тартып калган әнисен дә кызганды; Айсылуын да башкалардан көнләште; чит-ят җирләргә китеп, солдат итеген киеп йөрергә тиеш үзен дә уйлады. Үзеннән бигрәк, алар өчен борчылды. «Мин ир кеше, ни-

чек тә түзәрмен ул, менә алар нишләр? Көтәрме мине Айсылу? Өч ел бит бик озак вакыт...» — дип уйланды.

***

Алар иртә белән ат җигелгән арбаларга төялешеп район үзәгенә юл алдылар. Карлар эреп, арба юлы төшкән иде инде. Олылар бер арбага утырды, яшьләр — икенчесенә. Гөлсинә улын үзе кырына утыруын үтенсә дә, ул, әнисен ишетмәгәндәй, яшьләр кырынарак сыенды. Барысының да күңеле төшенке иде. Риф, сүз башлап, алар белән сөйләшергә, көлдерергә тырышса да, әңгәмә килеп чыкмады. Көлүче дә булмады. Айсылу Азатын уйлады, Азаты, билгеле, аның турында... Ә «мөхтәрәм» Риф абыйлары, тычкан аулаган песи кебек, Айсылудан күзен алмады.

Аерылу минутларының газапларын әйтеп кенә аңлатып була микән? Юктыр. Бу халәт котылгысыз һәм бик авыр иде. Гөлсинәгә, бердәнбер күз нурын — улын чит-ят җирләргә озатучы ана буларак, барысына караганда да авыррак иде. Алай да, сабыр булды, күз яшен улына күрсәтәсе килмәде. Кычкырып елыйсы килсә дә, тыелды. «Ярый, улым исән-сау әле, туган иле өчен хезмәт итәчәк, бу бит горурлык! Моның өчен кайгырырга түгел, сөенергә кирәк. Дүрт саны төгәл, тәне таза-сау булсын. Үзе нинди матур, торганы бер пәһлеван! Бик җитез, көчле! Армиядә дә сынатырлык түгел... Шундый ул үстергәнгә горурланмаслыкмыни! Исән генә булсын балакаем, сугышлар чыкмасын... Вакыт тиз үтә ул, түзәргә генә кирәк. Көткән чагында бер сәгате бер ел булып тоелса да,

кайтыр, Аллаһ боерса», — дип уйланып күңелен тынычландырды.

Азатны озатканда да тыелды, улы аның елаганын күрсә, кыен булыр дип уйлап, ничек кенә авыр булса да, күз яшен йотты. Тик Айсылу гына күз яшьләренә ирек бирде... Азатның күкрәгенә капланып, рәхәтләнеп елады, хәтта аның әнисеннән дә бу кылыгы өчен оялмады. Ә Риф бер сүз дә эндәшми аны читтән генә күзәтеп торды...

***

Җире әйләнеп кайтканда Риф, әрсезләнеп, елаудан шешенеп беткән Айсылу янына барып утырды. Төрле мәзәкләр сөйләп, аны көлдерергә тырышты. Тик кыз Риф сөйләгәнне башын иеп тыныч кына тыңлап утырды. Ә Гөлсимәнең, киресенчә, улының кыланмышына эче пошты. «Беткәнмени башка кызлар Азатның Айсылуыннан башка. Икетуган энесенең кызына карамаса... Бу бит бөтенләй ярамаган эш. Болай булса, сеңлем белән ара бозылуы көн кебек ачык бит. Күрде бит инде, Айсылуның ничек елап, вәгъдәләр биреп озатканын...» — дип алдагысын уйлап үрсәләнде ул..

Риф белән әнисе, район үзәгендәге үзләре яшәгән йорт янына җиткәч, арбадан төшеп калды, ә Айсылулар үз авылларына кайтып китте. Аларга әле җиде-сигез чакрым кайтасы бар иде. «Ямьле май җиткәч, китте... Озакламый бөтен дөнья чәчәккә күмеләчәк... Шушы вакытта аның белән шомырт исенә исереп, сандугачлар җырын тыңлыйсы килгән иде Айсылуның... Ә Азаты китте дә барды... Үзе белән бөтен хыялларын алып китте...

Бу күтәреп алган җәйләрне ничек ялгыз уздырырмын инде? Аңардан башка ничек ямь табармын инде?» — дип уйлап, юл буена беркемгә дә эндәшми кайтты. Бүген дә күк йөзен кара болыт каплаган иде. Күкне генә түгел, аның күңелен дә кара болыт каплагандай булды....

Айсылу кайтып кергәндә, әнисе өйдә чәй әзерләп йөри иде.

— И-и, менә кызым да кайтып җитте, — дип, өстәл әзерли башлады. Аннан өстәл артына утырып, сорашырга керешге: — Ну, ничек?

Айсылуның хәтта әнисе белән дә сөйләшәсе килми иде.

— Йә, кызым, тынычлан, һәс дигәнче үтеп китәр әле ул өч ел дигәнең. Кайтыр, исән булса, Алла боерса. Йә чәй эч тә ятып йоклап ал, күзләрең эчкә батып калды сагыштан. Мин эшкә барып кайтыйм, синең сыерларыңны да кызлар белән бүлешеп саварбыз... Мәхәббәт ул, балам, күпкырлы.Ияләшү бар, ярату бар... Син үзең дә белмисең әле, яратасыңмы аны әллә ияләшкәнсең генәме? Менә, еллар үткәч, аңларсың... Шуңа күрә артык өзгәләнмә! Син әле яшь, күп нәрсәне аңламыйсың...

Айсылуның әнисе Бану бар булмышы белән киң күңелле, күркәм холыклы һәм бик акыллы иде. Кырыкка җитсә дә, чибәрлеген югалтмаган, карап туймаслык. Кызы да, үзенә охшап, шулай чибәр булды... Бердәнберенең фермада эшләп, сыер савып йөргәненә дә бик эче поша иде. Кызын ерак җирләргә җибәреп укытасы, бәхетле тормышта яшәтәсе килде аның. Ә Азатка чыкса, аның авылда калып, гомере буе сыер савып йөриячәге көн кебек ачык иде. Кайчандыр үзенең дә кулыннан бәхет кошын шулай, яшьлеге белән аңламыйча,

очырып җибәргәнгә гомере буена үкенде. Белмәде шул ул чакта шулай килеп чыгасын, белмәде.

Бану Рифнең кайтуы турында ишеткән иде, әлбәттә. Кызының бик йончып кайтканын күргәч, ничектер аның хакында сорарга базнат итмәде. «Башта әзрәк ял итсен, аннан җайлап сорашырмын», — дип уйлады. Шунда ул яшьлеген сагынып куйды. Бар иде бит аның да җиләк кебек, егетләрнең һушын алырлык чаклары... Риф тә һушын югалтырлык булып аның артыннан йөрде. Тик ул вакытта кыз аны бөтенләй исәпкә дә алмады... Үзеннән ике яшькә кечерәк булганга, кимсетеп карады. «Син, энем, борыныңны сөрт башта, иреннәреңнән күкрәк сөте кипмәгән, кызлар артыннан чапкан буласың...» — дип көлгәнен әле булса хәтерли Бану. Ни дисәң дә, Риф әле мәктәптә генә укып йөри, ә Бану, җиденчене тәмамлап, фермага сыер саварга киткән иде. Риф Гөлсинә апасына җәйге каникулда кунакка килә. Шунда Бануны күреп алды да инде ул. Тик ул тиңсенмәгәнгә үзсүзле Рифнең бик ачуы килә, үләрдәй булып гарьләнә иде. «Тукта, армиягә барып кайтыйм әле, күрерсең мине!» — дип уйлады. Әмма ул армиядән тиз генә әйләнеп кайта алмады. Хәер, кайтасы да килми иде инде. Бердән, анда хезмәт итү ошаса, икенчедән, үз ягында әнисеннән башка өзелеп көтүче кызы да юк. Бануның да авылга эшкә килгән зоотехник егеткә кияүгә чыкканын белде хат аша. Шундый чибәр кыз кияүсез каламыни инде?! Риф, армиядә калып, хәрби училищега укырга керде. Аннан лейтенант дәрәҗәсенә житте. Шулай итеп анда әллә күпме еллар үтеп тә китте...

Кияүгә чыгып, бер ел үтүгә, Бануның Айсылуы туды. Тик озын-озак бәхетле гомер итәргә туры

килмәде аңа. Мәхәббәт дигәнең чамалы булгандыр, күрәсең, гаилә таралды, зоотехник үз ягына кайтып китте. Бану бер ялгызы гына кызын үстерде. Шунда аның Рифне кире кагып рәнҗеткәненә үкенгән чагы да күп булды. Тик Риф аның кызы тугаиын да, ирепнән аерылганын да белми иде... Бик озак еллар туган ягына бөтенләй кайта алмады.

Әйе, Риф Айсылуның Бану кызы икәнен дә белмәде. Ул кызны кемгәдер охшатты, бик якын һәм таныш кебек тоелды аңа күз карашлары... Тик кемгә охшаганын исенә генә төшерә алмады. Бу дөньяда бик күпне күргән, кызларны пирчәткәдән дә еш алыштырган Риф Бануның йөзен инде оныткан иде.

Шул ук төскә ул икенче тапкыр гашыйк булды. Кызны бер күрүдән бөтен аңы томаланды. Рифнең болай әле беркемгә дә гашыйк булганы юк иде шикелле. Нишләргә? Риф бит инде яшүсмер түгел, буе-яше җиткән ир кеше. Җитмәсә, якын туганының яратып йөргән кызы. Җитмәсә, армиядән кайтканын көтәргә вәгъдә бирде... Риф белә инде армия хәлен, үзе хәрби булгач... «Айсылуың кияүгә чыкты», — дигән хат алса, эш харап бит... Үз-үзенә кул салучылар да юк түгел. Йокларга яткач та башында төрле уйлар чуалды, түшәк өстендә әйләнде дә тулганды. Уйларын җыеп, йокларга тырышты, тик ничек кенә үзен тынычландырырга тырышса да, Айсылуның нурлы йөзе күз алдыннан китмәде. Күрше бүлмәдән әнисе эндәште, ул да уйланып, улы өчен кайгырып йөри иде.

— Нәрсә, улым, йоклый алмыйсыңмы? Белеп торам инде ни уйлавыңны. Син ул уйларыңны башыңнан чыгарып ташла, ул бит әле яшь кенә бала. Ул гына түгел, якын туганыңның яратып

йөргән кызы. Азат бит аңа кайту белән өйләнәм дип өметләнә. Аның өметен кисәсең бит, улым, кагылма инде, зинһар, ул кызга.

— Мин аны үзем дә аңлыйм, әни. Йөрәгем әллә нәрсә эшләде дә куйды. Азат яшь әле ул, әллә нинди кызлар табар үзенә, минем бит яшьлегем үтеп китте. Һаман ялгызмын...

Әнә шулай газапланды Риф. Газапланмаслык та түгел шул, кызы да нинди! «Шундый конфетканы иртеп барсам, андагы кыланчык офицер бичәләренең борыннарына чиртер идем. Теге бәйләнчек маржадан да котылыр идем, ичмасам», — дип уйлады. Бераз шулай боргаланып яткач, «Ни булса да булыр, барам», — дип уйлап торып, киенә башлады. Әнисенең ялваруына да карамый, күрше егетенә кереп китте. Әхәт ихатада йөри иде.

— Слушай, Әхәт, мине күрше авылга илтеп куй әле матаең белән, минем анда түткәй тора, — дип аңа эндәште.

— Нигә илтмәскә, әйдә, утыр, выжт илтеп куям. Әгәр теләсәң, матайны үзеңә дә биреп җибәрә алам, иртәгә кайчан кайтасың?

— Рәхмәт, күрше, юлым уңса, бүген үк тырышырмын...

Гөлсинә апасына бару юк иде аның уенда. Урамда үтеп баручы яшьләрдән Айсылуның кайда торганын белеп, ул торган йортка юнәлде. Килеп туктады. Мотоцикл тавышын ишетеп, Айсылу тәрәзәгә килде. Рифне күргәч, йөрәге табан астына төшеп киткәндәй булды. Ә Бану ихатада малтуарын караштырып йөри иде. Офицер киемендәге Рифне күргәч, ул авызын ачкан көе телсез калды. Әлбәттә, ул аны таныды. Риф тә, аны күргәч, Айсылуның анасы икәнне аңлап, аптырап кит-

те. Ләкин Бану үзен тиз генә кулга алды, барып күреште дә өйгә керергә тәкъдим итте. Эченнән генә сөенеп, «Минем белән күрешергә килгән, әле һаман онытмаган икән. Ни дисәң дә, беренче мәхәббәте идем бит мин аның. Ирем белән аерылышканымны ишеткәндер дә шуңа минем кырыма килгәндер. Кара, үзе нинди кешегә әйләнгән, формасы гына ни тора!» — дип уйлады. Бану тиз генә самовар куеп җибәреп, өстәлгә тәм-томнарын тезде. Иртә белән пешергән коймагы да бетмәгән иде әле. Бану Айсылуны да табын артына чакырды. Кыз кыенсынып кына килеп утырды. Риф Айсылудан күзен дә алмады. Әңгәмә дә коры гына барды. Искә алулар белән бергә хәзерге тормыш турында да сөйләштеләр. Риф үзенең әле дә ялгыз яшәве турында да әйтергә онытмады, әлбәттә. Ул күчтәнәчкә бер шешә шәраб та алып килгән иде. Һәм дә кәнфитләр... Үзе эчтән генә хәсрәтләнеп, Айсылу турында сүзне ничек башларга белмәде. Җас чыкканны көтте. Айсылу алдында ул бик ягымлы, бик тә әйбәт булырга тырышты. Озак утырдылар, инде төн уртасы җитеп килә иде. Ниһаять, Риф кулындагы сәгатенә карап алды да, нәрсә булса, шул булыр дип, тәвәккәллисе итте. Аның:

— Бану, мин сиңа бик зур йомыш белән килгән идем, әйдә, киен әле, икәүдән-икәү генә тышка чыгып сөйләшеп керик, — дип колагына пышылдавын ишетү белән Бану урыныннан җәһәт кенә торды да киенеп аның артыннан чыкты. Шул арада гына да үзенең башыннан йөз төрле уй үтте. «Бигрәк матур! Хәрби киемнәре ничек үзенә килешә! Буе-сыны һәм гәүдәсенә карап кына да башың югалтырлык... Тезелеп киткән тешләрен җемелдәтеп көлүләре генә дә ни тора!

Безнең авыл мужиклары түгел инде, ни әйтсәң дә, шәһәр кешесе, военный кеше, куллары да җылы, йомшак... Моңдый ирем булса, миннән дә бәхетле кеше булмас иде...»

— Әйдә, эчкәрәк утыр, монда үтәли җил. Язгы суык җилегеңә үтә күрмәсен, берүк, — дип, тиз генә күтәрмәгә җәймә җәеп, Рифкә утырыр урын әзерләде. Тегесе ничек сүз башларга белми аптырап басып тора бирде. Дөресрәге, югалып калды.

— Йә, — диде Бану үзен олырак икәнен белдереп, — миңа ни йомышларың бар иде, әйт. Һаман да әллә ничек, теге вакыттагы, җидәнчедә укыган малай сымак, оялып торасың...

— Бану, — диде Риф, тамагын кыра-кыра, — мин бит әле дә буйдакмын. Бер дә өйләнмәдем, — дип башлады сүзен.

— Китче әле, — диде Бану шатлыгын яшерергә дә уйламый, — чынлапмы? Уйламаган идем, — дип эчтән генә сөенеп: «Хәзер ул миңа тәкъдим ясаячак...» — дип нәтиҗә ясап куйды.

— Чынлап! Теләсәң, паспортымны күрсәтә алам. Чип-чиста.

— Юк, кирәкми, ышанам.

— Мин сиңа бер зур йомыш белән килдем, — дип Риф сүзен дәвам иткәндә, үзен тыныч тотарга теләп, карашын аска төшерде.

— Йә-йә, әйт, тыңлыйм, — диде Бану аны куәтләп.

— Мин кичәге озату кичәсендә синең кызыңны беренче тапкыр күрдем. Күрдем дә шундук йөрәгем әллә ни эшләде дә куйды. Әллә сиңа охшаганга, күземне дә ала алмадым. Моны әни белән Гөлсинә апа, гомумән, бар да сизделәр инде. Өстәвенә, әни тиргәшә. Әмма мин үз-үзем белән көрәшергә көч таба алмыйм. Ихтыярым белән

көчле кешемен дә, югыйсә. Бир син Айсылуны миңа кияүгә, мин аны рәхәттә генә яшәтермен. Акча бар, тормыш итәргә җитәрлек.

Шушы сүзләрне ишетермен дип көтмәгән иде Бану. Ул чак артына аумады, күз аллары караңгыланып, бер чокырга төшеп киткән кебек булды. Авызын ачып, каткан килеш күпме басып торгандыр... Бераздан гына үзен кулга алды.

— Бәй, — диде Бану, — ул бала синең туганыңның яратып йөргән кызы ласа. Нәрсә дияр соң Азат, Гөлсинә апаң? Алай иту килешерме соң?

— Аларны син миңа тапшыр, мин үзем аңлашырмын алар белән, тик Айсылу гына риза булсын, — дип тынычландырырга тырышты Риф. — Анда офицер хатыннары шундый чибәрләр, ну Айсылудан да чибәре булмас. Мин аны курчак кебек киендерәчәкмен, эшләтмәм, йокысы туйганчы йоклар, театр-концертларга йөретермен, — дип, төрле вәгъдәләр белән күмде. Һәрхәлдә ул моңа бик оста иде.

— Риф, — диде Бану, тыныч кына аны тыңлап беткәч, — бүген мин сиңа бер сүз дә әйтә алмыйм, уйларга кирәк, Айсылуның үзе белән сөйләшергә кирәк... Мин кызымның бәхетенә каршы килә алмыйм. Үзе ничек тели, шулай булыр...

— Ярый алайса, — диде Риф урыныннан кузгалып. — Иртәгә килермен... Сез сөйләшегез, уйлашыгыз кызың белән. Фермада сыерлар арасында пычракка батып-чумып йөргәнче, шәһәрдә аңа яхшырак булыр, дим.

Риф өйгә кереп тормыйча, ишек аркылы гына Айсылу белән саубуллашты да, мотоциклга атланып, өенә кайтып китте. Бану өйгә килеп кергәч тә, Айсылу аның төсе киткәнен күреп:

— Әнием, Риф абый безгә нәрсәгә килгән ул? — дип сорап куйды.

— Яныма утыр әле, кызым. Син бит минем берданберем, башка балам юк та, булмаячак та! Минем сине бик бәхетле итеп күрәсем килә. Сине бит сасы фермада тирескә батып йөрергә үстермәдем... Кызым, синең кебек чибәрләрнең урыны анда түгел, син бит бар булмышың белән тере артистсың. Ферма синең кебек кызлар өчен түгел ул. Минем авылда калып, тырмашып яшәвем бик житкән. Синең кулыңны сорарга килгән ул, кызым, сине ул бик ошаткан. «Үзем белән Мәскәүгә алып китәм, — ди, — ефәктән генә киендереп йөретермен, эшләтмәм», — ди.

— Әйтәм кичә күзен чәркәдәй итеп карап утыра иде. Мин аны сизгән идем инде. Сон, әни, мин бит Азатны яратам, мин бит аңа көтәргә сүз бирдем, ә ул: «Мин кайткач та, туй ясарбыз!» — диде.

— И балам, өч ел эчендә ниләр булмас?! Әнә Хәернисаның улы да йөргән кызына «Көт!» дигән иде армиягә киткәндә. Монысы өч ел буе көтте, тегесе аннан үзе белән бер маржаны ияртеп алып кайтмадымыни? Әле ярый, Мөслимәсе нык булды, тәки маржага торырга ирек бирмәде. Нишләсен тегесе, шул хәлләргә түзмичә, кайтып китте үз ягына... Син бит, үземә охшап, юашсың, шулай булса, ни эшләрсең? Тормышта ул гел көрәшеп яшәргә туры килә...

— Юк, минем Азатым андый түгел, ул ихлас кеше, алай итмәячәк.

— И балам, ышанма син ирләргә! Ул бит, кайтса да, бер колхозчы гына була инде, авылдан беркая да китмәячәк. Риф бит офицер, бер култыклашып урамнан үтүләре ни тора! Әле дә күршеләрнең күзләре дурт булгандыр. Синең аңа барганыңны

ишетсәләр, көнләшеп нишләргә белмәсләр әле. Күрше кызы Галиягә килсә, ябышып чыгар иде, билләһи!

— Соң, әни, миңа бит әле унҗиде яшь ярым гына. Галиягә утыз. Кая ашыгырга?

— Шуның өчен тәүдә никах кына укытырбыз. Унсигезең тулгач, ЗАГСка барырсыз, шундый кеше синс алдап утырмас бит инде.

— Соң, әни, мин Азатны яратам бит.

— Моны да яратырсың, алар бит икетуган, төскә дә охшашлар. Барасың гына, ике дә уйлап торма, оныкларым туса, мине дә үз кырыгызга алырсыз... Мәскәүдә торырбыз рәхәтләнеп. Минем дә кешечә яшисем килә...

— Ха, алды, ди. Кем әбисе белән бергә тора? Сине түгел, үз әнисен дә күрергә унбиш елга бер кайткан кеше... Син дә этигә баргансың да, зоотехник диеп, барыбер тора алмагансың, белем тигезсезлеге нәтиҗәсе. Минем дә җиде класс кына белемем. Ә ул офицер. Кимсетмәсме мине?

— Кимсетмәс, Риф андыйлардан түгел, май чүлмәге тышыннан билгеле, диләр, балам. Нинди шәһәрдә тора бит әле ул, башкалада — Мәскәүнең үзендә. Кем әле шулай Мәскәүдән авылга килеп тәкъдим ясар? Кемгә тия әле андый бәхет?! Әллә нинди мәхәббәт тә тиз сүнә ул менә бу баткакта...

— Шул Мәскәү кызыктыра да инде, — диде Айсылу, әзрәк уйланып утыргач... Бу аның әнисе белән күпмедер дәрәҗәдә ризалашуы иде.

— Йә, кызым, әйдә, йоклыйк, фермага баргач, бер кешегә дә берни дә сөйләмәм, аң бул, син дә бер сүз дә ычкындырма. Кайберләре, сүз урлап, юри сөйләндерергә тырыша...

Иртән эшкә барса, бөтенесенең күзе Айсылуда иде. Барысы да бу хәбәрнең дөресме, юкмы

икәнен белер өчен, аны күзәтәләр иде. Авыл радиосы бик шәп эшли шул. Ярты төн уртасында бер хәл була калса, иртәнгә бар да белә. Хәзер үк, яшен тизлегендә тарала иде. Тик Айсылу да, әнисе дә ни уйлаганнарын сиздермәскә тырыштылар. Үзләре әйтмәгәч, сорашучы да булмады.

Кич, эштән кайткач, утырып аш ашадылар. Тик бу турыда сүз кузгалтмадылар. Кояш баеп, эңгер-меңгер вакыты җиткәч, мотоцикл килеп туктаганы ишетелде. Май кояшы кебек елмаеп, Риф килеп керде.

«Ну матур да соң бу Риф абый, теләмәсәң дә, күзең төшәр», — дип уйлап куйды Айсылу, аны күргәч. Рифнең бүген күңеле бик күтәренке иде, чөнки соравын кичә кире какмадылар, ризалык белдермәсәләр дә.

— Ничек кәефегез? — диде ул ишектән килеп кергәндә үк.

— Кәефләр яхшы, әйдүк, түрдән уз, — диде Бану, — бергәләп, әйдә, чәй эчик, — дип өстәл артына чакырып урындыкка күрсәтте. Риф Айсылуга карый-карый өстәл артына барып утырды. Аның ни уйлаганын йөзеннән укыйсы килде.

— Айсылу, хәлләр ничек?

— Болай ярыйсы, Риф абый.

— Ярар.

Тагын сүзне нәрсәдән башларга да белми бераз башын аска иеп уйланып торгач, сүз башлап җибәрде.

— Минем ни... кичәге йомыш белән йөрүем инде, нәрсә уйладыгыз соң, нинди карарга килдегез? — диде Риф.

— Мин ике куллап риза инде... Менә Айсылу ни дип әйтер, — дигән булды кызының дәрәҗәсен төшермәскә тырышып Бану.

Кыз кыенсынып башын иде, үзе оялудан кып-кызыл булды.

— Нигәдер Айсылу бер сүз дә дәшми бит әле, — диде Риф, кызның кыенсынып торуыннан «риза» булуын чамалап.

— Мин нәрсә әйтсәм, ул шуңа күнәр, дип ышанам, без аның белән бик озак сөйләштек инде бу турыда, әйеме, кызым, — дип Бану кызына елмаеп карап алды. Тик Айсылу анасының елмайганын күрмәде, башын игән килеш утыра бирде. Ул ике арада калган иде. Бер якта «Көт мине» дип киткән Азаты, икенче якта Мәскәүнең үзендә торучы офицер. Әйе, алар бер-берсенә нык охшашканнар, әгәр бер яшьтә булсалар, игезәк кебек булырлар иде. Тик алар арасында аерма зур иде. Берсе яшь, әле берни күрмәгән, икенчесе — олы, дөнья күргән, бу тормышның ачысын-төчесен татыган... Кайсын сайларга соң?

— Минем отпускым азагына якынлашып бара, мәсьәләне ашыктырырга иде, — дип, кызның икеләнеп утырганын сизгәндәй, Риф өстәп куйды. Кызының бер якка да була алмаганын төшенгән Бану дилбегәне үзенең кулына алды:

— Ярар, озын-озакка сузмабыз, алай булгач, никах укытырбыз инде бер дүрт көннән, чөнки әзрәк әзерләнергә кирәк бит инде. Әйберләр алыштырырга кирәк, хәзер замана авыр, алып куйган әйберләр юк. Шуңа ике сарык суйдырырмын, дим, кешесенә күрә сые да булыр. Кодагый да килер, Аллаһы боерса.

— Ул да башта риза түгел иде дә, нәрсә эшләсен, күндердем. Мин аның яраткан улы бит инде, каршы тора алмады.

— Гөлсинә апаң нәрсә дияр инде? — дип Бану авызын яулыгының очы белән каплады.

— Нәрсә диясе билгеле инде. Ярар, вакыт — дәва, диләр бит, бар да җайланыр. Азат яшь әле, ул да язмышын табар, — дип, елт итеп Айсылуга карап алып, Бануны тынычландырырга тырышты. — Ярар, хәзер соң инде. Мин кайтыйм... — дип урыныннан торып басты Риф. — Без дә әзерләнә башларбыз. Димәк, дүрт көннән никах табынында очрашырга сөйләштек...

— Әйе, әйе, шулай сөйләштек, — дип, Бану Рифне озатып чыкмакчы булган иде, ул ишек төбенә җиткәч, артына борылып карап:

— Айсылу, озата чыгарсың, бәлки, — дип һаман башын иеп олылар сөйләшкәнне тыныч кына тыңлап утырган кызга эндәште. — Бар, балам, бар. Чыгып озатып кер! — диде Бану иркә тавыш белән.

***

Дүрт көн тиз генә үтеп тә китте. Никах укырга мулла абзый белән абыстаены, тагын бер өч-дүрт якын дусларын чакырды Бану. Риф әнисе белән килде. Гөлсинә апаларын да чакырганнар иде, ул килмәде. Хәер, аны килер дип үзләре дә көтмәгән иде. Ничек итеп ул газиз улын сатсын, ди. Аның эче тулы нәфрәт булгандыр. Икенче көнне Айсылуны алып та киттеләр. Тагын ике көннән алар Мәскәүгә очтылар. Юк, канатланып бармады Айсылу Мәскәүгә. Нигәдер бик эче пошты. Рифнең фатиры да коммуналкадан бер бәләкәй генә бүлмә булып чыкты... Бөтен нәрсә бергә уртак иде: кухнясы да, бәдрәфе дә, юыну урыны да... Нишләсәң дә, энә күзеннән үткәргәндәй бар да карап тора. Баштарак Айсылу барысыннан оялыбрак йөрде, бүлмәсендә генә уты-

рырга тырышты. Күршеләре барысы да руслар булгач, алар белән рәхәтләнеп сөйләшә дә белми иде. Шуңа да очраган һәрберсе белән итагатьле генә исәнләшеп узудан башка сүз әйтә алмады. Шулай булуына карамастан, Айсылуны ошатулары карашларыннан ук сизелеп тора иде.

Бер атна вакыт үтеп тә китте. Шулай бер кичне тышкы ишекне шакыдылар. Айсылу барып ишекне ачуга баласын ияртеп бер марҗа килеп керде дә, исәнләшеп тә тормый, хуҗаларча Риф торган бүлмәгә туп-туры атлап китте. Бүлмә ишеге ачык иде. Бала барып «папа» дип Рифне кочаклап алды. Ә бу хатын аңа акыра башлады. Айсылу русча юньләп белмәгәч, нәрсә әйткәнен аңлап та бетермәде. Хәер, болай да билгеле иде кем икәне бу балалы хатынның. Ул кычкырды-кычкырды да, улын җитәкләп, тагын шап-шап атлап чыгып китте...

Айсылу нәрсә эшләргә белми катып калды. Аның аяк астында җире убылгандай булды. «Менә сиңа өйләнмәгән егет! Менә хәрби форма һәм алтын погоннар... Ничек оста итеп ул Айсылуны да, әнисен дә алдаган. Ә алар ышандылар. Аңа ышанып, Айсылу үзенең мәхәббәтенә дә хыянәт итте... Нишләдем мин? Ялгыштым бит... Алдандым. Хур булдым. Бу хурлыкка ничек түзәргә? Авылда бу хәлне ишетсәләр, нәрсә уйларлар? Ничек урамнан узармын? Оятыннан җир астына керергә генә кала», — дип уйлап, Айсылуның кайнар күз яшьләре атылып чыкты.

Мендәргә капланып озак елады ул. Озак тынычлана алмады. Ә Риф аны төрлечә юатырга тырышты: «Ул бит минем хатыным түгел, мин аңа алам дип вәгъдә бирмәдем. Баланы ул: «Үземә кирәккә таптым, алиментка бирмәм», — диде, ә хә-

зер мине эзәрлекләп йөри. Ничек котылырга да белмим. Мин бит сине генә яратам, миңа синнән башка беркем дә кирәк түгел...» — дип борчагын сипте.

Айсылу ни әйтергә, ни эшләргә белми иде. Күршеләре дә бу хәлне күреп аптырадылар, нинди киңәш бирергә дә белмәделәр. Шулай беркөнне, Риф эшкә киткәч, күрше бүлмәдә яшәүче бер хатын чыгып китте дә икенче бер хатынны ияртеп алып килде. Ул Галия исемле татар хатыны булып чыкты. Аның да ире хәрби кеше, офицер икән. Айсылуның кайсы яктан булуы һәм кем икәнлеге турында сораштырды. Әлбәттә, ул да кеше язмышы белән шаярган Рифне тиргәде. Айсылуга, мондагы хәлнең шаһиты буларак, барысын да сөйләп аңлатып бирде: «Ул марҗаның исеме Ирина. Бик яхшы хатын. Риф өчен җанын бирергә әзер ул, бик ярата. Аның белән Риф гражданлык никахында да тордылар. ЗАГСка кермәделәр. Шул отпускыга кайтып китәр алдыннан гына ташлаштылар. Балага алты яшь. Рифкә бик охшаган. Сине дә алдаган, баланы да ятим итте. Хәтта хәзер алимент та түләргә җыенмый...» — дип барысын да ачып салды. Шулай бераз сөйләшеп утыргач, бу ханым хушлашып чыгып китте.

Бу хәлдән соң Айсылуның Рифтән бөтенләй күңеле сүрелде. Йөзе суырылып, боегып калды. Әй үкенде дә соң, ялгышканын аңлап, тик вакыт үткән, хатаны төзәтерлек түгел иде. Артка да юл юк. Инде Азатын да уйлый алмады. Үзенең хыянәтен үзе гафу итәлмәде. Яратып та бармаган иде бит, әнисе сүзенә карап кына барган иде, менә ничек килеп чыкты. Нишләп ризалашты соң? Аның дәрәҗәсенә, байлыгына кызыктымыни соң?.. Үзе гаепле барсына да. Мәхәббәт —

күлмәк кенә түгел шул, теләсәң, киеп, ошамаса, салып ташлап булмый... Риф кенә, бернәрсә дә булмагандай, ата песи сымак ешынып, ялагайланып йөри бирде.

Бер ай чамасы шулай яшәгәч, Айсылу үзенең авырга калганын аңлады. Бу хакта иренә белгертмәскә булды. Инде нишләргә дә белмәде. Кире кайтып та китәлми, бирелә дә калырлык түгел иде хәле. Рифкә булган нәфрәте артканнан-арта гына барды. Ире кочаклап иркәли башласа да, йөзен читкә бора иде. Шулай булгач, Рифнең дә аңа булган мәхәббәте суына башлады. Ә беркөнне ул бөтенләй кунарга да кайтмады. Элекке гаиләсенә китте ул. Риф малаен да бик ярата иде, ни әйтсәң дә, аның баласы бит. Иринасы да аның өчен өзелеп тора, ни ашатырга, кайда утыртырга белми... Риф тә Айсылуга өйләнгәненә ныклап үкенә башлады. «Ялгыштым бугай, сукыр мәхәббәт булды бугай Айсылу. Авылга унбиш ел кайтмаган идем бит... Ник кайттым, ник очрадым шуны?» — дип үзенең җанын үзе телгәләде.

Айсылу үзенең кичерешләрен Галия апасына гына сөйли алды:

— Инде нишләргә миңа? Балам да туса, кая барырга? Авылга кайтып ничек кеше күзенә күреним?! Риф юньләп өйгә кайтып та кергәне юк, мин аңлыйм, әлбәттә, балага әти кирәк, бала бит гаепле түгел. Минеке әле тумаган да... — дип эченә җыелганнарны сөйләп бирде.

— Юк, син авылга кайтырга уйлама да, әле корсагың беленми. Син эшкә кер берәр җиргә.

— Эшкә керергә минем бит пропискам юк.

— Ярар, мин иремә әйтермен дә, ул сөйләшеп сине пропискага да, эшкә дә кертер. Аның танышлары күп монда, — дип Айсылуны юатты.

Хәрби частька кер юучы булып урнашкач, Айсылуның эченә бераз җылылык керде, күз яшьләре кибә башлады. Авылда эшләп үскән бала булганга, ул эш тәртибен яхшы белә иде, шуңа да вазифасын җиренә җиткереп башкарды. Үзенең акчасы була башлады. Рифкә дә ул битараф иде. Кайтса да һушы китмәде, кайтмаса да, аптырамады. Аңа барыбер иде.

Ул, язмышына үч итеп, үзен сакларга, карап-бизәнеп йөрергә тырышты. Киемнәрдә барып сатып алды. Кемдер аңа гашыйк булырына өметләнмәсә дә, бик матур, килешле киенеп йөрде. Шушындый да гүзәл кызны күреп, кем генә гашыйк булмасын?! Солдатлар да аны тирәли башлады. Беркөнне бер татар егете сүз кушты.

— Син кайсы яктан? — дип сорады ул Айсылудан.

— Башкортстаннан, — диде Айсылу.

— Бәй, мин дә шуннан бит... — диде солдат, якташын очратканына ихлас сөенеп.

Шушы көннән башлап алар сөйләшеп йөри башладылар. Егетнең исеме Салават булып чыкты. Озын буйлы, кара чәчле, коңгырт зур күзле бу егет тора-бара Айсылуга ошый башлады. Ничектер күңелен җәлеп итте дә куйды. Аны уйламаска теләсә дә, күз алдыннан китми иде. Айсылу бу хәлгә үзе дә аптырады. Ул кайчандыр Азатын яратам дип уйлый иде. Ә Салават белән аралаша башлагач, мәхәббәтнең һич көтелмәгән башка ягын ачты. Бу хисне ул үзе дә аңлата алмады. Нишләсә дә, егет күз алдыннан китмәде. «Минем бит балам туачак, мин аңа кирәкмим...» — дип уйламаска тырышса да, йөрәге тыңламады. Шуңда ул әнисенең сүзләрен искә төшерде. «Әйе, мәхәббәт чынлап та күпкырлы икән», — дип уйлана башлады. Азатны яратмага-

нын, аңаияләшкәнгә генә яраткан кебек тоелганын аңлады. Ә Салаватка булган бу хис бөтенләй башкача, башны әйләндерерлек иде. Араларында берни булмаса да, Айсылу тора-бара Салаваттан башка тора алмаганын аңлады. Тик нишләргә дә белмәде. «Йөрәк турысында тибешә башлаган сабые башкадан бит... Аңа ничек әйтергә?» — дип уйланып йөрде.

Ә Салават боларның чуалчык тормышлары турында ишеткәнгә, Айсылу белән якыннапрак танышмакчы булып күптән йөри иде. Чөнки ул да Айсылуны бер күрүдән яраткан иде.

Риф өйгә бөтенләй кайтып керми башлады. Калган киемнәрен генә Айсылу өйдә юк чакта алып чыгып китә дә аннан соң бөтенләй кайтмый. Хәтта Айсылуның аңардан баласы туарга тиеш икәнен дә белми иде.

Шулай беркөнне тагын Салават очрады Айсылуга.

— Айсылу, — диде ул бераз кыенсынып, — тиздән без өйгә кайтып китәбез, мин сине шундый ошаттым, ирең белән барыбер тормышың юк, әйдә минем белән, мин сине кимсетмәм, тырнак белән дә чиртмәм...

Айсылу бу сүзләрне ишеткәч, аптырап калды. Аның Салаватның да тәкъдимен кире кагасы килми, туачак баласы хакында да әйтергә курка иде. Әзрәк уйланып сүзсез торгач, ул:

— Ә син беләсеңме, минем бит бәбием булачак, сиңа кеше баласы нигә кирәк? — диде. Ничек булса да, тормыш юлын алдаудан башламас иде ул.

— И-и... бала шатлык кына бит ул, сиңа да охшап туса, мин әниләргә дә, туганнарга да минеке дип әйтермен. Дөресен әйткәндә, мин барысын да беләм, барысын да сизәм. Синең һәр күзәнәгеңне мин йөрәгем белән тоям... — диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Айсылуның башы әйләнеп китте. Чынлап та, ул аңа мөкиббән китеп гашыйк булган иде. Салаватның тәкъдименә тиз генә җавап бирмәсә дә, күңеле белән әкренләп юлга җыена башлады.

Эшләгәч һәм кешеләр белән дә аралаша башлагач, Айсылу җиргә нык басып йөри иде инде. Карап торуга бераз көрәеп, матурланыбрак та киткән кебек. Русчаны да ярыйсы супалый башлады.

Салават белән көн дә очрашып, сөйләшеп йөрделәр. Кайтып китәр көне якынлашкач, ул янә бер мәртәбә тәкъдим ясады. Айсылу риза булды да куйды. Ә нигә ризалашмаска? Баласы белән дә алырга ризалашкан кешенең ихлас икәнен ул да бөтен йөрәге белән тоя иде. Икенче көнне алар вокзалда очрашырга сөйләштеләр. Ул өйгә кайтып әйберләрен җыярга керешә. Хәер, әйбере күп тә түгел иде.

Иртән, юлга җыенып, иренә хат язып, чыгып китәргә җыенып утырганда, малаен җитәкләп Риф кайтып керде. Аның хатынын машина бәреп киткәне, ә малайның әнисез калганы билгеле булды.

— Синең күз яшьләрең төшкәндер инде. Мине, зинһар, кичер, — дип ул инде корсагы беленә башлаган Айсылуның алдына килеп тезләнде. — Зинһар, кичер мине, туачак балабыз хакына, — дип ялынды.

— Мин аңа үлем теләмәдем. Син гаепле моңа, ул түгел, — диде Айсылу.

— Хәзер инде берәү дә тормый безнең арада, тик менә малай минеке, ул минем белән булачак, — диде Риф Айсылуның аны кызгануына, гафу итүенә өметләнеп.

— Монда баланың бер гаебе һәм зыяны да юк, әмма мин сиңа тәмам суындым, күрәсем килми!

Мин бүген кире кайтып китәм. Ялынма, мин монда бүтән кала алмыйм, — диде Айсылу үзен суык тотып.

— Ә баланы ятим итмәкчесеңме?

— Мин ятим итмәм, аның атасы бар. Менә син үзеңнең улыңны ятим итмә, — дип, әйберен алып чыгып китте. Риф, ишек яңагына тотынып, уйланып торып калды...

Вокзалда аны Салаваты сөйләшкән урында көтеп тора иде... Менә поезд да килеп туктады. Алар үзләренең урыннарына кереп утырдылар. Вагон тәгәрмәчләре туган Башкортстан ягына тәгәрәде дә тәгәрәде. Бәхетле иде Айсылу да, Салават та.

Әйе, һәркемнең бәхете — үзенең кулында. Бу күпкырлы тормышта чын мәхәббәтне таный белү дә, вакытында таба белү дә — бәхет ул.

СОҢГЫ БҮЛӘК

Җитмешенче елларда булды бу хәл. Көзге салкыннар җитү белән бик каты авырый башладым. Туктаусыз температурам күтәрелә, хәлем юк. Киттем табибка. Ул тыңлап карады да: «Сездә үпкә ялкынуы», — дип, дарулар, уколлар алырга рецепт язып бирде. Билгеле инде, больничныйга чыгарды.

Ул чорны һәрбер эшче кулы алтын бәрабәренә тора иде. Савыгып беттеңме, юкмы, озак тотмыйлар, унсигез көн үтү белән больничныйны ябалар. Унсигез көн үтеп тә китте. Алган укол, даруларның бер файдасы да булмады.

Берничә тапкыр больничныйда ауныарга туры килде. Шулай йөри торгач, кояшлы яз да җитте. Алмагачлар да чәчәк атты. Тик минем хәлем генә

җиңеләймәде. Янә поликлиникага бардым, табибәм миңа туберкулез диспансерына юллама бирде.

Бер дә кояш төшмәгән караңгы палатага салдылар минс. Күңелемә дә әллә ничек кыен, авыр. Сөйләп кенә аңлатырлык та түгел. Кердем дә урыныма аудым... Монда керсәң, тиз генә чыгып китеп булмый икән. Айлар, еллар буе яталар. Миңа да озак кына ятарга туры килде. Тиз генә дигән операцияләрс өч айга сузылды. Тора-бара палатадагылар белән танышып-дуслашып беттек, Тая исемле рус кызы белән таныштым. Тышка чыгып йөрибез, якында гына урман, яшеллек. Сентябрь ас булса да, көннәр җылы торды. Башкалар да чыгып утыра иде. Аралашабыз, сөйләшәбез. Хәлләребезне сорашабыз. Сүз бит тиз тарала, кемнең кем икәнен белә башладык. Бер төскә матур гына, уртача буйлы бер иркәй дә гел чыгып йөри иде. Үзе матур булса да, кеше белән бик аралашып бармый. Астан гына карап, исәнләшеп кенә узып китә дә читкәрәк барып уйланып утыра торган гадәтле иде. Үзе аралашмагач, башкалар да аңа йокмый. Тая, ничектер, аның белән уртак тел табып, бергә аралашып йөри башлады. Юк, Тая, әлбәттә, аның белән дус кына иде. Ул аның белән сөйләшеп йөргәнне күргәч, башкалар: «Күп еллар төрмәдә утырган бит ул, син артык ышанып барма аңа», — дип Таяны кисәтеп куйдылар. Тик ул кеше сүзенә игътибар итмәде. Аралашуын дәвам итте. Туганнары берәр тәмлерәк ризык китерсә, аңа да илтеп бирә иде. Мин, гомумән, бур, ялганчы кешене сөймәдем. Шуңа да Таяның аның янында йөрүе эчемне пошырды:

— Нинди уртак эшең бар аның белән? Нишләп үзеңне хурлыкка калдырып шул зэк белән йөрисең? Ул бит бандит! — дим.

— Мин аны бик тә җәллим, — ди Тая, күзләре яшьләнеп.

— Тапкансың җәлләр кеше, — дим үзсүзләнеп.

— Туктале, кызма. Ул да бит кеше. Бандит түгел, Рәфит аның исеме. Төрмәдә утырган дигәч тә. Аның да бит яшисе, бәхетле буласы килгәндер...

— Булсын иде бәхетле. Ник булмаган соң? Юньле булса, төрмәгә эләкмәс иде...

— Эләгә шул, яклар кешесе булмаса... Әтиәнисе үлгәннәр күптән, ул ятим үскән. Бик иртә читкә чыгып киткән, бик интегеп яшәгән. Аннан начар компаниягә эләгеп, ялгыш юлга баскан.

— Кеше талап йөргәннәр инде...

— Юк, алар кеше таламаганнар, магазиннарга төшкәннәр. Шулай беркөнне алтын магазинына кергәннәр... — дип, Тая аның хәлен сөйләп бирде.

«Минем үз гомеремә җитәр иде ул алтын», — диеп сөйләгән Таяга. Бик эзләп карасалар да, тота алмаган милиция боларны. Бераз тынычлангач, бу бик чибәр Оля исемле кыз белән танышкан. Яшәп киткәннәр. Күпмедер вакыттан тегене-моны туктаусыз алдырырга яраткан. Бу көйсез хатынны ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булган. Оля, бу хурлыкка чыдый алмый, милициягә әйтеп тоттырган боларны. Суд егерме елга иркеннән мәхрүм иткән. (Әйтергә генә җиңел!) Шуннан туберкулез эләктергән. Аның хәле безнеке кебек кенә түгел, бик авыр иде. Мин үзем дә табигатем белән кеше җәлләүче булганга, аны бик кызгана башладым. Бөтен бәла, бәхетсезлеге ятимлегеннән килә иде аның. Шуңа да кызгандым...Таяны да бүтән бер дә тыймадым.

Операцияне Тая белән икебезгә бер көнне, бер сәгатьтә ясадылар. Бераз яткач, дүрт айга санаториягә җибәрделәр. Санаториягә барып кына

бу диспансердан котылам димә. Кайткач, тагын киттем шунда. Теге Рәфит әле һаман анда ята иде.

Барсам, моңа операция ясаганнар. Хәле бөтенләй начарланган. Әзрәк күчтәнәч тә алып барган идем. Ул шундый мескен хәлендә иде. Өстәвенә җөе дә төзәлмәгән. «Аркасының җөе аша үпкәсе күренеп тора, хәле бик авыр...» — диде шәфкать туташы миңа, аның белән аралашканымны белгәнгә, сер итеп кенә.

Ул елларны көчле дарулар юк иде шул. Сатып алып китереп тә бирер идем. Артык тәрбияләмиләр дә иде ул вакытта андыйларны. Беркемгә дә кирәкми иде ул. Бертуган апалары да, күпме ятып, бары бер генә мәртәбә килгәннәр. Алар инде читләшеп тә беткәннәр иде аннан. Мин, бик кызганып, сирәк булса да күчтәнәчләр илтеп кайта идем. Аның сөенүе шуңа! Сабый бала кебек шатланып елмая иде. Үзенең бер тиен дә акчасы юк. Дәваханә ризыгы белән генә туклана. Аның язмышы язылып куелган иде инде. Шулай бер барсам, бик боек күренде бу миңа.

— Нәрсә булды, Рәфит? — дим.

— Кәрт уйнап, бераз акча откан идем дә, шуны урладылар, — ди. Анда бик күп иде төрмәдә утырып чыкканнар. Шулар урлагандыр инде...

— Ярар инде, бик кайгырма, болай да нык чирлисең, — дим аны тынычландырып.

Тагын бер баруымда, март ае иде, бу миңа «Белая сирень» дигән хушбуй суза. «Рәхмәт изгелегең өчен», — ди. Тагын икс тәңкә акча уйнаган булган кәрткә. Шуңа миңа хушбуй алып рәхмәтен белдерергә тырышкан, күрәсең. Яшәргә күп калмаганын ул үзе дә сизә иде инде. Инде ятып кына тора иде. Моңсу гына карап минем белән сөйләште. Күземә яшь тыгылып кайтып киттем.

Бер унбиш көн чамасы үткәч тагын барсам, «Ул үлде инде, туганнары килеп алып киттеләр. Туган авылында җирләделәр аны», — диделәр. Бу сүзләрне бер ишетеремне белсәм дә, бик авыр булды. Аның гомеренең аянычлы үткәнен уйлап бер кайгырсам, газиз гәүдәсе, сөякләре үзенең туган җирендә, туган зиратында ятачак дип уйлап, тынычландым. Бердәнбер бәхете аның шул булгандыр...

Аны гомерем буена онытмадым. Исемә төшкән саен йөрәгем сулкылдап әрнеп куя. Кеше гомере бит бер генә тапкыр бирелә... Ул биргән «Белая сирень» хушбуе бер генә дә ачылмаган килеш, инде менә ничә еллар буе сервантта урын алып тора. Аның соңгы бүләге.

ҖУЕЛМАС ЯРА

Күтәренке кәеф белән уянды бүген Гөлсем апа. Шулай булмый ни, өченче көн пенсиясен китерделәр, кичә шул акчага бер капчык он, бераз шикәр комы сатып алып шатланды. Ичмасам, аерым дөнья көткән балаларына таба тутырып бәлеш пешереп илтер. Бәйрәм ич бүген. Хатын-кызлар бәйрәме. Көне дә бит, гүя алдан сөйләшеп куйганнармыни, балкып тора. Таң алдыннан торып манный белән иләп куйган камыры да гөпердәп кабарган.

Байтак еллар инде Гөлсем апа берүзе генә яши. Пәһлевандай ире йөрәге тотып яшьләй генә үлеп китте. Биш баласы да үз оясын корып, балалар үстерә, шөкер. Болай бик еракка китеп бәгырьне телмәделәр, үз районнарында яшиләр. Менә дигән итеп дөнья көтәләр. Оныкларга да бик бай Гөлсем апа. Шулар белән юанып, шуларны сөеп, иркәләп

яши инде, кая барсын. Ялгыз яшәгәч, мал-туар асрап мәшәкатьләнмәскә булды. Аннары печәнен, саламын фуражын хәстәрләргә көче дә, хәле дә җитми иде инде. Дистәдән артык тавык белән аталы-инәле каз гына асрый Гөлсем апа.

«Кая әле, бәбкәйләремне мич ялкынында пешкән белен белән сыйлыймчы бүген. Газда пешкән ризыкның ни тәме, ни бәрәкәте. Хәер, көне-төне эштә йөргән кешенең камыр ашы белән булышырлык вакыты каламы аның...» Алмаш-тилмәш таба белән тиз генә пешереп тә алды Гөлсем апа бер өем тәбикмәкне.

Тәүдә ул олы киленен котларга булды. Беленнәрем суынмасын, эссе килеш ашасыннар дип, калын сөлгегә төреп, сумкасына салды. Иртәнге чәйне юньле ризык белән эчсеннәр дип, бәйрәмнәрдә генә кия торган матур-матур киемнәрен киеп, кабаланып чыгып китте.

— Хәерле иртә, бәбкәйләрем, бәйрәмнәр белән үзегезне! Кайсыгыз кая таралышканчы дип, кабалана-кабалана килдем. Белен пешереп китердем үзегезгә бәйрәм белән котлап, — дип елмаеп, сөйләнә-сөйләнә килеп керде ул өлкән улының йортына.

Ул кергәндә, улы чәй әзерләп, үзе генә чәй эчәргә җыена иде бугай.

— Бәй-бәй, әллә килен өйдә юк инде, иртән-иртүк кая китте? — дип сорамый түзә алмады апа.

— Ул, әни, үзенең әнисен — әбине — тиз генә бәйрәм белән котлап килим әле дип, бүләк илтә китте. Син утырып тор, әни, ул хәзер кайтып җитәр, — диде улы, никтер уңайсызланып.

Утырып чәй дә эчтеләр, чәшкеләрне дә юып куйдылар. Килен кайтмады. Гөлсем әби дә кайтырга дип киенә башлады.

— Ярый, улым, минем бит әле Сәлим улыма да барасым бар, кайтыйм инде мин, — диде ул күңеле төшеп.

— Әни, — диде олы улы кыенсынып кына, — мин сиңа бүләк алырга житешмәдем инде. Менә сиңа илле сум гына булса да акча бирим әле, үзеңә һич югы яулык алырсың.

— И, балам, мин бит сезгә бүләк өмет итеп килмәдем. Үз кулларым белән пешергән ризыкны авыз иттерәсем генә килгән иде. Аннары, улым, белеп калса, килен дә ачуланыр, — диде улының игътибарына күңеле эрегән ана.

— Ул белмәс, үзең генә сөйләнмә, — диде улы елмаеп.

Гөлсем апа сөенеп, түбәсе күккә тиеп кайтып китте. Өйләнгәннән бирле улының әнисенә бер генә дә бүләк бирә алганы юк иде бит әле. Һаман шул дөнья малы житми шул киленкәенә.

«Сәлим улыма барганчы тавыкларымны ашатып китим инде», — дип уйлады ана. Абзардагы тавыкларына жим салды, асларына салам түшәде. Аннары, өйгә кереп, мичтәге кайнар табаны сөлгегә төреп, сумкасына салып булышканда шак-шок басып кергән аяк тавышларын ишетеп, туктап калды. «Кунак килә, ахры, кем икән, әллә кызларым кайтты микән әниләрен котларга», — дип елмаеп уйлап куйды Гөлсем апа.

Ишекне киереп ачып, олы улының малае килеп керде дә, ни эшләргә белми, башын иеп, ишек төбендә басып тора бирде.

— Нәрсә, улым, әллә дәү әниеңне котлап открытка язып китердеңме? — диде ул, оныгының аркасыннан сөеп.

Әмма бу сорауга бала, ничектер, аптырап китте, чөнки ул бөтенләй башка йомыш белән килгән иде.

— Ни кирәк, улым, әйт инде? — дип кабаттан сорады дәү әни оныгының чәчләреннән сыйпап.

— Дәү әни, — диде башын аска игән оныгы, — теге, әти сиңа бүләк итеп биргән илле сум акчаны әни кире барып алырга кушты синнән. «Үзенең безгә гомергә дә бүләк биргәне юк әле. Гомумән, безгә бер кешенең дә бернәрсә дә биргәне юк», — диде әни. Шулай дип әйтеп тә бетерде, елап та җибәрде Гөлсем апаның оныгы. — Дәү әни, әтинең сиңа акча биргәнен мин әйтмәдем бит, абыем әйтте, — дип акланырга тырышты бу күңелсез вазифаны башкарырга мәҗбүр булган бала.

— Ярый, улым, кәефең кырылмасын, синең монда бер гаебең дә юк. Хәзер бирәм акчаны. Тик, улыкаем, син хәзер яза беләсең, миңа бер язу гына язып бир. Мин әйтеп торам, — диде дә оныгының кулына кәгазь белән ручка китереп тоттырды.

— Яз, улым, юл уртасына зур хәреф белән башлап «Расписка» дип яз...

Гомере буе башлангыч мәктәптә түбән сыйныф балаларын укыткан пенсиядәге карт укытучы бу расписканы әйтеп яздырганда ниләр уйлагандыр, анысын ул үзе генә белә. Гарьлегеннән буынсыз калган Гөлсем апа күңелендә нинди өермәләр өерелгәнен оныгына сиздермәскә, аны куркытмаска тырышып, йомшак тавыш белән:

— Акчаны югалта күрмә, улым. Берүк, әниеңнең кулына кайтарып тоттыра күр, — дип оныгын сөйде һәм ишектән озатып чыгарып җибәрде. Әмма үзенең инде ишек төбеннән түрдәге диванга барып җитәрлек тә көч-хәле калмаган иде. Кинәт кан басымы күтәрелеп, башы әйләнеп китте, күз алдында йолдыз малайлары җемелдәште.

Эх, дөньяларда... Киленкәе бит үзе укытып чыгарган, үзе тәрбияләгән бала. Шәфкатьле, ми-

һербашы, итагатьле булырга өйрәтмәдемени ул аларны? Хәреф тә танымаган килеш каршымда мөлдерәп күзгә карап торган балалар иде ич! Язарга, укырга, санарга өйрәтүем — шул үзе бүләк түгелмени? Тәрбияләп, укытып, бөркет кебек ул үстереп бирдем. Шуннан да зуррак бүләк була микәнни? Тормыштан гел алуны гына уйлагач, хәтер саклау, күңел күрү дигән төшенчәләр күңелдән җуела микәнни? Шулкадәр вак җанлы, миһербансыз килене белән ул кабаттан ничекләр итеп очрашыр да, ничекләр итеп бер-берсенең күзләренә карашырлар? Халык ишетсә? Ни йөзем белән урамга чыгып, кеше күзенә күренермен? Хурланудан, гарьләнүдән йөрәге теткәләнгән карт ананың башы төрле уйлардан ярылыр чиккә җитеп авырта иде. Ул көчхәл белән диванына менеп ятты.

Ә кызуы әле сүрелмәгән мичтә балаларына бәйрәм күчтәнәче итеп пешерелгән беленнәр майда кайный-кайный, чыжлый-чыжлый сызланалар иде...

ОЯСЫНДА НИ БУЛСА...

— Ай буена тартып-сузып җиткерергә тиешле пенсиямне тагын өч-дүрт көндә эчеп бетереп, мине ачка тилмертергә булдыгызмы инде, кызым? Ни дип шул җыен әтрәк-әләмне җыеп, ашатып-эчертеп яткырасыңдыр, белмим. Нигә бер генә дә башкасең эшләми икән синең, Алланың ачы каһәре төшкере нәрсә?..

— Тик кенә утыр, сукыр тәре! Кемне ашатып-эчертергә үзем беләм мин, синнән сорамыйлар. Юньле булсаң, син үзең безне шушы көнгә төшермәс идең. Кара, рәте бетеп, эт юлында йөрерлеге кал-

магач, баласын каргап утыра. Әллә үзең миннән әйбәтрәк идеңме? Хәерче төенчеге! Баш чатнавына түзәр әмәл юк, да еще син мозгамны кайнатасың. Бар әле, әнә, үз «кабинетыңда» гына ят! — дип, болай җил иссә очып китәрдәй калган ябык, хәлсез Сәбилә әбине идән капкачын ачып, базга төртеп төшерде кызы Вәсимә...

Кечкә табан гына иснә килде Сәбилә әби. Кай җиредер шартлап сынды да бугай. Чөнки аерым гына кайсы төше авыртуын аңларлык хәлдә түгел иде инде ул. Тәненең бөтен җире дә үтереп, чыдый алмаслык итеп сызлый. Башны борырлык та түгел...

Базга ыргытканда үзе артыннан каткан ипи кисәкләре дә ташлады бугай Вәсимәсе. Гел шулай итә ул, Ходайның рәхмәте төшкере. Тик ул каткан ипи кисәкләрен эзләрлек хәле калмады инде Сәбилә түтинең. «Бәхетең булып, кичтән күзләреңне йомып, тыныч кына итеп йоклап китсәң иде дә, иртән бөтенләй уянмасаң икән ул», — дип Ходайдан ничекләр генә сорамады, теләмәде дә бит. Сәгате сукмый үлеме дә килми икән шул аның...

Чигәләренә тигән бетмәс-төкәнмәс бу дөнья мәшәкатьләре, хәерчелек, гаугалы-тавышлы вә тукмаклы тормыш ялкыткан иде инде аны. Ай, ялкыткан иде. Нигә шушы кадәр дә бәхетсез булды әле ул? Нигә үз гомерендә бер генә көн дә рәхәтләр күрмәде? Башкалар бит, әнә, балаларының түр башында, кадер-хөрмәттә генә утыра, җылы түшәктә йоклап, тәмле шулпалар гына ашый... Нигә соң минем балаларым бигрәкләр дә миһербансыз, кансыз булдылар? Тамаклары тук, өсләре бөтен булсын дип, аз тырыштымыни ул?..

Бала чагы бик тә җиңелдән булмады Сәбиләнең. Гражданнар сугышыннан соң туган ул. Авыл кызы. Гаиләләре ишле булды, тамаклары ризыкка

туймады, юньле кием күрмәделәр. Дүртенче сыйныфны тәмамлагач, җәй көне аны район үзәгендә яшәгән хәлле генә туганнары бала карарга дип алып киттеләр. Әле үзең дә бала гына килеш тук гаиләдә үскән холыксыз балаларны каравы бер дә җиңелдән булмады Сәбиләгә. Уналтысы тулып, кулына паспорт алгач та, Уфага китеп тә барды. Фабрикага идән юучы булып урнашты, аннары юньлерәк эшкә күчте. Тулай торактан урын бирделәр үзенә. Төскә әллә ни чибәрлеге булмаса да, сөйкемлелек, ир-атны арбарлык кына күркәмлеге бар иде аның. Әнә, армиядә хезмәт итеп кайткан, үзеннән шактый гына өлкән Сәгыйрь, бәбкә саклаган карга кебек, артыннан калмыйча тагылып йөри. «Бәхетсез итмә мине, синнән башка минут та яши алмыйм. Менә-менә фатир бирергә тиешләр, ачкычын алгач та өйләнешербез», — дип көне-төне кызның теңкәсенә тиеп бетте...

«Әйдә әлегә болай гына яшик, минеке бул!» дип иркәләү-назлауларына түзәрлекмени аның. Болай гына, язылышмый гына яшәргә тәки күндерде Сәгыйрь. Иркәләп, яратып туйгач, көннәрдән беркөнне килүдән дә туктады. Ул Сәбиләнең елаулары, ул кайгырулары, ул үкенүләренең чиге-чамасы булмады. Ике ел чамасы менә Сәгыйрь килеп керер, менә алдына килеп тезләнеп, елый-елый гафу үтенер дип өметләнде. Беркая чыкмады, беркем белән аралашмады. Хәтта киногa да йөрмәде. Сәгыйрь килер дә, аймылыш булырбыз дип курыкты. Янәсе, ул киногa киткәнне белсә, үпкәләп кайтып китәр дә башкача беркайчан да килмәс. Сәгыйрь килмәде. Ә ул өйләнгән булган. Берьюлы ике яры булган икән. Берсе — бәйрәмгә, берсе — көндәлеккә. Көндәлеккә «кулланганы» Сәбилә булган. Ачу катыш ярсуларын тыя-тыя,

тешен кысып булса да, түзде алданган кыз. Кайгысы да басыла төште. Эшләп йөрүен белде.

Шулай беркөнне эштән кайтканда кызмача эчеп алган бер егет бәйнәнепме-бәйләнде кызга.

— Чибәр кызны озатырга барырга ярамасмы икән? — дигән булды.

— Ярый, нишләп ярамасын, без озатканнарны тешләмибез болай, — дип җаваплаганын кыз сизми дә калды. Үзенең кыюлыгына үзе үк сискәнеп куйды Сәбилә. Аннары тагын да кыюлана төшеп: — Нишләп сез көпә-көндез эчеп йөрисез, әллә ял көнегезме? — дип тә сорады әле. Бу сорау егеткә, билгеле, бик үк ошап бетмәде.

— Нәрсә, чибәркәй, синең үзеңнең әллә бер дә аракы эчеп караганың юкмы? Булмаса, әйдә, сыйлыйм әле үзеңне бер, — диде Сәйфулла.

Әнә шулай башланды аларның танышуы. Бер алданып, авызы пешкән кыз, Сәйфулланың эчәргә яратканын аңлап алса да, егетнең артыннан йөрүенә риза булды. Бераздан Сәйфулла аны өзелеп яратуы һәм өйләнергә теләве турында белдерде.

«Вакыт әрәм итеп күпме очрашып йөрергә була инде?» — дип ялварды егет. «Мине хәзер аннан башка кем алсын инде, кыз түгелмен бит», — дип риза булды Сәбилә. Егетнең бәләкәй генә бер бүлмәсе дә бар. Шулай яши башладылар. Сәйфулланың эштән айнык кайткан көннәре бик сирәк була башлады. Кайткач, Сәбиләдән тагы ярты таптырды. Бирмәсәң, тукмый да ташлый. Тукмалып үлеп булмый бит инде. Нишлисең, чәкүшкәсен булса да ала иде Сәбилә. Аракы өстәлдә торса — Сәйфулладан шәп кеше юк. Теленә сандугач төкергән диярсең. Кыстый-кыстый хатынын да эчерде. Күпләп эчмәсә дә, аракы тәменә күнегергә өлгерде Сәбилә. Өйләнеп, бер ел яшәгәч, уллары туды. Малайга бер ай тулу белән эшкә чыкты

яшь ана. Ул вакытта инде зур заводта эшли иде ул. Эшләп-эшләп тә — акча җитмәде. Сәйфулласы эшләп тапкан акчасын бетерә барды. Адәм арасында эшләгәч, адәмчә кием-салым да, өй җиһазлары да кирәк бит инде. Ирле хатын буларак, матур яшисе килә иде Сәбиләнең. Эчә торгач, Сәйфулланы эшеннән дә кудылар. Шуннан соң ул эш эзләп интегеп йөрмәде инде. Каяндыр үзенә шешәдәш дуслар табып ала да аларны өйгә чакыра. Таңга кадәр исереклэр күңел ача. Аларны озаткач, китә сугыш, китә талаш. Ә яшь хатынга иртән алтыда торып эшкә йөгерергә кирәк. Акча җитмәү, өйдә тынычлык булмау һәм тормышның чыдамаслык авырлыгыннан Сәбиләнең сәламәтлеге какшый башлады: башы әйләнә, күз аллары караңгылана, хәле бетә иде. «Ашау җитми, каның начар», — дип, врач ана дарулар язды. Юк акчага дару алып буламыни. Эчмәде Сәбилә даруларны. Даруга акчасын кызганды. Әмма хәле шәбәймәде. Икенче тапкыр баруында врач аңа: «Бала табып кара, каныңны алыштырырга кирәк», — диде. Шуннан соң Сәбилә бер-бер артлы ике кыз бала тапты. Әле үзләренең дә тамагы ипигә юньләп туймаган бер вакытта нәрсә уйлап тапты икән ул балаларны бәхетсез башкае? Газап-михнәтләрнең, хәерчелекнең чиге булмады. Бер кызына өч, икенчесенә ике яшь тулгач, Сәйфулла үлеп китте. Туктаусыз эчүдән организмы бөтенләй кибеп, корып беткән булган. Бер дә кайгырмады аның үлеменә Сәбилә. «Артык бер әрәмтамак, җилкә бетеннән, ниһаять, котылдым. Бер генә рәхәт тә күрсәтмәде бит, алкаш», — дип әрнеде ул, узып барган гомерен уйлап. Кызларын тәүлеклек балалар бакчасына бирде. Аз булса да тын алгандай итте яшь хатын. Сирәк булса да, ит шулпасын да күрә башлады. Балаларына кием-салым да алыштыргалады,

күрше-күләннәр дә иске-москыларын бергәләде. Кешеләр белән аралашырга яраткан алчак күңелле бу хатынны күршеләре чынлап торып кызганалар иде. Тамакка итле шулпа кергәч, кәеф-дәрт тә күтәрелеп, кузгалып куйгалаштыра башлады. Үзе кебек ялгыз хатыннар җыелып, табып корып, кайгы-хәсрәтләрен, күргән-булганнарын юып утыралар иде. Ялгыз хатыннар янына шунда ялгыз ирләр дә килә. Ярты төнгә кадәр шулай күңел ачалар. Ә балалар өйдә үзләре генә кала. Куып кайткалаган чаклары ешая төште. Тере җанны салам салып кына хушландырып булмый бит инде ул. Синс чакыргач, үзең дә чакырмый булмый. Балалар ярты төнгә кадәр йокламыйлар да аннары иртән укырга барырга уяна алмыйлар. Һич торгызып булмый үзләрен. Шулай еш кына дәрес калдыралар. Улы болай әйбәт кенә укыды, училищеда укып рәссам һөнәрен алды. Ә менә кызлары юньсезнең юньсезе булып чыктылар. Укый алмагач, махсус мәктәпкә күчерделәр.

Шулай... Пенсиягә чыккач та эшләми булдыра алмады Сәбилә. Өч баласының берсе дә юньләп эшкә кереп эшләмәде. Уйламадылар да хәтта. Улы инде бераз эшләштерен алгалады. Эчкәч, тиз генә куалар да чыгаралар шул үзен. Их, дус-ишләр белән күңел ачып утырганда, еш кына улын да сыйлыйлар, көчләп-көчләп сыйлыйлар иде шул. Бала, үзе дә сизмәстән, эчәргә өйрәнде дә куйды. Үзе гаепле шул Сәбилә, үзекәе генә гаепле.

Пенсиягә чыккач та әле ун ел эшләде Сәбилә. Кече кызы бер эчкече егеткә кияүгә чыкты чыгуын. Ире фатирына күчеп китте, шөкер аңысына. Ә менә олы кызы — Вәсимәсе, инде 46 яшьтә булуына карамастан, бер генә көн дә эшләп карамады. Кияве дә бер Ходай суккыры нәрсә булып чыкты. Йортка килеп керде бит. Башта болай ару гына кебек

күренгән иде, шофер булып эшләп тә йөрде. Аны да эчкәне өчен эшеннән кудылар. Вәсимәдән китеп, икенче хатынга йортка кереп карады. Хатыны куып чыгаргач, кире кайтты. Кызы үзе юллап алып кайтты. Әнә шулай өйдә бер өер кеше. Барысына — бер пенсия. «Мин үлсәм болар ачка үләчәк», — дип уфтанды Сәбилә. Үлемтегенә дип җыйган акчасын кесәсеннән урлый башладылар балалары. Җитмәсә, кисәк кенә күзләре сукырая башлады Сәбиләнең. Табиблар: «Апа, берүк аракы эчә күрмә, күзең бөтенләй сукыраер», — дип котын алдылар. Хәер, кыяфәтенә карап, Сәбиләнең эчкәләргә яратуын аңлаганнардыр шул. «Двурдагы биш-алты хатын, әнә, туктаусыз эчә, бер дә сукыраймаганнар әле», — дип кенә куйды шул ул вакытта Сәбилә түтиебез. Һәм җае чыккан саен саллы гына төшергәләштерде. Табибларның сүзе дөреска да чыкты. Күзләре томалана башлады Сәбиләттәйнең. Хәзер инде барлы-юклы пенсия акчасы да кызы кулына күчте. Икс дөньяның бер михнәте менә шунда башланды да инде Сәбилә әби өчен. Ире белән пенсия акчасын өч көндә эчеп бетерәләр дә, аннары икмәккә дә тилмереп утырасың. Авыз ачып кызын тирги башласа, тегесе, йодрыкларын төйнәп, бәргәләп алырга да күп сорамас булды. Ачы суыкта куып чыгарырга да кыенсынмадылар. Уф-ф, ачлыгына да түзә ул, тик суыкка гына түзүләре, ай-һай, газап. Ачлык, хәерчелек үзенскен итте, ана көннән-көн ябыкты, сызды, сөяк белән тирегә калды.

Әнисенең пенсиясен алгач, төне буе исерек ирләр белән бәйрәм иткән Вәсимә икенче көнне дә әле анасының кайда икәнлеген аңларлык халәттә түгел иде. Өч-дүрт көннән соң эчәргә акча, ашарына ипис беткәч кенә айный башлады. Ишегалдына чыгып, әби-сәбиләрдән анасы турында

сораштырган булды, тик Сәбилә әбине күрүче булмаган. «Сукыр тәре, кая гына китеп олакты икән?» — дип сукрана-сукрана кайтып, баз капкачын ачып караса — моннан дүрт көн элек җан тәслим кылган Сәбилә әбинең инде каралып беткән йөзен-тәнен күреп, ачы итеп сүгенеп җибәрде...

БҮРЕЛӘР

Авылдан алты-җиде чакрым ераклыктагы диләнкегә кура җиләге җыярга киткән оныгым кичкә табан чиләген тутырып кайтып керде. Минем бисмилла әйтеп, учыма җиләкләр алып авыз итүемне сабыр гына көтеп торды да:

— Кура җиләк быел бигрәкләр күп, нәнәй, тик рәхәтләнеп иркенләп җыя гына алмадык. Малайлар белән Кургы чокырын менеп килә идек, диләнкедән өч баласын ияртеп икс бүре чыгып килүен күрдек. Күрдек тә, әйтерсең менә юлга аякларыбызны кадаклап та куйдылар. Ни кузгалып кире йөгереп булмый, ни разбуй салып кычкырып булмый. Бишебез дә каттык та калдык. Бүреләр безне күрделәр, 2–3 тапкыр туктап карап тордылар. Җитмәсә, балалары безгә таба йөгереп килеп, уйнарга итә башладылар. Башта куркуыбыздан үлә яздык, нәнәй. Аннары тынычландык. Бер дә менә ырлый-ырлый өскә дә килмәделәр, безне ашарга аларның уйларында да юк иде бугай. И-и, курыктык. Минем бит әле бер дә бүреләр күргәнем юк иде. Бүре каршыңа килеп тә чыга, тешләрен ыржайтып сине ашарга дип өстеңә дә сикерә дип уйлый идем. Бер дә алай булмады. Ну курку хисе көне буе әзәрлекләде. Йә куралыктан каршыга килеп чыгарлар, йә юлдан

кайтканда арттан килеп эләктерерләр кебек булды. Бүреләр кеше ашый дигән булалар тагын...

— И улыкаем, җәй көне бүреләр тук булалар ул. Тук булгач, кешегә дә тиеп бармыйлар. Ярый әле балаларына кулыгыз белән кагылмагансыз, менә шунысын яратмыйлар, ди, бит алар. Хәзер безнең якларда бүреләр калмагандыр да инде. Ә менә безнең яшьлектә, авылларга килеп, абзар башыннан төшеп, сарыкларны буып, күтәреп алып китәләр иде. Мин дә очрадым яшь чакта бер өер бүрегә.

...Сугыш беткән еллар иде. Авылларда башлангыч мәктәпләр генә, җиде-уньеллык мәктәпләр районга ике-өч кенә. Укытучылар да җитешми. Җиде сыйныфны бетергәннәр укытучы булып эшләп йөри. Мин Уфада педучилище тәмамлап кайткан укытучы буларак, бездән биш чакрым ераклыктагы авылда 5—7 нче сыйныфларда урыс теле укытып йөрим. Дүшәмбе көн иртәнге алтыда чыгып китәм, шимбә кичен генә кайтам авылга. Яз көннәрендә бер дә куркыныч юк: иртә яктыра, соң гына караңгы төшә. Ә менә көз, кыш айларында ачы бәла инде. Күзгә төртсәң берни күренми, юллар юк. Тездән ләм ера-ера дөм караңгыда секунд саен алдыңа-артыңа әйләнә-әйләнә муеннар тала. Ул заманда бүреләр үрчеде, таң туган саен бер афәтле хәбәр ишетелеп кенә тора.

Шулай кышның язга авышкан бер кичендә туган авылыма кайтырга чыктым. Аякта төпле пима, атлавы авыр. Ай яктысы яп-якты. Басу юлыннан атлыйм. Юлдан бераз читтәрәк салам эскертләре тезелгән. Ниһаять, авыл да күренә башлады. Салам эскерте тирәсендә бер көтү этләр йөри. Язга табан этләр шулай өерләре белән туй ясыйлар. Анысын гына беләбез инде. Юлдан атлыйатлый якынлаштым бит тегеләргә. Барысы да

бертөрлеләр. Сагая төштем. Салам эскерте тирәли нидер эзләгән кебек йөриләр, шунда йоклаган булдылар микән. Бермәлне бөтенесе диярлек бердәй булып күккә карап улап җибәрделәр. Башыма күсәк белән китереп суктылармыни! «Бүреләр!.. Бетте башкаем», — дип уйладым. Тизрәк торып йөгердем. Андый чакта йөгереп тә булмый бит әле ул. Басу капкасына ук килеп җиттем. Борылып артыма карасам, берничә бүре икегә бүленеп юлның ике ягыннан, берничәсе — арттан, өчесе, юлымны кисеп, алга чыкты. Тукталдым. Ни эшләргә дә белмим. Шунда келт итеп букчамдагы икмәк исемә төште. Тиз генә алдым да, вак кисәкләргә бүлеп, башта бер якка, аннан икенче якка ыргыттым. Алдагы бүреләр юл читендәге икмәк кисәкләренә ташланды. Ипекәйне сындыра торам, бүреләргә ыргыта торам. Үзем йөгерәм. Авыл башындагы өйнең капка төбенә килеп җиткәндә икмәгем бетте, шунда этләр дәррәү өрә башлады. Капканы тиз генә ачып, ихатага кердем. Кердем дә, хәлсезләнеп, капканың бу ягына сөялдем. Икмәк тәмен тоеп алган бүреләр дә шак итеп җил капкага килеп бәрелделәр...

Көчкә кайтып егылдым өйгә. Әниемә бер өер бүреләр куып артымнан килүе турында сөйләгән идем, ни еларга белми, ни шатланырга белми һушын җуеп торды. Аннары бар белгән догаларын укый-укый Ходай Тәгаләгә рәхмәтләрен укыды. «Бүреләр, балам, синең икмәгеңә алданып куа килгәннәр ул. Адәм баласын ашарга ниятләре булса, алар күккә карап улыйлар, ди, Алладан ул кешенең нинди икәнлеген сорыйлар — изгеме ул, изге түгелме. Изге кешегә тимиләр икән, — дип, тагын әллә нинди кызык хәлләр турында сөйләде. — Алар син ыргыткан икмәк тәменә алданып ар-

тыщнан килгәннәр. Ашарга ниятләре булса, шунда ук ботарлап ташларлар иде, — дип елап та алды».

Олы бер гомер яши-яши, ерткычларга караганда кешеләрнең куркынычрак икәнен аңладым, улым. Яман кешеләргә дучар итмәсен Ходай үзеңне...

ТАТЛЫ КИЛЕН

Малайны башта укыттык та укыттык, аннан эшли башлады. Утыз биш яшькә житте, һаман өйләнми дә өйләнми бу. Моңа дигән кызлар әле тумагандыр, дип уйлап кайгыра башлаган идек инде карчык белән. Ниһаять, өйләнде бит. Нинди рәк кызга әле! Ул тәсе, ул гәүдәсе дисеңме! Ул аяклары... Жиләк кебек үзе, айдай нурлы йөзе, балдан татлы сүзе. Карчык белән икәү моңа «сөбханаллаһ» дип кенә карыйбыз. Күзебез тияр, диеп куркабыз. «Их, мин әйтәм, яшь чакта синең кебекне очратып булмады шул», — дим бер шаярткан булып киленгә. «Еще не поздно», — димәсенме бу миңа. Житмәсә, күз кысып куйды, чукынчык! Бигрәк шаян да инде үзе! Ул килгәч, өебез ямьләнеп, жанланып китте. Көлеп кайтып керә, көлеп чыгып китә. Кояш кебек инде менә! Йокысыннан торганда да елмаеп уяна, йоклаганда да елмаеп йоклый.

Бигрәкләр сөйкемле дә бигрәкләр алчак инде үзе. Безнең өчен дә өзелеп тора, бәхетле булгыры! Бәхетле дигәннән, Ходай безгә дә өеп бирде бәхетне. Иртәнге унберләр житкәч уяна да, кухняда килен торуга тәмле-тәмле ризыклар пешереп йөгереп йөргән минем карчыкны күреп: «И-и каенанам, бигрәк уңгансың инде: коймак та пешкән, чәй дә кайнаган. Сине яратмаган киленнең эчендә жаны булмас», — дип мактап-мактый. Жылы

сүз — җан азыгы инде. Минем карчыкка шул җитә кала. Эрепләр китә, авызы колагының артына ук җитә. Шулай мактагач, миңа да би-и-ик рәхәт булып китә. Аннан майлап-җайлап, коймак белән, чөкердәшә-чөкердәшә чәй эчәбез өчәүләп.

Малай иртән-иртүк эшкә китә. Ул начальник булып эшли бит инде. Чәйне иртән икешәр мәртәбә эчәбез шулай. Башта иртән-иртүк малайны чәй эчереп җибәрәбез, аннан киленне сыйлыйбыз. Карчык өстәлне җыештыргач, аның белән икәүләшеп кибеткә китәбез. Керәбез базарларга. Тәмле-тәмле азык-төлек җыябыз. Киленне теләсә нәрсә ашатып яткырып булмый бит инде. Аннан чак күтәреп кайтып керәбез. Килен инде, сөенә-сөенә, көлә-көлә, сумкаларны без кайтып керү белән күтәреп ала. «И-и, ничек бу сумкаларны күтәреп кайттыгыз? — ди. — Болай башкача йөрмәгез күтәренеп. Кибет тулы бәләкәй арбалар сатыла. Улыгызга әйтегез: иртәгә үк арба сатып алып кайтсын», — ди. Менә бит нинди безнең килен кайгыртучан! Бигрәк хәстәрле инде. Ул әйтмәсә, йөрер идек әле шулай күтәреп, рәхмәт төшкере! И-и, бигрәк уңдык инде! Күрше Гөлсемнең киленен әйтәм, ну торганы бер кобра инде менә! Иртән эштән кайтып керә дә (ул төнге сменада эшли) каенатасы белән каенанасына кычкыра да башлый. Өй сайгаклары селкенә. Тегеләр дер калтырап төшәләр. «Нәрсә, кабер төплекләре, чәй дә куймагансыз, арт ягыгызга кояш төшкәнче йоклап ятасыз, тәмуг кисәкләре», — ди. Шундый булса киленең, ни эшләр идең? Әстәгъфирулла! Тегеләр кычкырышканны карчык белән, ишек тишегенә колакны куеп, шып кына тыңлыйбыз да: «Әй, безнеке бигрәк әйбәт шул», — дип сөенешәбез.

Килен булып төшкәненә бер ел да үтмәде, секретарь булып эшкә дә керде үзе. Унган инде уңган,

сүз әйтерлек түгел. Әй, арып кайта инде эшеннән шултиклем! «Машинкада пичәтли-пичәтли бармакларым калмады, сызлыйлар инде...» — ди. Әй, аның хәлкәен үзе сөйләмәсә дә аңлап торабыз инде. Аны, чәй куеп, ишек төбеннән үк йөгереп барып каршы алабыз. «Ярар, ярар, киленкәем, әнә, аша да ял ит, телевизор кара...» — дибез. «И-и, бәхетне бирсә дә бирер икән Ходай, — ди. — Сезнең кебек изге, сабыр кешеләр башка беркайда да юктыр ул, — ди. — Мин сезне үз әтием-әниемнән дә ныграк яратам», — ди.

Әле карчык бер егерме көн чамасы дәвахانәдә ятып чыкты. Кайтып та керде, эшкә дә тотынды. Идән юа башлады. И-и, киленкәебезнең коты очты инде. «Әникәем, сиңа бит идән юарга ярамый. Операциядән соң авыр эш эшләргә ярамый, өзлегүең бар, хет бер атна булса да юмый тор. Егерме көн юылмыйча торган идән тагын бер атна гына торыр. Чуртым да булмас идәнеңә. Үзеңне сакла, берүк! Ятып кына тор», — ди өзгәләнеп.

Шул балага ни әйтәсең инде?! Бик әйбәт, бик дус торабыз. Аллага шөкер, киленебезнең теле бал кебек татлы, үзе бала кебек беркатлы, гел безнең яклы. Инде Ходай барыбызга да озын гомер, тазалык бирсен! Уңдык киленнән.

ШӘП КОДА

Хәдичәнең олы кызы медучилищены тәмамлады да бер районга эшкә китте. Ара ерак булу сәбәпле кызы гел генә кайтып та йөри алмады. Хәдичә үзе барып кайтырга булды кызы Халидә янына. Район үзәгенә исән-имин барып төште. Кызы яшәгән авылга бара торган автобуска билет алды. Озак та

көттерми автобус та килеп җитте. Хәдичә билетында күрсәтелгән урынга барып утырды. Алдагы ике урынга бер исерек ир белән мөлаем гына йөзле бер ханым утырды.

Автобус кузгалып та китте. Шуннан кәмит тә башланды. Бу исерек ирнең сүгенгәнен магнитофон тасмасына яздырып, айныгач, үзенә тыңлатсаң, бәлки, башкача аракыны авызына да капмас иде. Авылның бөтен кешесен, колхоз рәисеннән башлап көтүче Чәүкә Хәмиткә тиклем, тиргәп барлап чыкты бу. Берәрсе берәр сүз әйтсә. Хәер, кемнең анның белән бәйләнәсе килсен инде?! Хатыны да бер сүз дә эндәшмәде, әллә куркып, әллә үзе шундый тыныч, түзем кеше. Кыскасы, бу күренеш Хәдичәнең һушын алды. «Инде, Ходаем, нәселдә дә булмады мондый зат, киләчәктә дә була күрмәсен, балаларыма тәүфыйк бирсен, кода-кодагыең шундый була күрмәсен», — дип уйлады.

Кызының исән-имин яшәгәнен күрде, бик канәгать булып, сөенеп икенче көнне кайтып та китте.

Аннан соң байтак кына вакыт үтеп тә китте. Хат алышып тордылар. Ул вакытта бөтен кешедә дә телефон юк иде. Менә бүген дә эштән кайтуына хат китергәннәр: «Әнием, киләсе атнага минем кулымны сорарга киләләр. Киявең буласы кеше һәм аның әти-әнисе белән бергә кайтабыз».

Кодалары килүенә Хәдичә бик нык әзерләнде. Йөз кызарырлык булмасын дип тырышты. Шулай бер атна вакыт үтеп тә китте. «Бүген, Аллаһы боерса, кызым белән булачак киявем, булачак кода-кодагый кайта...» — дип уйлап, яхшы кәеф белән уянды йокыдан Хәдичә. Тиз генә аш салып җибәрде. «Көне дә бит нинди матур! Аллаһ биреп тора...» — дип сөенде, кояшлы аяз күккә карап. Тиз генә кече кызы белән ихатаны да себереп алырга

булдылар. Әллә ни чүбе күренмәсә дә, кызын кодаларга киләләр бит...

Себеркене кулына гына алган иде, капка шыгырдады. Кызы, булачак кияү белән кода-кодагый күренде. Боларны күрү белән Хәдичәнең йөзе агарып, күз аллары караңгыланып китте. Хәдичә кул биреп исәнләшү, танышу урынына сөрән салырга тотынды, чөнки ул алар белән бик тә таныш иде инде. Кода дигәне теге автобуста сүгенгән кеше булып чыкты. Шулай да кодагый буласы кеше бик тә тыныч, әдәпле кеше иде. «Йә инде, Хәдичә, эчкәч кеше ни сөйләмәс, син аны гафу ит инде. Балалар бер-берсен ярата бит, өзелеп тора берсе өчен берсе...» — дип үгетләргә керешге.

Тик Хәдичәнең ишетәсе дә килмәде бу сүзләрне. Булачак кода белән кодагый бу хәлдән югалып калдылар. Шунда кече кызы йөгереп әнисе янына килде дә: «Әни, тукта әле, тавышланма, Халидә апаның бәбие булачак икән, әнә, җизни белән «бала коляскасы алабыз да китәбез», — дип сөйләшәләр. «Бала» сүзен ишеткәч, кемнең күцеле эремәс тә йомшармас... Хәдичәнең башкача чарасы калмады. Риза булды. Гөрләтеп туй ясадылар. Сөеп-сөелеп яшәп яталар кызы белән кияве, тупылдап торган уллары туды. Ә кода бу хәлдән соң бөтенләй эчүен ташлаган һәм кешеләрне тикшерми башлаган. Бу хәл аңа олы сабак булган...

Эчтәлек

Шигырьләр, җырлар

Дус булдык без гомергә 3
Рус — башкорт дуслыгы 4
Башкортстан кызы мин 4
Туган илем — бәхетем 5
Җан дустыма 6
Илкәем 6
Ялгызлык 7
Балачакны сагынам 8
Шикәр тәме 8
Яшик якты тормышта 9
Әтәем, Исәнбаем 10
Халкым санласын мине . . . 11
Өзмик әле өметләрне 12
Чишмә җыры 12
Юанычым 13
Әтиемә истәлек 14
Алыштырма чәчәкне 15
Догалар кыласыңдыр 15
Дустыма 16
Яшьлекнең сере 17
Сөйкемсезне
кем сөйсен? 18
Гомер бер генә 19
Әткәм-әнкәм назлары 19
Дөнья төрлечә була 20
Картәтием 21
Кемгә — кояш,
кемгә — яңгыр... 22
Сагыш 22
Байлык бер айлык 23
Һәркем бәхеткә лаек 24
Кардай саф сөю көтә 25
Башкортстан илемдә 25
Бирешмәдем 26
Тиңлеге сокландыра 27
Кайсысы? 28
Шуңа туадыр җырлар 28
Илемнең хозурлыгы 29
Күңелем түрендә 30
Яшәп туйганнарым юк 31
Сыңар канат 31
Алыштырмыйм акчага 32
Акча җене 33
Сөенеп яшим 33
Сәләм Рузиләгә 34
Кадерле кешем 35
Роберт Миңнуллинга 35
Маңны үзебез саклыйк! 37
Җырлап яшәлем 37
Бәхетеңне сакла! 38
Хозурлык 39
Гадилек начар
бурлыктан 39
Дөнья малы каласы 40
Табибә Зиләгә 41
Әнкәй янында 42
Сеңлемә 43
Нәнәема 44
Шөкерана кылам 45
Рәхмәт, авылдашлар! 46
Яклагыз тынычлыкны! 46
Ташламагыз
туган якны 47
Коръән дәресен үтсәң 48
Чәчәк гомере бездә 48
Сөя белгән бәхетле 49
Чуп-чар һәм
асылташлар 49
Кара җирем 50
Күзге күңел 51

Ничек онытасың? 51
Гомер иттек парлашып 52
Табигать юмарт 53
Илкәем өчен. 53
Илһамым —
туган җирдән 54
Кызың күтә һаман 54
Илеш җире җимешле 55
Каберләре
кайда әтиләрнең? 56
Тукай телендә
сөйләшәм 57
Өйрәнегез эшләргә 57
Күңел җылыңны бүл 58
Габдулла Тукайга 59
Мәңге яшь
булып калдың 59
Без дингезне гизәрлек 60
Җырларым аша
якын күпләргә 61
Әнкәем шомырты 61
Могҗизалар әкияттә 62
Шәфкать туташына 63
Дөнья ямьле,
дөнья матур 63
Әнием, кадерлем! 64
Сизми калдым 65
Без әле әби түгел 65
Әнкәем — сагышым 66
Уем белән 67
Мин үзем Илеш малае 67
Яшик Ходай кушканча 68
Җырым — гомерем 69
Ачабыз тәүге битен 70
Бәхетеңне югалтма 71
Нәнәемнең мирасы 71
Ике фәрештәм 72
Телим бәхетләр 73
Өмет сүнми 73
Сайлап алмыйлар 74
Сөймәгез кеше ярын 75
Күз тимәсен күзеңә 76
Сандугачым 76
Игезәкләрым 77
Үрелмә йолдызларга! 78
Яшьлек —
чәчәк бөресе 78
Яшел —
яшьлегем төсе 79
Вәгъдә-ант бирештек 79
Сөю билгесеме әллә? 80
Саргайсың,
дисеңмени? 80
Әкияттәге кыз 81
Өзгәләнмим,
ашыкмыйм 82
Кемне генә сөяр идем? 82
Ак сирень 83
Сау булыгыз,
кыр казлары 84
Җитәкләшеп
атлыйбыз 84
Чәйләр эчәрбез 85
Йөрәкнең түрен били 85
Кышкы чия 86
Ак карлар яусын 87
Дуслар таптым
җыр аша 87
Телисеңдер күрергә 88
Алмасы нигә ачы? 89
Кайгы килмәсен
башка 89
Кем өшесен кочакта? 90
Гашыйк парлар бәхете . . . 91
Чәнечкеле гөлем 91
Ташлама, иркәм! 92

Сөйдергеч догасы 93
Мәңге йөрәктә 93
Бәхет табыла җирдә 94
Олы абыема 95
Җырламый
ничек түзим?! 95
Кодагыема 96
Сөю күләгәндә 97
Тирән эз сала 98
Мәхәббәт сере 98
Бүген миңа кирәксең 99
Сынган сирень 100
Хат җибәрәм иркәмә 100
Өмет яшәтә 101
Кырмачны
җинә гыйшык 102
Карлар кебек очамын 102
Карашып аңлашабыз 103
Балаларым —
гөлләрем 104
Якты өмет күңелдә 104
Татлы балым 105
Керер әле хәлемә 106
Якты таңда 106
Алтын-көмеш
җыймадым 107
Бәхет өлеше 108
Күреп куансак иде 108
Ни җитә? 109
Җаным ялгыз 110
Сөймәгәнне сөеп 110
Башкорт кызын
сөямен 111
Сагынып яшим 112
Уртак сөю
кавыштырыр 112
Назлар мине, яратып 113
Аерылмагыз ярлардан . . . 114
Кадерле гомеркәем 114
Җөйсез тәәлми яра 115
Яшь гомер
кире кайтмас 116
Соңлаган бәхет 116
Бераү дә бәхет
сатмый 117
Уйламаган идем 117
Карамадым буранга 118
Ташламагыз ярларны 119
Талпыныплар
кайтырсың 119
Әкияттәге
ярны эзләмә 120
Такмаклар 120
Җырлап
яшәргә язсын 121
Ялан чәчәкләре
бирермен 122
Дөньяның
ямьләндерден 123
Пар күгәрченнәр
төсле 123
Ташлар булсаң,
башлама 124
Артыңнан
карап калдым 125
Сикәлтәләр аша 125
Әзерсеңме? 126
Бергә утик 126
Сугыш ярасы 127
Булмый очырып 128
Җыр белән
әйт сереңне 128
Мәңгелек җыр 129
Йөрмим ялынып 129
Әйталмәдем
әйтер сүземне 130

Кадерле Уфам 130
Булганына
рәхмәт укыйм 131
Сагыну җыры 132
Күңелдән җыр түгелә 132
Туганмын
яшьләр өчен 133
Беркем
озатып калмый 134
Ялгыз үтә күрмәгез 135
Уйна, дускай,
гармуныңны 135
Сөяргә кешем барда 136
Чәчәк чагында
җәйнең 137
Әгәр сөйсә 137
Кире кайтмый 138
Мин дә шундый
булганмын 138
Яшәмәдем күеп 139
Сусыз чишмә
булалмый 140
Өметемне өзмәдем 140
Гомерлек була күрсен 141
Яшьлек истәлеге 142
Сөйгән йөрәк
ялгыз булмый 142
Юллар да төрле була 143
Җырлыйк бергә
гомергә 144
Гармунчыбыз
сыздыра 144
Күңелең
тартмый икән 145
Кайда үстең,
чибәркәй? 146
Җәйге урман 146
Туй җыры 147
Оныгым 148
Яшәсәң иде
яшәреп кенә 148
Саумысыз,
авылдашлар! 149
Зифа каеннарым 150
Сөймәсәң, өз араны 151
Төшермә
канатларыңны 151
Көннәр төрлечә килә 152
Синең белән атладым 153
Мин — авыл кызы 153
Тырышам
бирешмәскә 154
Шиңмәс гөлем 155
Сөю саф булса 155
Гомерлек ялгызым 156
Бөтерелә тирәмдә 156
Җуелмый хәтердән 157
Булмый шул тозәтеп 158
«Изге ай» 158
Белмәдем ни уйларга 159
Кирәк шифалы һава 160
Төшем дә,
өнем дә бер 161
Талдырма беләгемне 161
Җырдан
мәңге сүрелмәм 162
Мәхәббәтне сакласак 162
Елмаймый
бәхет кошым 163
Эзләмәсәң дә 164
Яшәү яме 164
Иртәнге чык 165
Яшермим хисемне 166
Газиз әниемә 166
Мәхрүм итмә 168
Күңелдә өмет көйри 168

Мәхәббәт сүрелми 169
Томанда үтә гомер 169
Мәхәббәт алмагачы 170
Шөкер кылып яшим 171
Нишләттең мине,
иркәм? 171
Вакыт узмасын диеп 172
Синең өчен генә 173
Тальян моңы 174
Түзим беразга 174
Кар бөртекләре 175
Яратам диярго
ашыкма 176
Ярата белсәң 177
Ник җибәрдем? 177
Бәхетне тоеп яшим 178
Кайтырсың әйләнеп 179
Мактарлык та шул 180
Очрады юлымда 180
Иң изге кешеләрем 181
Карамыйча беләккә 182
Кышкы кошлар 182
Сөекле нәнәебез 183
Ярдәм булыр 184
Алыштырды сәмәйгә 184
Карчыклар зары 186
Сәгыйть һәм Фәгыйть
мажарасы 188
Гөлләр кебек яшим 189
Ачы була баланы 190
Иблис иярләшсә... 191
Таза буласың килсә... 192
«Эчемне кырып
тормасын...» 194
Кемгә генә кем хаҗәт 195
Иреклек хикмәтләре 196
«Аю —
урманның хакиме...» 198
«Төрле бизәккә
бизәлгән...» 199

Хикәяләр, эссе, юморескалар

Газизләрдән-газиз
әнкәйләр 201
Бәхет язмышта икән 214
Әле дә син бар 218
Язмышмы бу? 229
Айсылу 242
Соңгы бүләк 268
Җуелмас яра 272
Оясында ни булса... 276
Бүреләр 283
Татлы килен 286
Шәп кода 288

В соответствии с Федеральным законом
от 29 декабря 2010 г. № 436-ФЗ 16+

2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ санлы
Федераль законга ярашлы 16+

Литературно-художественное издание

Фаттахова Виниса Шагизадиевна

ЗИМНЯЯ ВИШНЯ

Стихи, песни, рассказы, эссе, юморески

(на татарском языке)

Әдәби-нәфис басма

Фәттахова Виниса Шаһизадә кызы

КЫШКЫ ЧИЯ

Шигырьләр, җырлар, хикәяләр, эссе, юморескалар

Мөхәррире *Г. М. Абдуллина*. Бизәлеш мөхәррире
Л. Р. Мухтаруллин. Рәссамы *И. Я. Нигъмәтҗанов*. Техник
мөхәррире *В. Р. Абдрахманова*. Корректоры *Г. Ф. Закирова*.

Басарга кул куелды 24.09.14. Форматы 70x90 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе.
Литературная гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма таб. 10,82. Шартлы буяу отт. 11,41.
Исәп-нәшер таб. 12,09. Тиражы 1000 данә. Заказ 140968.

Башкортстан Республикасының Зәйнәб Бишева исемендәге
Башкортстан «Китап» нәшрияты дәүләт унитар предприятиесе.
450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.

Әзер файллардан басылды.

Башкортстан Республикасының «Белая река»
нәшрияты дәүләт унитар предприятиесе.
450078, Уфа, Киров урамы, 109.

КИТАП